Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ 7

Методик әсбап



Г. Н. Мөхәрләмова, Д. М. Абдуллина

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**7 нче сыйныф**

Методик әсбап

Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
2024

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
М92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында эшләнде

**Мухарлямова, Г. Н.**
М92 Родная (татарская) литература. Туган телдәге әдәбият. 7 класс. Методическое пособие : для преподавателей образовательных организаций основного общего образования, работающих с обучающимися, владеющими родным (татарским) языком / Г. Н. Мухарлямова, Д. М. Абдуллина. — Казань, 2024. — 128 б.

Методик әсбапта 7 нче сыйныфта «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметыннан дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, предметны өйрәнүдә планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләренең үрнәкләре бирелә.

Әсбап урта сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2024
© Г. Ибраһимов исем. әдәбият һәм сәнгать институты, 2024
© Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. 2024

## ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

Әлеге методик ярдәмлек дәреслек белән эшләүне беркадәр җиңеләйтү, юнәлеш бирү максатыннан әзерләнде.

Бүген мәктәптә сүз сәнгате яңа эчтәлектәге уку фәне — «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы кысаларында өйрәнелә. Әлеге предмет татар баласын туган телдәге әдәбиятка якынайта, сәнгатьнең бер төре булган әдәбият аша укучыны татар теле, тарихы, мәдәнияте, әхлагы, милли холык, милли кыйммәтләр белән таныштыра. Шуннан чыгып, аның максат-бурычлары да яңа нигездә корыла. Төп максат — алга таба әсәрләрне уку өчен мөстәкыйль сайлый белә торган, теләгенә һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле рәвештә үзенең уку эшчәнлеген мөстәкыйль белем алу өчен файдалана белүче грамоталы китап укучы формалаштыру.

Бүген урта сыйныфларда төп эш — вакыт һәм сәнгатьнең төрләре арасындагы бәйләнешне күзәтү аша, әдәбиятның төр һәм жанрлары проблемасын карау. Аерым алганда, 7 нче сыйныфта игътибар үзәгендә әсәрләрне жанр хасиятләренә нигезләнеп өйрәнү, әсәр турында аны иҗат итү закончалыкларына таянып фикер йөртү торачак.

«Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программаларында курсның эчтәлеге белән бергә планлаштырылган предмет нәтиҗәләр дә яңадан каралды. Аерым алганда, төп мәктәптә, ягъни урта сыйныфларда укучыларда формалаштырылырга тиешле предмет нәтиҗәләр әдәбият белән бәйле мәсьәләләрне киңрәк планда хәл итүгә йөз тота. Шул рәвешле, укучыларда Россия Федерациясендәге рус булмаган халыклар әдәбиятлары арасында туган телдәге әдәбиятның урынын һәм ролен, үзүсеш өчен әһәмиятен, сүз сәнгате буларак әдәбиятның образлы табигатен аңлау; әдәби әсәрләрне эстетик кабул итү; эстетик зәвык формалашу; төрле стиль һәм жанрдагы текстларны укый белү; үз фикереңне дәлилләү, фикер алышуда катнашу; әдә-

би әсәр турында сөйләшкәндә элементар әдәби терминологияне белү; тематика, проблематика, образлар дәрәҗәсендә төрле халыкларның фольклор һәм сәнгать әсәрләре арасындагы бәйләнешләрне билгеләү (охшашлык һәм аерымлык принцибы буенча); сүзләрне эстетик функциясендә аңлау; әдәби әсәрне анализлау: аның кайсы әдәби төргә һәм жанрларга каравын билгели алу; темасын, идеясен аңлау; әдәби геройларга характеристика бирү, бер яисә берничә әсәр геройларын чагыштыру кебек предмет нәтиҗәләр алга чыгарыла.

Без бик катлаулы заманда яшибез. Бүгенге җәмгыятьтә булган тәртипләр, кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте бик нык уйландырырлык. Соңгы берничә елда әхлаксызлык күренешләре тормышыбызның күп ягына үтеп керде. 90 нчы елларда җәмгыятьтә башланган үзгәрешләр тормыш идеалларының бәясе кимүе һәм әхлакый бушлык барлыкка килү кебек рухи проблемаларны китереп чыгарды. Җәмгыятьтә глобальләшү тенденциясенең көчәюе милли-мәдәни, милли-тарихи үзенчәлекләрнең кимүенә, аларның әһәмиятләре югалуына китерә. Алар белән бергә кешелеклелек кыйммәтләре, иман, рухи кыйбла кебек аеруча мөһим мәсьәләләр дә артка чигенә, укучыны шәхес буларак тәрбияләүнең нигезе какшый. Шуңа күрә дә хәзерге көндә әдәбият дәресләрендә милли тәрбия бирү, шәхескә этник әхлакый-эстетик кыйммәтләр яссылыгында җәмгыятьтә үз урынын билгеләү юлын күрсәтү, гасырлар буе тупланган милли рухи тәҗрибәне мөмкин кадәр тулырак тапшыру мөһимлеге арта. Шәхси–милли–гражданлык — гомумкешелек кыйммәтләре кебек бер чылбырга тезелеп барган кыйммәтләр системасы укучыны Туган иленең патриоты, туган җирен ярата һәм төрле милләтләргә хөрмәт белән карый торган шәхес итеп тәрбияләүгә юл тоту кирәклеген сорый.

Тәрбия эше — ул билгеле бер сыйныфтан, дәрестән тыш эш, яки сыйныф җитәкчесенең эше дип кенә уйлау, әлбәттә, дөрес түгел. Ул — беренче чиратта бала алдына кереп баскан һәр укытучының да вазифасы. Дәрестә тәрбия эше алып бару уку-укыту процессына билгеле бер дәрәҗәдә комачау итә дигән фикерләр дә очрый. Моның белән һич тә килешеп булмый.

Тел дәресләрендә дә, әдәбият дәресләрендә дә укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү күп очракта матур әдәбият текстларын өйрәнү аша алып барыла. Зур тәэсир итү көченә ия булган матур әдәбият әсәре укучыларның рухи аңын формалаштырырга, кешенең бу дөньяда тоткан урыны һәм аның роле, яшәү мәгънәсе турында күзаллау тудырырга ярдәм итә, югары хисләр тәрбияли.

Чыннан да, кеше төрле фәннәрдән тиешле белемнәргә ия булып та, тормыш өчен кирәкле әдәп-әхлак кагыйдәләрен белмәсә, хис-тойгылардан азат булса, кешелеклелек сыйфатларына ия булмаса, башкалар белән мөнәсәбәтләр урнаштыра алмаса, җәмгыятебез манкортлар һәм кеше сыйфатындагы роботлар ватанына әйләнер иде.

Әдәбият, сәнгатьнең бер төре буларак, кешенең җанына үтеп керә, хисләрен кузгата. Аның төп сурәтләү объекты да кеше, аның рухи дөньясы, яшәеше һәм шуның белән бәйле мәсьәләләр. Шул яктан ул укучыга башка бер фән дә бирә алмаган (дөрес яшәү һәм уңышка ирешүдә башкаларның эчке дөньясын, рухи халәтен, хис-кичерешләрен, холыкларын һәм кәефләрен аңлау һәм алар белән мөнәсәбәт урнаштыру өчен кирәкле булган) белемнәрне бирә. Ә тормышта әңгәмәдәшеңнең холкын, кәефен дөрес билгеләми, аның синнән нәрсә көткәнен аңламый торып, вакытсыз һәм урынсыз сүз башлаудан да олы хата юк. Димәк, ФДББС тәкъдим иткән заман таләбе югарылыгындагы, һәрьяклап үскән, көндәшлеккә сәләтле шәхес тәрбияләү бурычы, иң элек, әдәбият дәресләрендә үтәлә. Шәхескә юнәлтелгән УУГ билгеләгәндә без нәкъ менә шул бурычны ачык күзалларга тиеш булабыз.

Бүгенге көндә әдәбиятка карата (бигрәк тә яшьләрдә) игътибарның нык кимүе беркемгә дә сер түгел. Дөньяны танып белүгә юнәлдерелгән, тормыш дөреслеге булган әлеге өлкә игътибар үзәгеннән төшә бара. Шуның нәтиҗәсендә җәмгыятьнең рухи яктан таркалуы, традицион кыйммәтләрнең җимерелүе күзәтелә.

Төп кыйммәтләр булып прагматиклык, карьера ясый белү, бизнес структураларына уңышлы гына кереп китә белү тора. Шуңа күрә хәзерге яшьләргә классик әдәбиятның кирәге шуның кадәр генә, чөнки аның ориентирлары хәзерге

тормыш кыйммәтләреннән нык аерыла. Әмма бу — ялгыш фикер. Әдәбият искерми, югалмый торган кыйммәтләргә ия. Дәреслеккә кергән әсәрләребез җиде иләктән үткәреп сайланган, аларның һәркайсыннан искиткеч зур тәрбияви чыганак табарга була. Бу — укытучының әзерлекле, эзләнүчән, иҗади булуын гына таләп итә. Кеше үзендә тупларга тиеш булган киң күңеллелек (яхшылык), мәрхәмәтлелек, кешелеклелек, намуслылык, гаделлек, тугрылык, тәрбиялелек, җаваплылык, эш сөючәнлек, башкаларга хөрмәт кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияләүдә аларның роле искиткеч зур.

Бүген рус һәм татар мәктәпләрендә туган (татар) телдәге әдәбиятны укыту яңа ысул-алымнар куллануны таләп итә. Билгеле булганча, балаларның хәзерге вакытта фикер йөртү рәвеше, уйларын башкаларга җиткерү, аралашу дәрәҗәсе үзгә. Аларның компьютер технологияләре белән мавыгуы аралашу даирәсен чикли. Нәтиҗәдә татар әдәби телендә фикерләрен тиешле дәрәҗәдә аңлаешлы, төзек һәм дөрес итеп җиткерә алучы балалар кимегәннән-кими бара. Моны алга таба булдырмас өчен, татар теле дәресләре белән беррәттән, әдәбият дәресләрендә дә әсәрләрне уку барышында аларның эчтәлеге нигезендә фикерләп, монологлар төзү, диалогларда актив катнашу, татар мәктәпләрендә билгеле бер темага фикер алышу кебек эш төрләре ярдәмгә килә ала. Укучыларның сөйләм телләрен үстерү максаты бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып санала. Моннан тыш, татар балаларның (бүгенге көндә, ни кызганыч, бу күренеш хәтта саф татар авылларында да күзәтелә башлады) үз телендә иркен сөйләшә алмаулары да көн үзәгендәге проблемага әверелде.

Аралашу, сөйли белү күнекмәләре укучының коммуникатив компетенциясе белән бәйле. Бу исә сөйләм эшчәнлеге төрләрен формалаштыруның мөһим шарты булып тора. Коммуникатив компетенция ул — кешенең төрле даирәдә һәм аралашу ситуацияләрендә теге яки бу коммуникатив бурычларны тел чаралары ярдәмендә хәл итү сәләте. Укытуның коммуникатив максатын гамәлгә ашыру сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә уку, сөйләү, язу, тыңлау вакытында формалаштыруны аңлата. Коммуникатив гамәлләр, бер яктан, максат, мотив, бурычлар белән бәйле рәвештә

аралашуны оештыру, икенче яктан, сөйләм эшчәнлегенең социаль нормалары белән тәңгәллегенә ирешүгә бәйләнгән була. Бу очракта практик максат — аралашу күнекмәләрен формалаштыру — беренче планга чыга.

Тулы канлы аралашу булсын өчен, кеше шактый гына күнекмәләргә ия булырга тиеш, дип саный психологлар. Беренчедән, аралашу шартларында тиз һәм дөрес ориентлашырга, икенчедән, үз сөйләмен тиз һәм дөрес планлаштырырга, аралашу гамәленең эчтәлеген дөрес сайларга, өченчедән, бу эчтәлекне тапшыруның тиешле чараларын табарга тиеш. Аралашу гамәле чылбырында кайсыдыр буын өзелсә, сөйләүче һәм тыңлаучы да аралашудан көткән нәтиҗәләргә ирешә алмаячак.

Коммуникатив күнекмәләрне формалаштыру таләбе беренче чиратта тел дәресләренә бәйле, шул ук вакытта әдәбият дәресләре дә коммуникатив уку гамәлләрен формалаштыруда зур мөмкинлекләргә ия.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре җәмгыятькә мөнәсәбәтле осталык һәм башка кешеләрнең (әңгәмәдәш, хезмәттәш) позицияләрен исәпкә алуны тәэмин итә; тыңлый белү һәм диалогка керү; проблемаларны бергәләп тикшерүдә катнашу; яшьтәшләре төркеменә кушыла алу һәм алар, өлкәннәр белән бердәм хәрәкәт һәм хезмәттәшлек итә алу осталыгы булдыра.

Коммуникатив уку гамәлләре укытучы һәм сыйныфташлар белән укуда хезмәттәшлекне планлаштыру һәм оештыру максатын, катнашучыларның вазифаларын, алымнарын билгеләү; сораулар бирә белү — информация эзләү һәм туплауда хезмәттәшлек итү; конфликтларны чишү: проблеманы ачыклау, тәңгәлләштерү, аны хәл итүнең альтернатив юлларын эзләү һәм бәяләү, карар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; әңгәмәдәшнең тәртибенә җитәкчелек итү: аның гамәлләрен күзәтү, төзәтү һәм бәяләү; аралашу максатына туры китереп, үз фикереңне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл, ачык һәм дөрес итеп әйтә белү; тел нормаларына туры китереп, монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булуны аңлата. Шулай ук коммуникатив уку гамәлләренә тыңлый һәм башкаларның сорауларына җавап бирү, үзенең

карашын әйтү һәм дәлилләү, үз позициясен тәгъбир итү, коммуникатив мәсьәлә белән бәйле рәвештә сөйләм чараларын куллану, төп күренешләрнең һәм эпизодларның эчтәлеген сөйләү, парларда һәм төркемнәрдә конкрет уку-танып белү мәсьәләләре белән бәйле рәвештә бергәләп эшләү, эчтәлек сөйләү күнекмәләрен үстерү, укылганга телдән рецензия төзү, сөйләм нормаларын исәптә тотып, укытучы, сыйныфташлар белән уку диалогы алып бару, үз фикерләрен тәгъбир итү, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыру керә.

Алда әйтелгәннәр килеп туган каршылыкларны җиңеп чыгарга, әдәбият фәнен укытуның нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итәчәк.

## «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ» УКУ ПРЕДМЕТЫННАН ФЕДЕРАЛЬ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

1. «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программасы (предмет өлкәсе — «Туган тел һәм туган телдәге әдәбият») (алга таба — туган (татар) телдәге әдәбияттан программа, туган (татар) телдәге әдәбият, татар әдәбияты) туган (татар) телдә һәм рус телендә белем бирүче оешмалар өчен туган (татар) телдә сөйләшүче укучылар өчен эшләнде, һәм аңлатма язуын, уку-укыту эчтәлеген, туган (татар) телдәге әдәбияттан программа үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләрен үз эченә ала.

2. Аңлатма язуы туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең төп максатларын, уку планы структурасындагы урынын, шулай ук эчтәлекне сайлап алуга, планлаштырылган нәтиҗәләрне билгеләүгә юнәлешләрне чагылдыра.

3. Уку-укыту эчтәлеге төп гомуми белем дәрәҗәсендә һәр сыйныфта мәҗбүри өйрәнү өчен тәкъдим ителгән эчтәлек юнәлешләрен ача.

4. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә барлык уку чоры өчен шәхескә бәйле, метапредмет нәтиҗәләрне, шулай ук һәр уку елы өчен предмет нәтиҗәләрне үз эченә ала.

5. Аңлатма язуы.

5.1. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программа укытучыга белем бирүдә заманча тенденцияләргә һәм актив укыту методикаларына юнәлдерелгән эш программасын булдыруда методик ярдәм күрсәтү максатыннан эшләнде.

5.2. «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгели торган гуманитар белем бирү юнәлешендәге төп предметларның берсе булып тора. Туган телдәге әдәбиятны өйрәнү тормышны танып белергә һәм чынбарлыкны модельләштерергә ярдәм итә, сүз-сурәт чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы картинасын булдыра һәм аңа билгеле бер мөнәсәбәт тудыра, югары дәрәҗәдәге эмоциональ тәэсиргә ия.

Әдәби белем укуның һәм әдәбиятны өйрәнүнең үзенең шәхси үсеше өчен әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилли һәм аны телдән һәм язма формада тәгъбир итә алган, шулай ук кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен гармонияләштерү, дөньяны тану һәм үзен бу яшәештә күрә белү чарасы буларак системалы рәвештә укуга ихтыяҗы формалашкан укучы тәрбияләү белән бәйле.

5.3. 5–9 нчы сыйныфларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү укучыларның татар әдәбияты әсәрләрен үзләштерүен, художестволы форма һәм эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып шәрехләү һәм анализ күнекмәләрен үстерүне; милли үзаңны үстерү, этник чыгышны аңлау, системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыру үз халкының тарихы, теле, мәдәнияте, дөньяга карашы, менталитеты, фәлсәфәсе турындагы белемнәрне тәэмин итә.

5.4. Уку предметы гуманитар циклга караган башка уку предметлары белән, аеруча «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәбият» уку предметлары белән предметара бәйләнешләрне тәэмин итә.

5.5. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаның эчтәлегендә түбәндәге эчтәлек юнәлешләре аерып чыгарыла:

халык авыз иҗаты (әкиятләр (тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турында әкиятләр), мифлар, риваятьләр, легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр), татар халык җырлары, дастаннар,

бәетлар; татар фольклоры 5—8 нче сыйныфларда тәкъдим ителә);

чорлар буенча татар әдәбияты (әдәби әсәрне мөстәкыйль сәнгать әсәре һәм катлаулы әдәби процессның бер чылбыры буларак карау; татар әдәбиятын аның үсеш этапларына туры китереп өйрәнү, Урта гасырлар, XVIII гасыр, XIX—XX гасырлар әдәбиятларыннан башлап хәзерге татар әдәбиятына кадәр; туган телдәге әдәбиятта тарихи вакыйгаларның чагылышын күзәтү, тарихи барышта татар әдәбиятының роле турында күзаллауларны киңәйтү);

әдәбият теориясе (конкрет әдәби әсәрләрне өйрәнү процессында теоретик-әдәби төшенчәләрне үзләштерү: вакыт һәм сәнгать формалары арасындагы өзелмәс бәйләнешне күзәтү процессында әдәбият төрләре һәм жанрлары проблемасын карау, 5 нче сыйныфта аерым әсәрләр мисалында проза, лирика һәм драма үзенчәлекләре өйрәнелә, 6 нчы сыйныфта лирик әсәрләрдә, хикәядә һәм повестьта, лироэпик әсәрләрдә, драма әсәрләрендә, шулай ук фантастик, автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала, 7 нче сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма, лирик һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен беләләр), 8 нче сыйныфта өйрәнү объекты булып әдәби алымнар (пейзаж, портрет, символ, нәфис деталь һәм башкалар) тора, 9 нчы сыйныфта татар әдәбияты тарихы өйрәнелә.

5.6. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

туган мәдәниятнең мөһим өлеше буларак туган (татар) телдәге әдәбиятка кыйммәти мөнәсәбәт тәрбияләү;

укучыларны үз халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә якынайту;

үзбелем чарасы буларак үз уку эшчәнлеген куллана алган грамоталы укучы формалаштыру.

5.7. Программаны гамәлгә ашыруның куелган максатларына ирешү туган (татар) телдәге әдәбият буенча түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүне күздә тота:

әдәби текстка комментарийлар бирү, анализлау һәм шәрехләү күнекмәләрен үстерү;

укучыларны әдәбият белемендәге анализлау элементларын кертү, аерым теоретик-әдәби төшенчәләр белән таныштыру аша сүз сәнгате буларак туган (татар) телдәге әдәбиятка якынайту;

татар әдәбиятының барышы белән танышу һәм аның тарихи барыш белән бәйләнешенә төшенү;

укучыларның коммуникатив күнекмәләрен (татар телендә сөйләм һәм язма диалогик һәм монологик сөйләмнәрен) үстерү;

уку күзаллауларын формалаштыру;

укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру;

укучыларның туган (татар) телдә иҗади эшчәнлеккә сәләтләрен үстерү;

гомум уку күнекмәләрен һәм универсаль уку гамәлләрен үзләштерү.

5.8. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләрнең гомуми саны — 170 сәгать: 5 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 6 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 7 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 8 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 9 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать).

8. 7 нче сыйныфта уку-укыту эчтәлеге.

8.1. Халык авыз иҗаты.

8.1.1. Бәет — татар фольклорының оригиналь жанры.

Халык авыз иҗаты жанры буларак бәетләр. Жанр хасиятләре. Бәет төрләре. Халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Х. Ярми һ.б.).

Бәетләр: «Сак-Сок бәете»

8.2. Татар әдәбияты.

8.2.1. Хикәя жанры. Хикәя жанры үзенчәлекләре.

Ш. Камал, «Буранда». Укучыга эмоциональ тәэсир итү алымнары. Ана образы.

И. Гази, «Ак сирень». Берече мәхәббәт һәм аның белән бәйле герой кичерешләре. Пейзаж образларының символик мәгънәсе.

Р. Галиуллин, «Сәлам». Тышкы матурлыкны кешенең эчке дөньясына каршы кую. Ялган һәм канәгатьсезлек.

8.2.2. Повесть жанры. Жанр үзенчәлекләре.

Г. Бәширов, «Туган ягым — яшел бишек» (өзекләр). Татар халкының яшәү рәвеше. Кешенең күңел байлыгы, әхлакый принциплар. Милли традицияләр һәм йолалаларның сурәтләнеше. Повестьның автобиографик характерда булуы. Әдәбиятта фольклор үзенчәлекләре.

М. Мәһдиев, «Без — кырык беренче ел балалары» (өзекләр). Сугыш һәм сугыштан соңгы еллар авырлыкларын сурәтләү. Яшүсмер образы.

8.2.3. Роман. Жанр хасиятләре.

И. Гази, «Онытылмас еллар». Романда күтәрелгән проблемалар. Образлар системасы.

8.2.4. Драма жанры.

Т. Миңнуллин, «Әлдермештән Әлмәндәр». Яшәү һәм үлем, җәмгыять алдында җаваплылык, намус, үткәнгә хөрмәт, киләчәккә ышаныч. Әсәрдә көчле кеше образы. Аллегория һәм шартлылык. Драма әсәренең нигезе буларак конфликт. Конфикт төре (тышкы конфликт, эчке конфликт, аларның үзара бәйләнеше).

8.2.5. Лирика жанрлары: пейзаж лирикасы, фәлсәфи лирика, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы.

Х. Туфан, «Агыла да болыт, агыла...», «Кайсыгызның кулы җылы?». Кеше хис-кичерешләренең байлыгы һәм төрлелеге.

Г. Тукай, «Җәйге таң хатирәсе». Табигать образлары.

С. Хәким, «Бу кырлар, бу үзәннәрдә». Туган як образы. Туган ил образын мификлаштыру.

Г. Афзал, «Бу — Ватан». Халыкның милли образы.

Н. Арсланов, «Халкыма». Үз халкы, аның тарихы һәм мәдәнияте өчен горурлык хисе.

Р. Гаташ, «Татар китабы». Татар халкының тарихи шәхесләре. Язмышларының фаҗигасы. Китап — рухи байлык, матурлык һәм мәңгелекнең символы.

Р. Фәйзуллин, «...Җыя кеше». Яшәү мәгънәсе. Кешенең асылы.

Р. Харис, «Кеше кайчан матур?». Кешенең күңел матурлыгы.

М. Мирза, «Көздә бер мәл», «Моң». Лирик геройның хискичерешләрен ачуда табигатьнең роле.

Г. Морат, «Туган тел». Үз халкының тарихына хөрмәт, туган телне саклауда җаваплылык.

8.2.6. Әдәбиятның лиро-эпик жанрлары.

Поэма жанры. Поэманың үзенчәлекләре. Нәсер жанры. Жанр хасиятләре.

Р. Фәйзуллин, «Сәйдәш». Танылган татар композиторы С. Сәйдәшевнең тормышы һәм иҗаты турында поэма. Композитор язмышындагы каршылыклар.

Г. Кутуй, «Сагыну». Туган җиргә сагыну хисен ачыклап килгән Туган илгә мәхәббәт, үз халкы белән горурлану, Туган илгә кайтуга өмет һәм ышаныч хисләре.

8.3. Әдәбият теориясе.

Бәет, хикәя, сюжет, сюжет элементлары, композиция, повесть, әдәби деталь, лирик чигенеш, персонаж, хикәяләүче, роман, драма, конфликт, ремарка, реплика, монолог, диалог, күңел лирикасы, пейзаж лирикасы, фәлсәфи лирика, гражданлык лирикасы, поэма, нәсер, импрессионизм.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

Төп гомуми белем бирү баскычында «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметын өйрәнү укучыларда түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне формалаштырачак:

1) ***гражданлык тәрбиясе:***

гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү, гаилә, белем бирү оешмасы, җирле берләшмә, туган як, туган ил тормышында актив катнашу, шул исәптән әдәби әсәрләрдә чагылдырылган вакыйгалар белән чагыштыру аша да;

экстремизм, дискриминациянең теләсә кайсы формаларын кабул итмәү, кеше тормышында төрле иҗтимагый институтларның ролен аңлау, гражданның төп хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын, күп мәдәниятле һәм күп кон-

фессияле җәмгыятьтә шәхесара мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый нормаларын һәм кагыйдәләрен күзаллау, шул исәптән туган (татар) телдәге әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да;

төрле уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм үзара ярдәмләшүгә омтылу, шул исәптән әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да; мәктәп үзидарәсендә актив катнашу, гуманитар эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***2) патриотик тәрбия:***

татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау, туган телне (татар телен) һәм туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну;

Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү;

Россия символларын, дәүләт бәйрәмнәрен, тарихи, табигый мирасны һәм һәйкәлләрне, илебездә яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итү, аларның татар әдәбиятында чагылдырылуына игътибар бирү;

***3) рухи-әхлакый тәрбия:***

әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү;

үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен, аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу;

җәмгыятьтә кабул ителмәгән гамәлләрне тулысынча кире кагу, шәхси һәм иҗтимагый киңлек шартларында шәхес иреге һәм җаваплылык;

***4) эстетик тәрбия:***

үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең,

шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау;

аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлеген аңлау;

Россия һәм дөнья сәнгатенең кыйммәтен, этник мәдәни традицияләрнең һәм халык иҗатының ролен аңлау;

сәнгатьнең төрле төрләрендә үзеңне чагылдырырга омтылыш;

***5) физик тәрбия, сәламәтлек һәм эмоциональ иминлек культурасын формалаштыру:***

тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау, үз сәламәтлегенә җаваплы карау һәм сәламәт яшәү рәвеше (сәламәт туклану, гигиена кагыйдәләрен үтәү, дөрес оештырылган эш һәм ял режимы, даими физик активлык) алып бару;

начар гадәтләрнең (спиртлы эчемлекләр, наркотиклар куллану, тәмәке тарту) һәм физик-психик сәламәтлеккә башка зыян салу формаларын аңлау һәм кире кагу, шул исәптән интернет-мохиттә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү:

стресслы ситуацияләргә, үзгәрүчән социаль, информацион һәм табигать шартларына җайлашу, шул исәптән үз тәҗрибәсеннән чыгып һәм алга таба максатлар да куеп, үзеңне һәм башкаларны битәрләми кабул итә белү сәләтенә ия булу;

әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау, үз эмоциональ халәтең белән идарә итә алу осталыгы, рефлексия күнекмәсе формалашкан булу, әдәби геройларның гамәлләрен бәяләү аша үзеңнең, башкаларның хаталану хокукы булуын тану;

***6) хезмәт тәрбиясе:***

технологик һәм социаль юнәлештәге практик мәсьәләләрне (гаилә, мәктәп, шәһәр, төбәк кысаларында) хәл итүдә актив катнашу максатын кую, мондый эшчәнлекне башлап җибәрү, планлаштыру һәм мөстәкыйль башкара алу сәләтенә ия булу;

өйрәнелгән предмет белемнәрен куллануга һәм әдәби әсәрләрдә геройларның эшчәнлеге белән танышуга да нигезләнеп, һөнәрләрне һәм хезмәт төрләрен гамәли яктан өйрәнү белән кызыксыну;

уңышлы һөнәри эшчәнлек өчен гомер буе белем алуның әһәмиятен аңлау һәм моның өчен кирәкле күнекмәләр булдыру һәм үстерү;

һөнәри мохиткә яраклаша белү; хезмәтне һәм хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләрен хөрмәт итү, шул исәптән татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләрен өйрәнгәндә дә, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне, ихтыяҗларны исәпкә алып, белем алуның һәм тормыш планнарының индивидуаль траекториясен аңлы рәвештә сайлау һәм төзү;

***7) экологик тәрбия:***

иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү, гамәлләрне планлаштыру һәм аларның әйләнә-тирә мохит өчен мөмкин булган нәтиҗәләрен бәяләүдә куллануга юнәлдерү;

экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау;

экологик проблемалар күтәрелгән әдәби әсәрләр белән танышканда формалашкан карашларга да нигезләнеп, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче гамәлләрне кире кагу;

табигый, технологик һәм иҗтимагый мохитнең үзара бәйләнеше шартларында гражданин һәм кулланучы буларак үз ролен аңлау, экологик юнәлештәге практик эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***8) фәнни танып белү кыйммәтләре:***

үз эшчәнлегендә кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгәнлек;

дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу;

әдәби белем үзенчәлекләрен исәпкә алып, тикшеренү эшчәнлегенең төп күнекмәләрен үзләштерү, тәҗрибә, күзәтү, эш-гамәлләрне аңлауга юнәлгәнлек һәм шәхси, коллектив иминлеккә ирешү юлларын камилләштерү омтылышына ия булу;

***9) укучының үзгәрүчән социаль һәм табигый мохит шартларына яраклашуын тәэмин итү:***

укучыларның социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне, төркемнәрдә һәм җәмгыятьтә, шул исәптән гаиләдә, һөнәри эшчәнлек буенча оештырылган төркемнәрдә һәм берләшмәләрдә, шулай ук башка мәдәни мохит кешеләре белән үзара социаль бәйләнеш кысаларында иҗтимагый тормыш формаларын үзләштерүе, әдәби әсәр персонажларының социаль рольләрен өйрәнүе һәм бәяләве;

билгесезлек шартларында үзара бәйләнештә эш итә белү, тәҗрибә тупларга һәм башкаларның белемнәренә таянырга әзер тору, билгесезлек шартларында эш итү сәләтенә ия булу, гамәли эшчәнлек аша үзенең компетентлык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән башка кешеләрдән өйрәнә алу, уртак эшчәнлектә башкаларның тәҗрибәсеннән яңа белем, күнекмә һәм компетенцияләргә төшенү;

образларны ачыклау һәм үзара бәйләү күнекмәсе, яңа белемнәр формалаштыру сәләте, билгеле булган һәм моңа кадәр билгесез объектлар һәм күренешләр турында идеяләр, төшенчәләр, гипотезалар тәгъбирләү, үзендә белем һәм компетенцияләрнең җитенкерәмәвен аңлау, үз үсешен планлаштыру;

тотрыклы үсеш концепциясе өлкәсендә төп төшенчәләр, терминнар һәм күзаллаулар белән эш итә белү;

табигать, җәмгыять һәм икътисадның үзара бәйләнешләрен анализлый һәм ачыклый алу;

әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне, максатларга ирешү һәм мөмкин булган каршылыкларны җиңүне, глобаль нәтиҗәләрне исәпкә алып, үз гамәлләрен бәяли алу;

стресслы ситуацияне аңлый, тормыш һәм укучы тәҗрибәсенә таянып, дөньяда бара торган үзгәрешләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бәяли алу, стресслы ситуацияне кире кагарлык чара күрелергә тиешле чакыру буларак кабул итү, стресслы ситуацияне бәяләү, кабул ителгән карарларны һәм гамәлләрне үзгәртү, килеп туган куркынычларны һәм аларның нәтиҗәләрен тәгъбирләү һәм бәяли алу, моның төрле юлларын эзләү, билгеле бер ситуациянең уңай ягын таба белү, уңышка ышаныч булмаганда да эшләргә әзер тору.

11.2. Төп гомуми белем дәрәҗәсендә туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү нәтиҗәсендә укучыда танып белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәлләре, регулятив универсаль уку гамәлләре, уртак эшчәнлек осталыгы формалаштырылачак.

11.2.1. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге төп логик гамәлләр формалаштырылачак:

объектларның (сәнгати һәм уку текстлары, әдәби геройлар һәм башкалар) һәм күренешләрнең (әдәби юнәлешләр, әдәби-тарихи барыш этаплары) төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү;

классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, үткәрелгән анализ критерийларын билгеләү;

тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау, аларны ачыклау өчен, критерийлар тәкъдим итү;

куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау;

әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, дедуктив һәм индуктив фикерләүне, охшашлык буенча фикерләүне кулланып нәтиҗәләр чыгару, аларның үзара бәйләнешләре турында гипотезалар тәгъбирләү;

текстларның төрле төрләре белән эшләү барышында уку мәсьәләсен чишү ысулын мөстәкыйль сайлау (чишелешнең берничә вариантын чагыштыру, мөстәкыйль билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, иң кулаен табу).

11.2.2. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак укучыда түбәндәге төп тикшеренү гамәлләре формалаштырылачак:

әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану;

ситуациянең, объектның реаль һәм кирәкле халәте арасындагы аерманы теркәргә ярдәм иткән сорауларны тәгъбир-

ләү, нәрсәнең бирелгәнлеген, ә нәрсәне эзләп табарга кирәклеген мөстәкыйль билгеләү;

үз һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позициянне, фикереңне дәлилләү;

әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү;

тикшеренү (эксперимент) барышында алынган мәгълүматның кулланырлык һәм ышанычлы булуына бәя бирү;

үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру; алынган нәтиҗәләрнең һәм гомумиләштерүләрнең ышанычлылыгын бәяләү коралларына ия булу;

вакыйгаларның алга таба үсешен һәм аларның бердәй яки охшаш ситуацияләрдә нинди нәтиҗәләргә китерәчәген фаразлау, шулай ук аларның яңа шартларда һәм контекстларда, шул исәптән әдәби әсәрләрдә дә үсеше турында фаразлар тәкъдим итү.

11.2.3. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда мәгълүмат белән эш итүнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

чыганаклардан тәкъдим ителгән уку бурычын һәм, бирелгән критерийларны исәпкә алып, әдәби һәм башка төр мәгълүматны эзләү һәм сайлау барышында төрле инструментлар, ысуллар һәм табу алымнарыннан файдалану;

төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү;

төрле мәгълүмат чыганакларында (бер үк идеяне, версияне раслаучы яки кире кагучы) охшаш аргументлар табу;

әдәби һәм башка төр мәгълүматны тәкъдим итүнең оптималь формасын мөстәкыйль рәвештә сайлау һәм гади схемалар, диаграммалар, башка график һәм аларның комбинацияләре ярдәмендә чишелергә тиешле уку мәсьәләләрен тасвирлап бирү;

әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү;

мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру.

11.2.4. Коммуникатив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге коммуникатив күнекмәләр формалаштырылачак:

фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үзеңне (үз фикереңне) телдән һәм язма текстларда белдерү;

аралашуның вербаль булмаган чараларын тану, социаль билгеләрнең мәгънәсен аңлау, конфликтлы ситуацияләрнең алшартларын белү һәм тану, әдәби әсәрләрдә охшашлыклар табып, конфликтлы ситуацияләрне көйләү, сөйләшүләр алып бару;

башка кешеләрнең ниятләрен аңлау, әңгәмәдәшкә ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтү һәм үзеңнең килешмәгәнлегеңне әдәп белән тәгъбир итү, уку диалогы һәм (яки) дискуссия барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү;

уку мәсьәләсен хәл итүгә юнәлдерелгән идеяләрне җиткерү, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау; үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау;

үткәрелгән тәҗрибә (әдәби эксперимент, тикшеренү, проект) нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү;

презентация бурычларын һәм аудитория үзенчәлекләрен исәпкә алып, чыгыш форматын мөстәкыйль сайлау, аңа ярашлы иллюстратив материаллар кулланып, телдән һәм язма текстлар төзү.

11.2.5. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге үз-үзеңне оештыру күнекмәләре формалаштырылачак:

матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау;

карарлар кабул итүдә төрле алымнарга (индивидуаль, төркемдә карар кабул итү, төркем тарафыннан карарлар кабул итү) юнәлеш тоту;

уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, булган ресурсларны һәм үз мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку мәсьәләсен чишү ысулын сайлау, тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын дәлилләү;

эш-гамәлләр планын (билгеләнгән чишү алгоритмын гамәлгә ашыру планын) төзү, һәм өйрәнелә торган әдәби объект турында яңа белемнәр алуны исәпкә алып, тәкъдим ителгән алгоритмны үзгәртү;

сайлау һәм карар чыгаруда җаваплылыкны үз өстеңә алу.

11.2.6. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда үз-үзеңне контрольдә тоту, эмоциональ интеллект, үзеңне кабул итү һәм башкаларны тануда түбәндәге күнекмәләр формалаштырылачак:

әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү;

уку ситуациясенә тиешле бәя бирү һәм аны үзгәртү планын тәкъдим итү;

контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру;

эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү;

яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү;

башкаларның хисләрен һәм үз хисләреңне аеру, атау һәм алар белән идарә итү;

хисләрнең сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау;

матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау;

үз хисләрен белдерү ысулын көйләү;

әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау;

хаталанырга хокукыңны һәм башкаларның да шундый ук хокукын тану;

үзеңне һәм башкаларны гаепләмичә кабул итү;

үзеңә һәм башкаларга карата ачык булу;

тирә-юньдәге бар нәрсәне контрольдә тота алмауны аңлау.

11.2.7. Укучыда уртак эшчәнлекнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

туган (татар) телдәге әдәбият дәресләрендә конкрет мәсьәләләрне хәл итү барышында командалы (парларда, төркемнәрдә, күмәк) һәм индивидуаль эшнең өстенлекләрен аңлау һәм файдалану, куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау;

бергәләп уку эшчәнлегенең максатын аңлау, аңа ирешүдә күмәк рәвештә гамәлләр булдыру: рольләрне бүлү, килешүләр төзү, бергәләп эшләү барышы һәм аның нәтиҗәсе турында фикер алышу;

берничә кешенең фикерен гомумиләштерә белү, җитәкчелек итүгә, йөкләмәләрне үтәүгә, буйсынуга әзерлек күрсәтү;

туган (татар) телдәге әдәбият дәресендә бергәләп эшне оештыруны планлаштыру, үз ролен билгеләү (аралашуда катнашучыларның теләкләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып), команда әгъзалары арасында бурычларны бүлеп бирү, төркем эшендә (сөйләшү, фикер алышу, «аң штурмы» һәм башкалар) катнашу;

эштә үз өлешеңне башкару, үз юнәлешең буенча сыйфатлы нәтиҗәгә ирешү һәм үз гамәлләреңне команданың башка әгъзалары белән координацияләү;

әдәбият дәресләрендә катнашучылар тарафыннан тәгъбир ителгән критерийларга таянып, гомуми нәтиҗәгә керткән өлешеңнең сыйфатын бәяләү;

нәтиҗәләрне башта куелган бурыч һәм һәр команда әгъзасының нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлеше белән чагыштыру, җаваплылык өлкәсе белән уртаклашу һәм төркем алдында хисап бирергә әзерлек күрсәтү.

11.5. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең предмет нәтиҗәләре.

7 нче сыйныфны тәмамлаганда, укучы:

*татар телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнә:*

сәнгатьле итеп укырга һәм программада билгеләнгән әсәрләрне һәм аларның өлешләрен яттан сөйләргә;

укыган әсәрләрнең проблемасын билгеләргә һәм тәгъбирләргә;

әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм проблематикасын чагыштырырга;

әдәби геройны, аның төс-кыяфәтен, холык сыйфатларын, гамәлләрен һәм башка геройлар белән мөнәсәбәтләрен характерларга;

үзләштергән әдәби-теоретик төшенчәләрне (хикәя, повесть, роман, лирика жанрлары, комедия, драма, сюжет, диалог, монолог, композиция һ.б.) әдәби әсәрне анализлау барышында кулланырга;

әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләргә;

әсәрдә конфликт төрен ачыкларга;

эпик әсәрдә вакыйгаларның үсеш этапларын билгеләргә;

тәкъдим ителгән әдәби тематика (бер әсәрне кулланып) буенча инша язарга;

*рус телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнәчәк:*

сәнгатьле итеп укырга һәм программада билгеләнгән әсәрләрне һәм аларның өлешләрен яттан сөйләргә;

укыган әсәрләрнең проблемасын билгеләргә һәм тәгъбирләргә;

әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм проблематикасын чагыштырырга;

әдәби геройны, аның төс-кыяфәтен, холык сыйфатларын, гамәлләрен һәм башка геройлар белән мөнәсәбәтләрен характерларга;

үзләштергән әдәби-теоретик төшенчәләрне (хикәя, повесть, роман, лирика жанрлары, комедия, драма, сюжет, диалог, монолог, композиция һ.б.) әдәби әсәрне анализлау барышында кулланырга;

әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләргә;

әсәрдә конфликт төрен ачыкларга;

тәкъдим ителгән әдәби тематика (бер әсәрне кулланып) буенча инша язарга.

# ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

## 7 класс — 34 сәгать (рус телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема, | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | **Халык авыз иҗаты** | | |
| 1 | Татар фольклорының оригиналь жанры — бәет (1 сәгать) | Шатлыкта — нур тама, кайгыда — моң ага (Татар халык авыз иҗаты жанры буларак бәет. «Сак-Сок бәете») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укылган бәетләр текстының эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү: бәет төшенчәсен үзләштерү, фольклор әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау |
| | | **Татар әдәбияты** | | |
| 2 | Хикәя жанры (4 сәгать) | Күңелеңдә буран купса... (Эпик жанр буларак хикәя. Ш. Камал. «Буранда») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку; рольләргә кереп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, әсәр исеменең мәгънәсен аңлау һәм аңлату, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү. |
| | | Ана күңелен аңлау кирәк (Ш. Камалның «Буранда» хикәясендә ана образы) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Хакыйкатьтән өстен көч юк (Р. Галиуллинның «Сәлам» хикәясе) | 1 | Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән геройның портретын тудыру.<br>Укыган әсәр проблемасын формалаштыру.<br>Текстны сөйләү: кыскача һәм җентекләп сөйләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Текст буенча сораулар төзү.<br>Хикәя язу алгоритмын ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү: хикәя жанрының үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш башкару: жанр үзенчәлеген исәпкә алып хикәя язу |
| | | Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| 3 | Повесть жанры (7 сәгать) | Җанга сеңгән бишек җылысы (Повесть жанры үзенчәлекләре. Г. Бәширов. «Туган ягым — яшел бишек») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку; рольләргә кереп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, укыган әсәрнең темасын, идеясен билгеләү, проблемасын формалаштыру, әсәр исеменең мәгънәсен аңлау һәм аңлату.<br>Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән геройның портретын тудыру.<br>Әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү. |
| | | Туган җир — тормыш мәктәбе (Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте) | 1 | |
| | | Халык күңеленә уелган бизәкләр (Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда образлар системасы) | 1 | |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Басулардан парта арасына кайтканда (М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте) | 1 | Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Моң белән уралган истәлекләр (М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте) | 1 | |
| | | Иртә егет булган малайлар (М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестенда яшүсмер образы) | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. | 1 | |
| 4 | Роман жанры (3 сәгать) | Өйгә таба юл якынмы? (Роман жанры. И. Гази. «Онытылмас еллар») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Уку әңгәмәсе: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: вакыйгалар эзлеклелеген, әсәрнең темасын һәм идеясен |
| | | Балконлы йортта кемнәр яши? (И. Газиның «Онытылмас еллар» романы) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Ерак Казанга таба юл totып (И. Газиның «Онытылмас еллар» романының проблематикасы). Үткән материалны кабатлау | 1 | билгеләү, тышкы кыяфәте, эчке сыйфатлары, гамәлләре, башка геройлар белән мөнәсәбәтләреннән чыгып әсәр героена бәя бирү. Текстны сөйләү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| 5 | Драма жанры (3 сәгать) | Яшәү яме нәрсәдә? (Драма жанры Т. Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку. Уку әңгәмәсе: укылган пьеса текстының эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган текстның эчтәлеге буенча сораулар әзерләү, тышкы кыяфәте, эчке сыйфатлары, гамәлләре, башка геройлар белән мөнәсәбәтләреннән чыгып әсәр героена бәя бирү. Текстны сөйләү: план буенча сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Иҗади эш: сочинение язу. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Рух нык җаннар бирешми (Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә көчле кеше образы) | 1 | |
| | | Кеше китә — җыры кала (Иҗади эш: «Кеше китә — җыры кала» темасына сочинение) | 1 | |
| 6 | Лирик жанрлар (12 сәгать) | Табигатькә таң калырлык (Лирика жанрлары. Пейзаж лирикасы. Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә табигать образы) | 1 | Уку: шигырьләрнең мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: әсәрләрнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәрнең эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Күңелдәге моңнар сүзгә күчә (М. Мирза. «Көздә бер мәл») | 1 | Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәрләрнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү, сурәтләү һәм лирик геройның хисләрен белдерү чараларын ачыклау, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Әдәби әсәрләренең эчтәлеге һәм проблемасы арасындагы бәйләнешне ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата» (Иҗади эш: «Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата» темасына сочинение) | 1 | |
| | | Йөрәк ярасын җылы куллар гына дәвалый (Күңел лирикасы. Х. Туфан. «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә хис-кичерешләр тирәнлеге) | 1 | |
| | | Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр нәрсә әйтер туганнарыма (Х. Туфан. «Агыла да болыт агыла») | 1 | |
| | | Яшьлек эзләре калган үзән (С. Хәкимнең «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре) | 1 | |
| | | Байлык белән бәяләнми гомер (Фәлсәфи лирика. Р. Фәйзуллин «...Җыя кеше», М. Мирза. «Моң») | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Үткәннәребез бай, киләчәгебез өметле (Гражданлык лирикасы. Г. Афзал. «Бу Ватан», Н. Арсланов. «Халкыма») | 1 | |
| | | Туган телне сайлап алмыйлар (Г. Морат. «Туган тел»). | 1 | |
| | | Утта янмый, суда батмый безнең үткәннәр (Р. Гаташ. «Татар китабы») | 1 | |
| | | Йөз матурлыгы күзгә өчен... (Р. Харис. «Кеше кайчан матур?») | 1 | |
| | | Кеше кайчан матур була? (Проект эше яклау).<br>Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| 7 | Поэма жанры (2 сәгать) | Моң чишмәсе кайдан башлана (Әдәбиятның лиро-эпик жанрлары. Поэма жанры. Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш») | 1 | Уку: поэманың мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри |
| | | Халык белән мәңге бергә (Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш») | 1 | |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Хикәяләү: укылган эпизодлар һәм өлешләр буенча тасвирлап сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Музейга виртуаль экскурсиядә катнашу |
| 8 | Нәсер жанры (1 сәгать) | Ерагайган саен ара, сагыну арта бара (Нәсер жанры үзенчәлекләре. Г. Кутуйның «Сагыну нәсере») | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, нәсердә хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| 9 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү |

## 7 класс — 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** |
| | | **Халык авыз иҗаты** | | |
| 1 | Татар фольклорының оригиналь жанры — бәет (1 сәгать) | Шатлыкта — нур тама, кайгыда — моң ага (Татар халык авыз иҗаты жанры буларак бәет. «Сак-Сок бәете») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укылган бәетләр текстының эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү: бәет төшенчәсен үзләштерү, фольклор әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау |
| | | **Татар әдәбияты** | | |
| 2 | Хикәя жанры (4 сәгать) | Күңелендә буран купса... (Эпик жанр буларак хикәя. Ш. Камал. «Буранда») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, әсәр исеменең мәгънәсен аңлау һәм аңлату, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү.<br>Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән |
| | | Ана күңелен аңлау кирәк (Ш. Камалның «Буранда» хикәясендә ана образы) | 1 | |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Сиреньнәр чәчәк аткан мәлдә (И. Гази. «Ак сирень») | 1 | геройның портретын тудыру.<br>Укыган әсәр проблемасын формалаштыру.<br>Текстны сөйләү: кыскача һәм җентекләп сөйләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Текст буенча сораулар төзү.<br>Хикәя язу алгоритмын ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү: хикәя жанрының үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш башкару: жанр үзенчәлеген исәпкә алып хикәя язу |
| | | Хакыйкатьтән өстен көч юк (Р. Галиуллинның «Сәлам» хикәясе. Үткән материалны кабатлау) | 1 | |
| 3 | Повесть жанры (6 сәгать) | Җанга сеңгән бишек җырысы (Повесть жанры үзенчәлекләре. Г. Бәширов. «Туган ягым — яшел бишек») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, укыган әсәрнең темасын, идеясен билгеләү, проблемасын тәгъбир итү, әсәр исеменең мәгънәсен аңлау һәм аңлату. |
| | | Туган җир — тормыш мәктәбе (Г. Башировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Халык күңеленә уелган бизәкләр (Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда образлар системасы) | 1 | Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән геройның портретын тудыру.<br>Әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Басулардан парта арасына кайтканда (М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте) | 1 | |
| | | Моң белән уралган истәлекләр (М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте) | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш | 1 | |
| 4 | Роман жанры (4 сәгать) | Өйгә таба юл якынмы? (Роман жанры. И. Гази. «Онытылмас еллар») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: вакыйгалар эзлеклелеген, әсәрнең темасын һәм идеясен билгеләү, тышкы кыяфәте, эчке |
| | | Балконлы йортта кемнәр яши? (И. Газиның «Онытылмас еллар» романы) | 1 | |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Ерак Казага таба юл тотып (И. Газиның «Онытылмас еллар» романының проблематикасы) | 1 | сыйфатлары, гамәлләре, башка геройлар белән мөнәсәбәтләреннән чыгып әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| 5 | Драма жанры (3 сәгать) | Яшәү яме нәрсәдә? (Драма жанры Т. Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган пьеса текстының эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган текстның эчтәлеге буенча сораулар әзерләү, тышкы кыяфәте, эчке сыйфатлары, гамәлләре, башка геройлар белән мөнәсәбәтләреннән чыгып әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Рух нык җаннар берешми (Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә көчле кеше образы) | 1 | |
| | | Кеше китә — җыры кала (Иҗади эш: «Кеше китә — җыры кала» темасына сочинение) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6 | Лирик жанрлар (12 сәгать) | Табигатькә таң калырлык (Лирика жанрлары. Пейзаж лирикасы. Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә табигать образы) | 1 | Уку: шигырьләрнең мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: әсәрләрнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәрнең эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәрләрнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү, сурәтләү һәм лирик геройның хисләрен белдерү чараларын ачыклау, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Әдәби әсәрләренең эчтәлеге һәм проблемасы арасындагы бәйләнешне ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Көндәлеге моңнар сүзгә күчә (М. Мирза. «Күздә бер мәл») | 1 | |
| | | Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата» (Иҗади эш: «Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата» темасына сочинение) | 1 | |
| | | Йөрәк ярасын җылы куллар гына дәвалый (Күңел лирикасы. Х. Туфан. «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә хискичерешләр тирәнлеге) | 1 | |
| | | Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр нәрсә әйтер туганнарыма (Х. Туфан. «Агыла да болыт агыла») | 1 | |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Яшьлек эзләре калган үзән (С. Хәкимнең «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре) | 1 | |
| | | Байлык белән бәяләнми гомер (Фәлсәфи лирика. Р. Фәйзуллин «...Җыя кеше», М. Мирза. «Моң») | 1 | |
| | | Үткәннәребез бай, киләчәгебез өметле (Гражданлык лирикасы. Г. Афзал. «Бу Ватан», Н. Арсланов. «Халкыма») | 1 | |
| | | Туган телне сайлап алмыйлар (Г. Морат. «Туган тел») | 1 | |
| | | Утта янмый, суда батмый безнең үткәннәр (Р. Гаташ. «Татар китабы») | 1 | |
| | | Йөз матурлыгы күзгә өчен... (Р. Харис. «Кеше кайчан матур?») | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Кеше кайчан матур була (Проект эше яклау)<br>Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| **7** | Поэма жанры (2 сәгать) | Моң чишмәсе кайдан башлана (Әдәбиятның лиро-эпик жанрлары.<br>Поэма жанры. Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш») | 1 | Уку: поэманың мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Хикәяләү: укылган эпизодлар һәм өлешләр буенча тасвирлап сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Музейга виртуаль экскурсиядә катнашу |
| | | Халык белән мәңге бергә (Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш») | 1 | |
| 8 | Нәсер жанры (1 сәгать) | Ерагайган саен ара, сагыну арта бара (Нәсер жанры үзенчәлекләре.<br>Г. Кутуйның «Сагыну нәсере») | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү |

*Дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, нәсердә хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| 9 | Нәтиҗәләр чыгару | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

7 нче сыйныфта туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүгә тәкъдим ителә торган дәреслек төп гомуми белем бирү өчен яңартылган Федераль белем бирү стандартына туры китереп һәм федераль эш программаларына нигезләнеп эшләнде.

Дәреслекнең төзелеше, материалның күләме, фәнне өйрәнү өчен кирәкле төшенчәләр белән таныштыру яңа калыпка салынды. Дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус) күздә тотып төзелде, төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материаллар аерып бирелде, ягъни дәреслектәге мәгълүмат телне бик аз белгән укучыдан алып югары әзерлекле укучының да ихтыяҗын канәгатьләндерә ала. Татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен алар өстәмә рәвештә дәреслекнең чите буйлап график сурәт (пунктирлар) ярдәмендә билгеләнә. Телне белү һәм әдәби үсеш дәрәҗәләрен исәпкә алып, татар балалары өчен әдәби материал чагыштырмача күләмлерәк тәкъдим ителә. Шулай ук ике дәрәҗәгә аеру әсәр ахырыннан соң урнаштырылган сорау-биремнәрдә дә чагылыш таба.

Татар телендә белем бирү мәктәпләренә предметны укыту өчен укытучыга киңәшләр, аерым темалар методик әсбапта зәңгәр төс белән бирелә.

Дәреслектә тәкъдим ителгән сорау һәм биремнәр, укучыларда билгеләрне аерып чыгару максаты белән, объектларны анализлау, синтезлау — өлешләрдән бөтен төзү, объектларны чагыштыру, классификацияләү критерийларын сайлау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, фикер йөртүнең логик чылбырын төзү, фикерләрне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән һәм язма формада белдерү кебек универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга йөз тота. Дәреслектәге биремнәр, артык кыенлыклар тудырмыйча, әсәрнең эчтәлеген, хасиятләрен белү, геройларга характеристика бирү, сәнгатьчә эшләнешенә игътибар итү белән бәйле. Алда әйтелгәнчә, татар телендә белем бирү мәктәпләрендә укучылар өчен сораулар бераз катлаулырак, укучыларның иҗади сәләтләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне төшенүгә юнәлтелгән булачак.

Тексттан соң бирелгән сүзлекчәдә таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта — урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе күрсәтелә.

Дәреслектә сүз белән эшләү максатыннан махсус рубрикада әдәби текстларда очраган фразеологизмнарга, канатлы сүзләргә, образлы гыйбарәләргә аңлатма бирелә.

Сүз сәнгате буларак өйрәнгән вакытта, укучыларда туган телдәге әдәбиятны милли мәдәниятнең бер өлеше буларак аңлау белән бәйле компетенция формалаша. Этномәдәни материал яңа УМКларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең барлык этапларында да тәкъдим ителә, моны дәреслекләрнең эчтәлегендә дә ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, укучылар әдәби-тарихи материал белән танышканда, комментарий-аңлатмалар, шул исәптән теге яки бу вакыйга, мәдәни объект, күренеш яки төшенчә турында тарихи мәгълүматлар да бирелә. Бу — укучыларның танып белүгә кызыксынуларын арттырырга, шул исәптән татар халкының мәдәнияте, тарихы турында белемнәрне киңәйтергә ярдәм итә. Моннан тыш, биредә милли мәдәниятнең халык тарихы белән генә түгел, ә гомумән ил тарихы белән дә үзара бәйләнеше күзәтелә.

Дәреслектә милли-мәдәни һәм тарихи характердагы комментарийлар әдәби әсәрләрне уку барышында бирелеп бара. Әдәби текстта очрый торган, теге яки бу сәбәпләр аркасында укучыларга таныш булмаган аерым сүзләр, милли-мәдәни компонентлы төшенчәләр әлеге рубрикада урын ала. Сүз беренче чиратта архаизмнар, тарихи сүзләр, татар халкының һәм гомумән Россиянең ерак үткәнендә булган төшенчәләр һәм күренешләр турында бара. Комментарийлар укучыларны төрле сәнгать әсәрләре белән таныштыру максатыннан да тәкъдим ителә. Милли-мәдәни компонент дәреслектәге иллюстрацияләрдә сурәтләнгән киемдә, бизәнү әйберләрендә, көнкүрештә, йортларның бизәлешендә, интерьерда чагылыш тапкан.

Шулай ук дәреслектә урын алган «Бу кызыклы», «Файдалы фикер» рубрикалары белән танышу укучыларның дөньяга карашларын, белемнәрен киңәйтүгә хезмәт итә.

Татар халкы тарихы, сәнгате, әдәбияты өлкәсенә зур өлеш керткән шәхесләребез турында кыска гына, гомуми күзәтү «Шәхесләребез» рубрикасында ясала. Моннан тыш, программа өйрәнүне күздә тоткан аерым язучыларыбызның тормыш юлы һәм иҗатын киңрәк яктыртуга дәреслектә зур игътибар бирелә. (Укучыларны таныштыру максатыннан, төрле чорда яшәгән күренекле шәхесләребезнең биографиясенә бәйле фотоархив белән https://photo.miras.info/№ сылтамасы буенча кереп танышырга мөмкин).

Дәреслекнең тулы электрон варианты, видеодәресләр, өстәмә материалны табу һәм куллану өчен чыганаклар, методик ярдәмлек заман укытучысына уңышлы эшчәнлек өчен мөмкинлек тудыра. Дәреслекнең электрон вариантында, төп материал белән беррәттән, һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр, аудиоязмалар һ.б.

Дәреслектәге уку материалы өлешчә видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 7 нче сыйныф өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган видеороликларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә һәм алар федераль белем бирү программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты — укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Бу видеоязмалардан дәресләрдә дә, дистанцион укытуда укучының уку материалын мөстәкыйль үзләштерүе барышында да файдаланырга мөмкин. Шулай ук укучылар белән дәрестән тыш эшләгәндә, дә аларны уңышлы кулланып була.

Әлеге видеодәресләр, шулай ук туган (татар) телдәге әдәбиятны уку-укыту барышында кулланыла торган норматив документлар, федераль эш программалары, дәреслекләрнең, уку әсбапларының электрон вариантлары, методик әсбаплар, медиаматериаллар, татар балалар әдәбияты антологиясе белән «Мәгърифәт» медиаплатформасында танышып була (https://magrifat.antat.ru).

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ[1]

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә. Методик әсбапта тәкъдим ителгән дәрес үрнәкләрендәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомум һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештырганда, ул үзе теләгәнчә эшли ала. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема**: Шатлыкта — нур тама, кайгыда — моң ага (Татар халык авыз иҗаты жанры буларак бәет. «Сак-Сок бәете»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау; ата-анага хөрмәт, туганлык хисләренә төшенү, дус-тату яшәүнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — татар халык авыз иҗаты жанры буларак «Сак-Сок бәете» эчтәлеген һәм идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—14.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

---

[1] Аерым дәрес үрнәкләре берләштереп тәкъдим ителә.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес кереш сүздән башланып китә. Дәреслектә авторларның укучыларга мөрәҗәгате бирелә. Шулар белән таныштырганнан соң, бәетләр темасын өйрәнүгә керешәбез.

*Туганнар татулыгы байлыктан артык* мәкале нигезендә сөйләшү оештырып була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләнгәннәргә нигезләнеп дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрес татар фольклорына гына хас булган бәет жанрын өйрәнүгә багышлана. Теманы ачу өчен, «Сак-Сок бәете» алынды. Әлеге бәетнең структурасы, эчтәлеге, жанр үзенчәлеге, образлар системасы, тел-сурәтләү чаралары тикшерелә. Әсәрне өйрәнү нәтиҗәсендә, укучылар бәетләргә аңлатма бирә, аларның поэтик үзенчәлекләрен билгели, тематик яктан төрләрен аера, кеше тормышына тәэсирен аңлауга ирешәләр.

Бәет жанрына билгеләмә биргәнче, иң элек әсәр белән танышырга, аңа анализ ясарга кирәк. Шулар эшләнгәннән соң гына, укылган бәет мисалында әлеге жанрның үзенчәлекләрен барлау, күрсәтү отышлы булачак.

Әсәрне сәнгатьле итеп укып чыккач, укучылар беренче тәэсирләре белән уртаклашалар, аңлашылмаган сүзләрне барлап, мәгънәләрен ачыклыйлар. Бу эштә видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

«Сак-Сок бәете»нең эчтәлеге барыбызга да мәгълүм. Бер гаиләдәге ике малай ялгыш тимер укны сындыралар. Әниләре моның өчен аларны бик каты орыша һәм каргый. Малайлар Сак һәм Сокка әйләнеп урманга очып китәләр һәм беркайчан да бер-берсе белән кавыша алмыйлар.

Әлеге әсәрне анализлаганда, дәреслектә тәкъдим ителгән сорау-биремнәргә нигезләнәбез. Моннан тыш, түбәндәге моментларга да игътибар итү сорала.

«Сак-Сок бәете»ндә кайгы төсмере белән белдерелгән образларны ачыклап була. Әйтик, *ятимнәр, канлы яшь, урыныбыз урман, кара карлыгач, сары сандугач, сары күлмәк, кара ат, пар каен*. Каен образы татар фольклорында ялгызлыкны белдерә. *Канлы яшь — кайгының иң зурысы, караңгы шыксыз урман — куркыныч җир, бәхил бул — мәңгегә хушлашу* кебек гыйбарәләр кайгы билгеләре белән сугарылган. Шулай ук кара, сары төсләрнең кайгы һәм аерылу билгеләре булуына игътибар иттерәбез. Төсләр турында сөйләшүне дәвам итеп, аларның түбәндәге мәгънәләрен ачыклыйбыз:

Аклы күлмәк — балачакның матур мизгеле;
Кара карлыгач — малайларның берсе;
Сары сандугач — малайларның икенчесе;
Кара урман — авыр тормыш;
Сары күлмәк — кайгылы язмыш;
Яшел путам — әтисенә яхшы мөнәсәбәт.

Образларның хис-кичерешләрен билгеләгәндә, шулай ук кайгы, сагыш, борчылу, үкенү хисләре өстенлек итүе күрсәтелә.

Бәет жанрына билгеләмә бирү өчен, «Сак-Сок бәете» хас үзенчәлекләрне барлыйбыз. Укучылар аның сюжетка ия һәм шул ук вакытта хисси якның да көчле икәнлеген, ягъни лиро-эпик жанрга каравын ачыклыйлар. Икенче үзенчәлек — шигъри формада булуы, ике юллыклардан торуы күрсәтелә. Укучылар аның эчтәлек ягыннан фаҗигалы хәлләр турында сөйләнүе, образларның тормыштан алынуы турында әйтә алалар.

Тагын бер үзенчәлеген күрсәтү максатыннан, Ания Туишева башкаруында «Сак-Сок» бәетен тыңлатырга мөмкин. Әсәрне тыңлаганнан соң, укучылар нәтиҗә ясыйлар: бәетләр көйләп әйтелә.

Бу эшләрдән соң укучылар белән бергәләп бәеткә билгеләмә бирәбез:

Бәет — гарәп сүзе (тезмә әсәрнең һәр ике юлы дигәнне аңлата); татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Аның

нигезендә күпчелек очракта кайгылы яки көлкеле вакыйгага ята. Тема башында *Фаҗига һәм көлке бер жанр эчендә ничек яши ала*? дип бирелгән проблемалы сорауга нәкъ менә бу урында җавап табыла.

Бәет шигъри формада язылып, телдән әйтелә яки көйләп башкарыла.

Бәетләр төзелеше (композицион) яктан ике катламның кушылуыннан гыйбарәт: эпик башлангыч фаҗигалы яки көлкеле якларны бәян итсә, лирик башлангыч шул вакыйгаларга бәйле лирик герой күңелендә туган кичерешләрне укучыга җиткерә.

Кайбер галимнәр бәетне җырлана-сөйләнә торган хикәят дип йөртәләр. Бәетләр көйләп әйтелә. Бәетләр көйле, рифмалы булулары, ритмик төзелешләре, ике яки дүрт юлдан торулары белән җырга охшаган. Ләкин бәет нинди дә булса бер сюжетка корыла һәм анда тормыштагы берәр вакыйганы сурәтләү төп максат итеп куела. Бу жанрның төп алымы — бәян итү, хикәяләү, сөйләү, әйтү.

Бәетләр туганнарын, якыннарын, дусларын югалтучы кешеләрне юату өчен язылалар. Аларда берничә кеше катнаша. Бәет фаҗигага очраган кешенең хисләре, аның туганнары, якыннарының хисләре, бәет чыгаручы автор хисләре турында да сөйли. Шуңа күрә ул күләмле, чөнки хиснең сәбәбен, дәрәҗәсен һәм юану турындагы строфаларны берничә тапкыр кабатларга тиеш була. Бәеттә фаҗигага юлыккан кешенең хисләре дә, аның туганнарының хисләре һәм бәет чыгаручының дә хисләре дә бар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта өлкәннәрнең сүзен тыңларга кирәклеге хакында әңгәмә үткәрелә. Татар мәктәпләрендә «каргыш» сүзенең мәгънәсе турында уйландырып, сөйләшү оештырырга мөмкин.

Шулай ук дәреслектә бирелгән әдәбият галимнәре, фольклорчылар һәм язучыларның бәет турында әйткән фикерләре белән таныштыру урынлы. Бу вакытта бәетләрне тикшерүче танылган фольклорчы галим Хәмит Ярми турында мәгълүмат бирелә. Укучылар бу мәгълүмат белән дәреслектән укып таныша алалар.

Ахырдан теманы йомгаклау максаты белән, «Бәет җырдан нәрсә белән аерыла?» соравы ярдәмендә укучыларның дәрестә алган белемнәренә таянып нәтиҗә ясатабыз.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Бәетне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә. Бәет сюжеты буенча иллюстрация ясарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Күңелеңдә буран купса... (Эпик жанр буларак хикәя. Шәриф Камал. «Буранда»);

Ана күңелен аңлау кирәк (Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә ана образы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; әниләргә карата мәхәббәт, хөрмәт хисенә төшенү, үз әниләренә игътибарлы булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ш. Камалның «Буранда» хикәясенең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 15—29.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә, үткән материал искә төшерелә.

2. *Ана күңеле балада, бала күңеле далада* татар халык мәкале нигезендә теманы өйрәнүгә юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы ике дәрес хикәя жанрының үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлана. Укучы хикәя жанрына билгеләмә бирә, хикәядә сюжет сызыгын һәм сюжет элементларын билгели алачак. Хикәяләүче образының бирелешен, укучыга эмоциональ тәэсир итү көчен арттыру өчен кулланылган алымнарны күрсәтергә өйрәнәчәк. Әдәби әсәрләрдә импрессионизм билгеләрен аера беләчәк. Өйрәнү объекты итеп Ш. Камалның «Буранда» хикәясе алына. Әлеге хикәя укучыда әниләргә карата мәхәббәт, хөрмәт хисе тәрбияли, үз әниләренә игътибарлы булырга өйрәтә, тормыш вакыйгаларын хикәяләү, дусты, якын кешесенең билгеле бер вакыйгага булган мөнәсәбәте, хис-кичерешләрен күрү, тою күнекмәләрен булдыра.

Әлеге әсәрне өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

Укучылар хикәяне уку барышында әсәрнең эчтәлеген ачыклап, түбәндәге төп вакыйгалар турында сөйлиләр: Мостафа исемле солдат әнисе янына кайтып бара. Ул бергә хезмәттә булган Хөсәен дустына кунарга керә. Мостафаның күңеле боек, ул тизрәк өенә кайтырга ашкына. Көн буранлы булуга карамастан, ашыгып, юлга чыга. Юлда барганда, бала чагын, әнисен искә төшерә. Мостафа әнисе белән егерме ел күрешмәгән, ә хәзер тизрәк әнисен күрергә, аңардан гафу үтенергә ашыга. Ул кайтуга, әнисе үлгән була.

Әсәрне анализлау барышында түбәндәге моментларга игътибар итү сорала.

Ш. Камалның «Буранда» хикәясендә Мостафаның үкенү, газаплану, ялгышны төзәтергә теләү хисе яктыртыла. Без аның вөҗдан газабы кичерүен күрәбез, ягъни автор геройның күңелендә психологик конфликт барлыкка килүен тасвирлый. Мостафа кичерешләре пейзаж белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Мәсәлән, төне буе бала елавы белән тышта буранның котырынуын сурәтләү әсәрнең буеннан-буена Мостафа кичерешләренең нинди хәлдә икәнлеген күрсәтә. Буран — символик образ. Ул, геройның газаплы кичерешләрен чагылдырып, ситуациянең кискенлеген, драматизмын ассызыклый.

Әсәрдә аерым урынны ана образы алып тора. Ана кайгылы, чөнки тиздән үләчәген белә. Шуңа күрә ул бик күп еллар күрмәгән улын юксына. Ананың кыяфәте мескен итеп бирелә: йөзе сары, күзләре төпкә баткан, кул-аяклары салкын, үзе авыр сулый. Ләкин һаман улын көтә, кызыннан «Килмәдеме?» дип сорап тора.

Әсәрнең темасы — кешенең вөҗдан газабы кичерүе. Автор әлеге әсәрендә, һәр кеше үзенең гаебен вакытында танып, аның өчен гафу үтенергә тиеш, чөнки соңга калырга мөмкин, дигән фикер җиткерә. «Буранда» хикәясе безне башка кешеләргә карата игътибарлы, мәрхәмәтле булырга өнди, матур сыйфатларга ия булырга чакыра.

Әлеге әсәр белән «Хикәя жанры» исемле зур тематик блокны ачып җибәрәбез. Беренче дәрестә үк хикәя жанрына гомуми билгеләмә бирү кирәк.

Зур булмаган вакыйгаларны үз эченә алган кечкенә күләмле эпик жанр хикәя дип атала. Сөйләп бирүгә, хикәяләүгә нигезләнгән, катлаулы булмаган вакыйгаларны, күп очракта тормыш-көнкүрешенең бер эпизодын, кеше характерын сурәтли, кеше гомеренең бер мизгелен, холкындагы бер сыйфатның чагылышын аерып күрсәтә.

Хикәя укылып беткәч, икенче дәрестә, Ш. Камалның «Буранда» әсәрендә хикәя жанрына хас үзенчәлекләрне барлыйбыз. Укучылар хикәядә зур булмаган вакыйгалар сурәтләнүен, эпик жанр, кеше гомеренең бер мизгеле тасвирлануын билгели алачаклар.

Шулай ук бу әсәрне өйрәнү кысаларында сюжет төшенчәсен үзләштерү каралган. Укучыларга сюжет элементлары турында аңлатма бирәбез. Әлеге эш артык вакыт алмасын өчен, сюжет турында билгеләмә белән таныштырабыз һәм «Буранда» хикәясе мисалында сюжет элементларын барлыйбыз.

Эпик әсәрләрдә нинди дә булса вакыйгалар яктыртыла. Әсәрдәге вакыйга-хәлләр яки кеше холкының үсү-үзгәрү тарихы сюжет дип атала. Сюжетны конфликт хәрәкәткә китерә. Әсәрдә конфликт барлыкка килә, үсә һәм чишелә. Менә шушы сыйфатлар сюжетның элементларын (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш) билгели.

Гадәттә, әдәби әсәр кереш сүз (пролог) яисә башламнан (экспозиция) башланып китә. Әдәби әсәрдә пролог булмаска да мөмкин, ул бик сирәк очрый. Авторның әсәрдә күптән булган бер вакыйганы ниндидер максат белән әсәр башында сөйләп куюын пролог дип атыйлар. Ул әсәрнең эчтәлегенә кереп китәргә ярдәм итә. Экспозициядә конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр күрсәтелә. Әдәби әсәрдә вакыйгаларны, гадәттә, шул сәбәпләрне күрсәтүдән башлыйбыз. *Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә экспозиция булып нәрсә тора дип уйлыйсыз?* дип укучылардан сорыйбыз. Укучылар бала елавын билгелиләр.

Төенләнеш ул — конфликтның башлану ноктасы. «Буранда» хикәясендә төенләнеш булып нинди вакыйга санала ала?» соравына укучылар Мостафаның юлга чыгуын күрсәтәләр.

Конфликтның зураю, тирәнәюе, аны чишәргә омтылышлар вакыйгалар үстерелешен тәшкил итә. Хикәядә вакыйгалар үстерелеше этабына юлдагы хәлләр, хатирәләрне, Мостафаның үкенүен кертә алабыз.

Әсәрдәге вакыйгаларның, көрәш, каршылыкларның иң югары ноктасы кульминацион нокта санала. Биредә кульминацион нокта — ананың үлеме.

Чишелеш этабы конфликтка нокта куелу, проблеманың хәл ителүен аңлата. Ул я конфликтның юкка чыгуын, я чишелә алмаслыгын күрсәтә. «Буранда» хикәясендә Мостафа-

ның әнисен исән килеш күрә алмавына үкенү әсәрнең чишелешен тәшкил итә.

Укучылар белән табылган сюжет этапларын схема рәвешендә эзлекле итеп күрсәтеп бару отышлы. Мәсәлән,

**Экспозиция**
Бала елавы

→

**Төенләнеш**
Мостафаның юлга чыгуы

→

**Вакыйгалар үстерелеше**
Юлдагы хәлләр, хатирәләр,
Мостафаның үкенүе

→

**Кульминацион нокта**
Ананың үлүе

→

**Чишелеш**
Мостафаның әнисен исән
килеш күрә алмавына үкенү

Ш. Камалның «Буранда» хикәясе — импрессионизм исемле сәнгать агымы үзенчәлекләрен исәпкә алып язылган әсәр. Шуңа күрә импрессионизм төшенчәсе белән укучылар 7 нче сыйныфта ук танышалар.

Импрессионизм (французча «тәэсир» дигән сүздән) — әйләнә-тирә дөньяны үзгәрештә, шуннан алган кәеф-халәт бирелеше кебек сурәтләргә омтылган сәнгать агымы. Ул кәеф, халәт, тойгы, кичереш һәм аларның үзгәрүен югалырга әзер мизгел кебек күрсәтә; тышкы сурәт, күренешне төсләр, тавышлар гармониясе ярдәмендә тергезә. Зәвыклы, эмоциональ, матурлыкка сокланучы, хисләнүче кешенең эчке дөньясы байлыгын раслый. Тиз үтүче мизгел матурлыгы аркылы гомумән тормышка бәя бирә, дөньяга караш үзенчәлеген билгели. Импрессионизмның төп билгеләре:

- матурлыкны аңлый, бәяли белүче герой, лирик герой, хикәяләүче яисә авторның тормышны нечкә зәвыклы итеп күрүе аша тасвирлана;
- хәрәкәттәге мизгел матурлыгы, үзгәреш халәте сурәтләнә;
- һәр кечкенә детальнең мәгънәсен белдерә;

• сүзләр сайланышы ярдәмендә көй-халәт тудыра;

• психологизм, хисләр тирәнлеге, кешенең бай эчке дөньясын күрсәтү, очраклылык беренче планга чыга һ.б.

Ш. Камалның «Буранда» хикәясендә импрессионизм билгеләрен күзәткәндә түбәндәгеләр ачыклана: буран күренеше Мостафаның күңел халәте белән тәңгәл килә; хикәядә лапас һәм морҗаларда әллә нинди моңлы җырлар җырлана иде; бала һаман елый; тышта буранның сызгыруы һәм стенадагы сәгать тыкылдавы; өй түбәсендә «кар-кар» итеп, карга карылдый; этләр өрә иде; үзалдына бер моң һәм зар көйли торган тавышлар килә; тышта буран дулый иде тавышлары тасвирлана; «Буранда» хикәясендә сурәтләнгән төсләрдән яулыкның төсе зәңгәр, читләре ак; күз алдында очсыз-кырыйсыз караңгылык, төсе балавыз кебек саргайган, күз алдына каралы, яшелле пәрдәләр корыла кебекләрне күрсәтеп була.

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дөнья әдәбиятында ана-бала образын яктырткан әсәрләр бик күп. *Укылган хикәя нигезендә Ана образына характеристика бир: ул нинди сыйфатларга ия? Әдәби әсәрдәге Ана образы белән син үз әниең арасында охшаш сыйфатларны күрәсеңме? Әсәрләрдә ана-бала тирәсендә барган вакыйгалар тормышта да очрарга мөмкинме?* кебек сораулар ярдәмендә әңгәмә оештырып була. Әңгәмә барышында түбәндәге нәтиҗә ясала: хикәядә ана образы нигездә сабыр, түзем, баласы өчен догада торган, соңгы минутка кадәр баласы өчен сулап, аны көтеп яшәгән авыр язмышлы татар хатын-кызы итеп сурәтләнә. Баласы нинди холыклы булуга карамастан, аны ярата, аңа соклана, аның өчен янып-борчылып яши. Һәр ана да сабыр, безнең өчен борчылып, безгә изге теләкләр-бәхет теләп тора. Хикәядәге вакыйгалар тормышта да кабатланырга, ана белән бала арасы бозылырга мөмкин. Балалар әниләрнең сүзләрен һәрвакыт тыңламый, аларны аңларга теләми, шуңа күрә аңлашылмаучылык килеп чыга. Татар халкы, бала күңеле — далада, дип белмичә әйтми. Баланың уе уенда, дуслары янында, үз хыял дөньясында. Ә үскәч, үзенең тормыш мәшәкатьләре белән яши. Еш кына әни кешегә тиешле игътибар, хөрмәт җитәрлек дәрәҗәдә бирми. «Буранда»

хикәясендә солдаттан кайткан буй җиткән ир-егет Мостафа соң булса да ялгышын аңлап, әнисеннән гафу үтенергә ашыга. Ләкин соңга кала.

Әниләр турында мәкаль һәм әйтемнәрне искә төшерергә мөмкин: Мәсәлән, *Ана куены туннан җылырак; Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс; Ананың бер догасы җиде мулланың бәддогасын җиңә. Агачына күрә алмасы, анасына күрә баласы; Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада; Ана янында бала ятим булмый; Баласы суга төшәр анасы утка төшәр* һ.б.

*Мостафаның әнисе үлмәгән булса, гафу үтенергә җитешкән булса, төп герой үзен ничек тотар иде? Аның холык-сыйфатлары, гадәтләре үзгәрер идеме? Әллә инде үзгәрергә соңмы?* дип, укучыларны уйлануга этәрергә мөмкин.

Әлеге ике дәрестә шактый зур әдәби һәм теоретик материалны өйрәнү күздә тотылган. Аны укучыларның үзләштерү-үзләштермәвен белү өчен һәм укучыларның белемнәрен ныгыту максатыннан, түбәндәге тестны үткәрергә мөмкин.

1) Нәрсә ул сюжет? Дөрес җавапны билгелә.
а) персонаж фикерләренең бәрелеше
ә) персонажлар сөйләме
б) образларның бирелеш рәвеше
в) **вакыйга яки кеше холкының үсү-үзгәрү тарихы**

2) Сюжетны нәрсә хәрәкәткә китерә? Дөрес җавапны билгелә.
**а) конфликт**
ә) пейзаж
б) метафора
в) лирик чигенеш

3) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә бала елау нинди вакыйгага сәбәп була? Дөрес җавапны билгелә.
а) манарадан азан әйтелүгә
б) авыл этәчләренең кычкыруына
**г) Мостафаның йокламавына**
д) Хөсәеннең чәй ясавына

4) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә нинди күренеш сюжетны хәрәкәткә китерә? Дөрес җавапны билгелә.

а) җил дулавы

**ә) бала елавы**

б) таң атуы

в) ананың үлеме

5) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә бала елау һәм тыштагы җил — буран дулау метафоралары нинди мәгънәне ячерәләр? Дөрес җавапны билгелә.

а) Гаишәнең ире һәм кунагы өчен борчылуын

ә) Хөсәеннең дусты белән күрешү шатлыгын

**б) Мостафаның хис-кичерешләрен**

в) солдат хезмәтенең авырлыгын

6) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә төенләнеш — конфликтның башлану ноктасы булып нинди вакыйга тора? Дөрес җавапны билгелә.

а) Хөсәеннең ат эзләргә чыгып китүе

ә) Ананың Мостафаны көтүе

**б) Мостафаның юлга чыгарга карар бирүе**

в) ананың үлеме

7) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә вакыйгалар үстерелеше кайдан башлана? Дөрес җавапны билгелә.

**а) Мостафаның балачак хатирәләрен яңарту, үкенү-газаплары, гафу үтенү теләге**

ә) бала елавыннан

б) буран дулавыннан

в) Мостафаның әнисе битенә көл сибүеннән

8) Әдәби әсәр сюжетының кульминациясе нәрсә ул? Дөрес җавапны билгелә.

а) конфликтның башлану ноктасы

ә) конфликтның зураю, тирәнәюе, аны чишәргә омтылышлар

**б) әсәрдәге вакыйгаларның, көрәш-каршылыкларның иң югары ноктасы**

в) конфликтка нокта куелу, проблеманың хәл ителүе

9) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә иң югары нокта булып кайсы күренеш тора? Дөрес җавапны билгелә.

а) Мостафаның буранлы иртәдә дусты йортыннан чыгып китүе

**ә) Ананың үлүе**

б) әнисенең үлем түшәгендә ятуы

в) Мостафаның әнисе янына кайтып керүе

10) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясеннән бирелгән җөмләне укы. Бу җөмлә кайсы сюжет элементы булып килә. Дөрес җавапны билгелә.

*«Иптәш, ат әзерләп куй. Миңа тизрәк китәргә кирәк».*

а) пролог

**ә) төенләнеш**

б) иң югары нокта

в) чишелеш

11) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясеннән өзекне укы.

*«Һаваның бозыклыгына карамый, хәят-хәрәкәт үз юлы белән бара иде. Бер якта, шыгырдап, урам капкасы ачыла, кемдер һәм ни өчендер чыгып бара, икенче якта тагын берсе кар астыннан әллә ниләр чыгарып маташа...»*

Әлеге өзек әсәрнең кайсы сюжет элементы булып килә? Дөрес җавапны билгелә.

а) экспозиция

ә) төенләнеш

б) пролог

**в) вакыйгалар үстерелеше**

12) Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә язылган *«Нечкә тармакның очыннан ычкынып китте»* дигән сүзләр нәрсәне аңлата? Дөрес җавапны билгелә.

а) Мостафаның әнисен күреп шатлануын

**ә) әнисенең үлемен**

б) әнисенең авыру хәлен

в) Мостафаның елавын

**V. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Сиреньнәр чәчәк аткан мәлдә (Ибраһим Гази. «Ак сирень»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау; беренче мәхәббәт төшенчәсен аңлау, аның татлы да, газаплы да хис, кайчак җавапсыз булуына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — И. Газиның «Ак сирень» хикәясенең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 29—34.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә үткән материалны искә төшерү.
2. Укучыларга ак сиреньнәр чәчәк ату күренешен тасвирлаган видеоязма күрсәтеп була. Шуның нигезендә *Чәчәк аткан сиреньнәргә карап, синең күз алдыңа нинди ассоциацияләр килә? Сирень чәчәкләре нинди сыйфатларга ия?* со-

рауларын биреп әңгәмә уткәрелә, теманы өйрәнүгә юнәлеш бирелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәрдән чыгып, дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

И. Газиның «Ак сирень» хикәясен өйрәнүгә программада 1 сәгать вакыт каралган. Шушы вакыт эчендә әсәрне укып, аны анализлау күздә тотыла. Сюжетын барлаганда, үткән дәрестә каралган схеманы төзетергә мөмкин.

**Экспозиция**
Сания исемле кыз турында сөйләү

→

**Төенләнеш**
Көлтә башлы егетнең Санияләр тәрәзә төбеннән үтеп китмәве

→

**Вакыйгалар үстерелеше**
Саниянең ашкынып урамга чыгып китүе, кинотеатр каршына килеп туктавы

→

**Кульминацион нокта**
Саниянең сөйгәнен башка кыз белән күрүе, хисләренең җавапсыз икәнен белүе

→

**Чишелеш**
Саниянең өенә кайтып китүе, ишегалдында бик озак үзенә урын таба алмыйча йөреп, таш стенага маңгаен терәп үксеп елап җибәрүе

И. Газиның «Ак сирень» хикәясе беренче мәхәббәт турында. Сания, гашыйк булгач, хыялга бирелә, шигырьләр укырга, җырлар тыңлап хозурланырга ярата башлый. Кызның шул рәвешле күңеле нечкәрүе, татлы күз яшьләре түгүе мәхәббәтнең кеше күңелен нечкәртүен, матурлыкны күрә белергә өйрәтүен аңлата.

Автор күз яшен татлы, ди. Моның белән ул беренче мәхәббәт — иң матур хисләрнең берсе, аның шашкын яратуы да, сөйгәнеңне югалту ачысыннан туган газабы да татлы һәм кадерле, дип әйтергә тели.

И. Газиның «Ак сирень» хикәясендә төп каршылык хыял һәм чынбарлык арасында. Әлеге каршылыкны сурәтләү аша автор, кеше һәрчак матур хыяллар корып яши, әмма чынбарлык кырыс һәм аяусыз, күп кенә хыяллар реаль чынбырлык белән бәрелешеп челпәрәмә килә, юкка чыга, шулай да хыяллар белән яши алган кеше генә тормышның матурлыгын тоярга сәләтле, дигән фикер җиткерә. «Ак сирень» хикәясендә төп идея — мәхәббәт — кешене үзгәртүче татлы да, газаплы да хис, ул, хәтта җавапсыз булса да, һәрвакыт серле һәм матур дип яңгырый.

И. Газинең «Ак сирень» хикәясендә табигать образлары Саниянең беренче мәхәббәт хисенең сафлыгын, самимилеген ачып бирә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Гашыйк эшен дә онытыр, ашын да онытыр* мәкале нигезендә әңгәмә оештырып була.

Алдагы дәрестә алган белемнәрне ныгыту максатыннан, түбәндәге өзекне укытып, бу өзектә сурәтләнгән тавышларның импрессионизм сәнгать агымына хас сурәтләү чаралары булып торуын билгеләтәбез.

*«Ачык тәрәзәдән бүлмәгә кичке шәһәр тавышы агыла... Серле тавыш. Чыркылдап көлгән тавышлар... Пышылдашкан тавышлар... Әллә язгы төн үзе шундый серле итеп пышылдыймы? Әллә тротуар тутырып йөрүче кызлар пышылдашып сөйләшәләрме? Бу серле тавышлардан Саниянең күңеле иләс-миләсләнә. Балачактагы кебек, әнкәсенең муенына барып сарыласы килә».*

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Хакыйкатьтән өстен көч юк (Рөстәм Галиуллинның «Сәлам» хикәясе. Үткән материалны кабатлау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау; ялганның нинди нәтиҗәләргә китерә алуына төшенү; тугрылык, ышаныч хисен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Галиуллинның «Сәлам» хикәясенең эчтәлеген белү, идеясен билгеләү, белемнәрне системага салып гомумиләштерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 35—40.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. *Төче ялганнан ачы хакыйкать яхшы* мәкале нигезендә әңгәмә оештырып була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә туган җир турында сүз барачагын фаразлыйлар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Р. Галиуллинның «Сәлам» хикәясендә студент яшьләр тормышыннан бер вакыйга сурәтләнә. Шуңа күрә дә

бу хикәя иң беренче чиратта яшь укучы өчен кызыклы. Автор аларны Рамил белән Алинә ялгышын кабатламаска өнди.

Хикәя нигезендә Рамилнең телефон аша Алинә исемле кыз белән танышуы, аралашуы һәм аларның аралары өзелү вакыйгасы ята. Әсәрне өйрәнү барышында үткән дәрестә төзелгән схема рәвешендә сюжет элементларына таркатып сөйләтергә мөмкин.

Экспозиция — Алинәнең Рамилгә смс язуы, аларның телефон аша аралашып китүләре.

Төенләнеш — Рамил белән Алинәнең беренче очрашуы вакытында егетнең телефоннан сөйләшкән кыз белән янәшәдәге кыз арасында уртаклык тапмавы.

Вакыйгалар үстерелеше — Рамилнең күңелен Алинә биләве, аны гына уйлавы, телефоннан Алинәнең туганы шалтырату, кызга эт ташлануы, аның Мәскәүдә дәвалануын әйтүе, Алинә белән икенче тапкыр күрешү.

Кульминацион нокта — Алинәнең Рамилгә үзе турында дөреслекне ачуы.

Чишелеш — Рамилнең Алинәгә дип язган ярату сүзләрен җибәрми калуы.

Рамил Алинәгә җанга якын тавышы, төпле киңәшләре өчен гашыйк була. Ул паркта кыз белән ике тапкыр очраша. Беренче юлы аның белән очрашуга Алинәнең игезәге Алисә, икенче юлы Алинә үзе килә. Хикәядән шул өлешләрне таптырып укытабыз. Беренче юлы Рамил Алисәне күрә. Кыз бик матур, әмма никтер сүзләре ялганып китә алмый, чөнки Рамил телефоннан сөйләшкән кыз белән янәшәсендәге кыз арасында уртаклык тапмый. Икенче юлы Алинә үзе килә, ул үзгәргән: йөзендә кимчелеге бар. Әмма Рамил ул кимчелеккә игътибар итмәскә тырыша, алар паркны каткат урыйлар, сөйләшәләр. Бу очракта автор кешенең тышкы матурлыгыннан бигрәк эчке матурлыгы мөһим булуы турында әйтергә тели. Җаның якын кешенең тышкы кимчелекләренә игътибар да итмисең, аның белән вакыт үткәне сизелми дә кала.

Алинә Рамилгә башта үзенең йөзендәге кимчелек турында әйтми. Үзе урынына очрашуга Алисәне җибәрә. Бу аның

оялчанлык, үз-үзенә ышаныч җитмәү, үзеңне ничек бар, шулай кабул итмәү сыйфатлары белән бәйле. Алинәнең Рамилгә язган иң соңгы хаты кызның үз гаебен танып, гафу үтенә белүе турында сөйли. Алинә образы аша автор һәр кеше ялгышырга мөмкин, әмма үз гаебен танырга, гафу үтенә белергә тиеш, дигән фикерне җиткерә.

Р. Галиуллинның «Сәлам» хикәясендә Рамил, Алинәнең үзе өчен бик кадерле һәм газиз булуын аңласа да, аның соңгы хатына җавабын җибәрми калдыра. Бу аның ялганны гафу итә алмавы турында сөйли.

Хикәянең идеясе — нинди ачы булса да, кеше һәрвакыт дөресен әйтергә тиеш.

Бу хикәяне өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Рөстәм Галиуллинның «Сәлам» хикәясендә Алинә ни өчен Рамилгә баштан ук дөресен сөйләмәгән дип уйлыйсың? Аның үз-үзенә ышанычын бетергән, аны кыюсыз, оялчан иткән сәбәп булды микән?* соравы укучыны уйланырга мәҗбүр итәчәк.

Шулай ук *Үзен күрмичә, кешегә гашыйк булырга мөмкинме?* проблемалы соравын куеп, укучыларны сөйләшүгә алып чыга алабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә.

*Беренче очрашуга ук Алинә үзе килсә, Рамил белән аларның мөнәсәбәте ничек булыр иде?* дигән сорауны биреп хикәяне башкача язып бетерергә тәкъдим итәбез.

Р. Галиуллинның «Сәлам...» хикәясен Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясе белән чагыштырып, «Күңелең матур булсын...» темасына 1—2 битлек сочинение язып килергә тәкъдим итәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Җанга сеңгән бишек җылысы (Повесть жанры үзенчәлекләре. Гомәр Бәширов. «Туган ягым — яшел бишек»);

Туган җир — тормыш мәктәбе (Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте);

Халык күңеленә уелган бизәкләр (Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда образлар системасы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү; туган җиргә мәхәббәт хисен аңлау, аның матурлыгын күрә белү; татар халкының тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләренә ихтирам хисе уяну, авыл кешесен олылау хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестеның эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген күрсәтә алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 41—93.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү.
2. «Балачак безгә нинди хатирәләре белән якын?» темасына әңгәмә үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты, бурычлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы өч дәрес Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестен һәм әдәби жанр буларак повесть жанрын өйрәнүгә юнәлдерелгән. Укучылар әлеге әсәр нигезендә повесть жанрына хас билгеләрне өйрәнәләр. Повестьта образлар, геройлар, сюжет төзелеше, вакыйгалар белән бәйле урын-вакыт төшенчәләрен ачыклыйлар. Геройларга хас сыйфатларны күрсәтә һәм бәяли алалар. Әсәрдә сәнгать чараларының вазифасын ассызыклыйлар. Әсәрнең темасын, идеясен, проблемасын билгелиләр.

Бу белемнәре нигезендә мөстәкыйль рәвештә повесть жанрының башка эпик әсәрләрдән (хикәядән) аермасын әйтә алалар. Повестьта күтәрелгән проблемага карата уйларын һәм сыйныфташлары карашына үз мөнәсәбәтләрен белдерә, фикерләрен дәлилләп бирә алалар.

Иң элек, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестена керешкәнче, укучыларга әсәрнең нинди жанрда булуын аңлатырга кирәк. Бу очракта алдагы дәресләрдә өйрәнелгән хикәя жанрыннан аермасын күрсәтергә була, чөнки повесть — хикәядән күләмлерәк чәчмә әсәр. Повестьта төп герой язмышының бер этабы сурәтләнә. Әсәрдә билгеле бер төркемгә (авыл кешеләре, эшчеләр, яшьләр һәм башкалар) хас тормыш гомумиләштереп бирелә. Ул бер яки берничә кеше язмышы аша ачыла. Сюжет вакыйгалары да хикәянеке кебек бер яки ике генә түгел, ул берничә тармаклы була. Бу вакыйгаларны хикәяләүче образы бергә туплап тора.

Повесть кискен каршылыклар, киеренке вакыйгаларны сурәтләүгә караганда гадәти тормыш-көнкүреш вакыйгаларын салмак агым белән хикәяли. Повестьта вакыт һәм урын ягыннан да чикләүләр юк диярлек. Ул хикәяләүченең фикер агымына буйсына.

Укучылар Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәренең шактый күләмле булуын, шуңа күрә дәресләрдә алар повестьның берничә өлешен генә укыячакларын аңларга тиешләр. Бер өлешен татар мәктәпләре укучылары гына укып анализлыйлар.

Алдагы мәгълүматларга таянып, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә повесть жанрына хас билгеләрдән хикәягә караганда аның зуррак булуын, хикәяләүче вакыйгаларны бербөтен итеп туплап торуын, вакыйгалар салмак хикәяләүгә корылганлыгы, берничә кеше тормышы (Гомәрнең гаиләсе) аша инкыйлабка кадәрге авыл тормышын ачып бирүен күрсәтә алабыз.

Повестьта аерым бер төркемгә хас сыйфатлар бер яки берничә кеше язмышында гәүдәләнә. Әсәрдә авыл крестьяннары тормышы Бәшир агай гаиләсе язмышы аша сурәтләнгән. Повестьның авторы Гомәр Бәширов һәм хикәяләүче Гумәр — бер үк кеше. Димәк, автор үзенең балачак хатирәләре турында бәян итә. Укучылар авторның үзе хакында язган әсәре автобиографик әсәр булуын искә төшерәләр.

Повесть төп герой язмышының билгеле бер этабын алып хикәяли, дидек. Укучылар Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә төп герой Гумәрнең балачагы сурәтләнүен билгелиләр.

Повестьтагы вакыйгалар инкыйлабка кадәрге авыл крестьяннары тормышы турындагы гомуми темага берләшә. Әсәрдә Гумәрләр гаиләсе хакында сөйләнгәннәр татар халкының өлкәннәргә карата хөрмәте, хезмәтне ярату, тырышлык, гаиләдә һәркемнең үз хезмәтен төгәл үтәве, крестьян, табигать белән аерылгысызлыгы, тормышының аңа бәйлелеге кебек сыйфатларын күрсәтә.

Повестьта бер яки берничә кеше ярдәмендә аерым бер төркем кешеләргә хас үзенчәлекләр ачыла, дигән идек. Биредә дә Гумәр образы аша автор авыл баласына хас сыйфатларны, аның рухи дөньясын, теләкләрен гәүдәләндерә.

Әсәрдәге образларга характеристика биргәндә, түбәндәгеләр ачыклана. Гумәр — 6—7 яшьләрдәге малай. Ул уенны яратып, рәхәтләнеп уйный. Бераз гына мактанчык та, көнләшә дә, үпкәли дә. Анда балаларга хас сыйфатларның барысы да бар. Өлкәннәр сүзен тыңлый, кушкан эшне яхшы итеп эшләргә тырыша, үзенең эше өчен җаваплылык тоя. Хайваннарны, табигатьне ярата, нечкә күңелле, хисчән булуы билгеләнә. Бу вакытта укучыларның күзаллавын үстерергә ярдәм итә торган *Әсәрдә Гумәрнең тышкы кыяфәте*

*сурәтләнмәгән. Сез аны ничек күзалдына китердегез?* кебек сорау бирә алабыз.

Бәшир агайны характерлаганда, Гумәрнең сүзләрен табып укытабыз. «Мин белә башлаган вакытларда, әти илле яшьләрдән узган киң җилкәле, таза гына бер кеше иде. Коңгырт кара чәчендә бер генә бөртек агы да юк, тавышы калын, вак тешләре ап-ак булып, тезелеп кенә торалар. Әмма шул матур тешләрнең җемелдәп яктырып китүен, әти кешенең рәхәтләнеп көлүен бәйрәм кебек әллә нидә бер генә, бик тансыкка гына күрә идек».

Гумәрнең апасы — Өммикамал авылда иң уңган кызларның берсе. Кул эшенә оста, өйдәге эшләрне тәртип белән башкара, энесен дә тәртипкә өйрәтә. Әти-әнисенә итагатьле. Авыл яшьләре арасында да дәрәҗәле, үткен дә, чая да. Авыл кызлары тыйнак, үзара тату, телгә дә оста, шаян да, бөтен эшкә дә өлгерәләр.

Хикәяләүче Гумәр кечкенә. Шул сәбәпле ул сөйләгән һәм бәя биргән көндәлек тормыш күренешләре бала күзаллавыннан чыгып тасвирлана. Ул катлаулы иҗтимагый-тарихи вакыйгалардан ерак тора. Шулай итеп, әсәрдә вакыйгаларны бергә җыеп тора торган уртак тема — авыл тормышы, андагы кешеләрнең рухи дөньясы, яшәү рәвеше.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шулай ук дәрестә без игътибар иттерергә тиешле нәрсә: «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә яз килүне каршылау, орлык чыгару вакыйгаларында кешенең табигать белән мөнәсәбәте чагылыш таба. Шулай ук халык ышануларында аның белән белән кешенең аерылгысызлыгы күренә. Авыл халкы табигать белән үзенең бердәмлеген тоеп яши, үзен табигать баласы буларак күрә, аңа сак караштa тора.

*Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә татар халкында үткәрелә торган кайсы бәйрәмнәр, йолалар турында укып белдегез? Аларның кайсылары бүген дә үткәрелә?* сорауларын биреп, укучыларны сөйләшүгә алып чыгабыз.

Укучылар Сабантуйның хәзер дә бәйрәм ителүен әйтәләр. Шулай ук авылларда сабантуйга бүләк тә (бирнә) җыялар. Хәзер инде бүләккә үз кулы белән чиккән сөлгеләр бирелми. Бәйрәмнәрдә авыл кызлары-киленнәренең уңганлыгын төр-

ле ярышларда сынаганнар, җитезлекләрен, көчлелекләрен күрсәткәннәр. Каз өмәсе дә бәйрәм төсен алган, эш беткәч, җырлы-уенлы хезмәт һәм ял бергә үрелеп барган, ди билгели ала укучылар.

Бу әсәрне өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә, сорауларга җавап бирергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Басулардан парта арасына кайтканда (Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте);

Моң белән уралган истәлекләр (Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте);

Иртә егет булган малайлар (М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестенда яшүсмер образы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — укучыларның социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне өйрәнүе һәм бәяләве; укуга омтылыш, аңа карата уңай мөнәсәбәт, тырышлык, авырлыкларга бирешмичә максатка ирешү, укытучыларга хөрмәт кебек хис-төшенчәләрнең асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның (сәнгати һәм уку текстлары, әдәби геройлар һәм башкалар) һәм күренешләрнең (әдәби юнәлешләр, әдәби-тарихи барыш этаплары) төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, нәтиҗә чыгару; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» әсәренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлекләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 93—117.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Үткән дәрестә өйрәнелгәннәрне сораштыру.

*«Кырык беренче ел» сүзтезмәсе сездә нинди ассоциация тудыра? Бу елда нинди вакыйга була? Кем ул кырык беренче ел балалары? Алар нәрсә күреп үскән?* сорауларын биреп әңгәмә оештырып була.

Танылган татар әдибе М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» дип аталган повестен язуын хәбәр итәбез һәм авторның бу әсәрнең язылу тарихын ачыклаган сүзләре белән танышырга тәкъдим итәбез.

«*Безнең балалык еллары дәһшәтле Ватан сугышына туры килде. Без балалык чорыбызда таякны ат итеп уйный алмадык, бәлки чын атлар җигеп колхоз басуында эшләдек... Бу китапны язар алдыннан мин үземнең бала чагымны, үсмер елларымны тагын бер кат күңелдән кичердем. Кешеләр безне бүген кайсы буынга гына кертеп сөйләмәсен, мин яшьтәшләрем исеменнән бер дә шикләнмичә әйтә алам: без — кырык беренче ел балалары. Әсәрнең исеме дә әнә шулай туды*», — дип язган Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы өч дәрес повесть жанрын өйрәнүне дәвам итүгә юнәлдерелгән. М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестеннан алынган өзекләр нигез булып тора. Бер өлешен татар мәктәпләре укучылары гына укып анализлыйлар. Укучылар повестьтагы өзекләрне анализлыйлар, әсәрнең темасын һәм идеясен билгелиләр, сорауларга җавап әзерли, персонажларның гамәлләренә бәя бирәләр, мөнәсәбәтләрен белдерәләр һәм портретын төзиләр, сюжеттан тыш элемент буларак, «лирик чигенеш» төшенчәсен беләләр һәм аны аерырга өйрәнәләр. Шул рәвешле, укучылар повесть төзелешендәге үзенчәлекне билгелиләр. Нәтиҗә буларак, караган спектакль буенча рецензия язарга һәм әдәби геройның портреты төзергә кушыла.

М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестенда авыр сугыш елларында гади авыл малай-кызларының Арча педучилищесында белем дөньясына кереп китүләре, аларда әдәбият-сәнгатькә тирән мәхәббәт уянуы сурәтләнә. Биредә укучыларның интернаттагы тормышы, дөньяны танып белергә, белемгә омтылулары, шул заман атмосферасы кызыклы хәлләр, төрле тормыш детальләре, үзенчәлекле һәм кабатланмас характерлар аша җанлы итеп гәүдәләндерелә.

Язучы башта бу юлның алар өчен җиңел бирелмәгәнлеген күрсәтә. Кайчандыр колхоз басуларында бәрәңге ташыган 15—16 яшьлек малайлар, педучилище коридорында авыл тузанын кагалар, иркенлекне сагыналар. Малайлар үзләре өчен ят, билгесез дөньяга килеп керәләр. Монда тәртип, барысы да үзгә. Училищеның үз законнары. Авылда иректә йөргән малалайларга башта училище тормышына ияләшергә җиңел булмый. «Көлтә йөге өстендә үгез көенә баруы нинди рәхәт иде! Ә монда кыймылдарга да шикләнеп утырасың», — дип уйлыйлар алар, училищега килгәч. Укучылар авыл мәктәбендә иркенлектән тулысы белән файдаланганнар. Шунлыктан күбесе тәмәке тарта, теләгән дәресенә керә, теләмә-

гәненнән кайтып китә. Һәм шундый иркенлектән соң училищеның уку атмосферасына эләккәч, алар башта куркып калалар. Шуның өстенә малайлар-кызлар училищеда үзләренә әлегә таныш булмаган фәннәр үзләштерә башлыйлар. Беренче адымнарны ясау, әлбәттә, бик авыр, ташлап китү уе белән янучылар да булгалый. Бу исә дәресләрдә ачык чагыла. Әлегә билгесез, таныш булмаган катлаулы эшне башлау һәркемгә дә авыр бирелә. Аның асылына төшенү бик читен. Шуңа күрә балаларның ризасызлыгы, вакыты-вакыты белән юк кына нәрсәләр алдында аптырап калулары яки ялгышып китүләре сурәтләнә. Шул малайлар өчен иң зур сынау итеп дәрес санала. Алар әле училище тормышына ияләшә алмыйлар. Мәсәлән, укулар башланган көнне беренче дәрес — рус теле. Укытучы эшнең җиңелен сайлый. Укучыларга ике баганага бишәр сүз язарга кушыла: беренче баганага — «б» авазына, икенче баганага — «в» авазына башланган сүзләр язарга. Ниһаять, зур газаплар белән ун сүз языылып бетә.

Әйе, ачлы-туклы йөргән малайларда башта уку теләге зур булмый. Ләкин артка юл юк, чөнки күбесенең педучилищега укырга килүләренең төп сәбәбе ул — ипи карточкасы. Геройлар һәрвакыт ашау турында уйлыйлар. Җыр дәресендә утырганда да, алар дәрес турында түгел, ә бары тик ашханәгә бару сәгатен көтеп утыралар. Шулай ачлы-туклы йөрүләренә карамастан, яшьләр, үзләренә бирелгән ипи нормасыннан өйдәгеләренә дә өлеш калдырырга тырышалар. Баязитова, Октябрь бәйрәменә үзенә бирелгән рулет белән өйдәге сеңелләрен сыйлыйм дип, салкын буранлы көндә ерактагы авылына юл тота. Әлтафи да, кышкы каникулга, үзе белән ипи карточкасына бирелгән онны алып кайтып, әнисенә тапшыра.

Балаларның сугыш турында уйлаулары да аңлашыла, чөнки сугыш аларны да читләтеп үтми. Ирләрне фронтка озаткач, колхоздагы бөтен эш өлкән буынга, хатын-кызлар һәм яшүсмерләр җилкәсенә төшә. Алар җаннарын фида кылып тырышалар: сугышчыларга азык-төлек, җылы киемнәр озаталар.

Шулай да М. Мәһдиевнең геройлары авыр эшләр эшләсәләр дә, ачлы-туклы йөрсәләр дә, уен-көлкегә дә вакыт табалар. Кичен ут кабынуга, тулай торакта төрле уеннар,

бәхәсләр, кызык сөйләүләр китә. Малайлар шашка, шахмат уйныйлар, тыелганга карамастан, карта да сугалар. Сәнгать белән дә бик дус булып чыгалар.

Повесть геройлары — яшүсмерләр Бөек Ватан сугышы вакыйгаларында турыдан-туры катнашмыйлар. Ләкин аларның балалык еллары дәһшәтле сугыш вакытына туры килүе күңелләренә «Ватан язмышы дигән олы хис»нең кереп урнашуына сәбәп була.

Повесть жанры кысаларында персонаж һәм лирик чигенеш төшенчәләрен үзләштерү дә күздә тотыла.

Персонаж (лат. — йөз, шәхес, маска) — әдәби әсәрдәге вакыйгаларда катнашучының гомуми исеме. Персонажлар төп, ярдәмче, эпизодик төрләргә бүленә. Нәкъ әлеге мәгънәдә әдәби герой төшенчәсе дә кулланыла.

Персонаж, әдәби герой төшенчәләре — синонимнар. Еш кына персонаж ул — кеше образы. Шулай ук әдәби әсәрдә табигать күренешләре, хайваннар, үсемлекләр, кош-кортлар, җансыз предметлар да сөйләшә һәм нәрсәдер эшли ала. Димәк, алар да персонаж була.

Алга таба М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестенда персонажларны барлап, бер персонажны сайлап алып, аңа телдән характеристика бирергә тәкъдим итә алабыз.

Персонажга характеристика бирүнең якынча планы.

1. Әсәрнең образлар системасында персонажның урыны (төп яки ярдәмче).

2. Социаль һәм материаль хәле.

3. Тышкы кыяфәте.

4. Кызыксынулары һәм гадәтләре, омтылышлары.

5. Хисләр өлкәсе (Әйләнә-тирәдәгеләргә нинди мөнәсәбәттә? Эчке кичерешләре нинди?)

6. Авторның персонажга мөнәсәбәте.

7. Әсәрдә геройның нинди сыйфатлары ачыла:

а) портрет ярдәмендә;

ә) автор характеристикасында;

б) әсәрдәге башка геройлар характеристикасы аша;

в) биография ярдәмендә;

г) эш-гамәлләре аша;

д) сөйләм характеристикасы аша (Ничек сөйләшә?);

е) башка персонажлар белән янәшә куелып;

ж) әйләнә-тирәдәге мохит аша.

8. Җәмгыятьтәге нинди проблема авторны әлеге образ тудыруга этәргән? соравына җавап.

Үзләштерелергә тиешле алдагы теоретик төшенчә — лирик чигенеш.

Лирик чигенеш — сюжеттан тыш элемент. Автор, сюжетны тасвирлаудан читкә китеп, теге яки бу вакыйгага карата үзенең фикерләрен, уйлануларын җиткерә. Ул әсәрдә укучыларга мөрәҗәгать, истәлек яки хатирәләр буларак бирелә. Димәк, лирик чигенеш — авторның лирик, фәлсәфи, әхлакый, автобиографик һәм башка характердагы сүзләре, уйланулары.

Мисал итеп, әсәрдән түбәндәге өзекне китерәбез.

*Шулай. Безгә дә яшәргә һәм бурычыңны үтәргә кирәк иде.*

*Әйе, яшәргә кирәк иде.*

*Ах син, җил!*

*Син һич тә агачларны селкетмисең. Син бары тик телеграф чыбыкларына кагыласың да шомлы итеп сызгырасың. Аязга булса да, яңгырга булса да сызгырасың.*

*Син миңа яшьлегемне сөйлисең...»*

Калган мисалларны укучыларның үзләреннән таптырабыз. Мәсәлән,

1. *Сәнгатьнең тамак туклыгы яки ачлыгы белән бернинди уртаклыгы юк. Сәнгать — мөстәкыйль, ул ашказаны, корсак фәлсәфәсеннән югары. Аның законнары мөстәкыйль, ул, теләсә, суыкны да, ачлыкны да буйсындыра. Чөнки ул — йөрәк эше.*

2. *Мәрхәмәтле җир! Нигәдер мин синең шундый томанлы, буранлы, яңгырлы көннәреңне яратам. Син ул вакытта миңа ышанычлырак тоеласың. Эссе, коры көннәреңдә аяк асты ярылган, өермәле, коры җәй минем исемә төшә.*

Бу әсәрне өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Бу сугыш кешеләрне генә түгел, бөтен тереклек дөньясын әллә нишләтте, дигән сүзләрне ничек аңлыйсыз? Су-*

*гыш нәрсәне үзгәртә?* сораулары ярдәмендә укучыларны сөйләшүгә алып чыгабыз.

Бүгенге заман яшүсмерен һәм сугыш чоры яшүсмерен чагыштырырга тәкъдим итеп була.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә, сорауларга җавап бирергә.

Шулай ук М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повестеннан алынган өзекләр буенча 2012 елдан Кәрим Тинчурин театрында куела торган спектакльне карарга тәкъдим итеп, укучылардан хис-кичерешләре белән уртаклашып рецензия язарга тәкъдим итеп була.

Рецензиянең якынча планын да бирәбез:

1. Спектакльнең исеме, режиссёр, театр (төп мәгълүмат), куелу датасы.
2. Әсәр/пьеса авторы һәм аны сәхнәгә куючы турында мәгълүмат.
3. Әсәрнең сюжеты, төп эпизодлар.
4. Актерлар уенын бәяләү.
5. Автор күтәргән төп проблема һәм аның актуальлеге.
6. Спектакльне караганнан соң туган хисләр.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Үткән материалны кабатлау. Контроль эш.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; белемгә омтылышның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне системага салып гомумиләштерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 41—117.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар алдагы сөйләшүдән әлеге дәреснең кабатлау, үткәннәрне искә төшерү дәресе икәнлеген билгели алалар.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Әлеге дәрестә өйрәнелгән зур тема буенча нәтиҗәләр чыгарыла. Укылган әсәрләр искә төшерелә, аерым әсәрнең темасы, төп фикере искә төшерелә. Бирелгән өзекнең кайсы әсәрдән булуын ачыкларга һ.б. биремнәрне үтәргә була.

Биремнәрнең бик төрле булуы үтелгән материалның иң әһәмиятле өлешләрен укучының хәтеренә сеңдерергә булышырга тиеш. Мөһим уй-фикер, укучыларның хәтерендә саклансын өчен, дәфтәргә яздырырга мөмкин. Бу эш шулай ук нәтиҗәләрне бер җепкә төзергә, шулар аркылы зуррак гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә.

Дәреснең икенче өлешендә теманы өйрәнү барышында үзләштергән белемнәр нигезендә контроль эш эшләтәбез. Электрон дәреслектә тәкъдим ителгән тестны эшләтеп була.

**VI. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Өйгә таба юл якынмы? (Роман жанры. Ибраһим Гази. «Онытылмас еллар»);

Балконлы йортта кемнәр яши? (Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романы);

Ерак Казанга таба юл тотып (Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романының проблематикасы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; үз-үзеңә ышаныч хисенең асылына төшенү, теләктәшлек итү, бердәмлек, ихтыяр көче төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, эшне планлаштыру, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, тыңлап аңлау, аңлап уку, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, нәтиҗә чыгара, гомумиләштерүләр ясый белү; фикерләрен төгәл һәм ачык итеп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — И. Газиның «Онытылмас еллар» романының эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 4—28.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру. Мотивлаштыру.**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру

**II. Актуальләштерү.**

*Ничек уйлыйсыз, нинди еллар онытылмас була икән?* соравын биреп укучыны уйландырабыз, әңгәмәгә алып керәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

*Укучылар, ничек уйлыйсыз, бүген дәрестә без нәрсә турында сөйләшәчәкбез икән?* дип сорап, дәреснең максатын билгеләтәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

Алдагы өч дәрестә И. Газиның «Онытылмас еллар» романын өйрәнү күздә тотыла. Әсәрнең сюжетын билгеләү, аның нигезендә сорауларга җавап бирү, темасын, идея-проблематикасын билгеләү, геройларны характерлау романны тирәнтен аңлау-төшенүгә китерәчәк. Әлеге тема кысаларында, әдәби-теоретик төшенчә буларак, роман белән танышу күздә тотыла. Роман жанры хасиятләрен укучылар Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» әсәренә нигезләнеп үзләштерәләр.

Иң элек тема башында бирелгән проблемалы сорау турында уйландырып, укучыларда роман герое турында кызыксыну уятабыз.

Укучылар роман төшенчәсе белән очраша. Шуңа күрә әсәрне укырга керешкәнче, аңа билгеләмә бирү отышлы булыр.

Роман — зур күләмле эпик әсәр. Анда геройлар саны да чагыштырмача күбрәк, шуңа бәйле рәвештә вакыйгалар да күбәя. Романда геройларның теләк-омтылышлары, язмышы, тирә-як белән мөнәсәбәтләре сурәтләнә, алар аша кеше һәм җәмгыятькә бәя бирелә.

Романның сюжеты катлаулы. Төп сюжет сызыгыннан тыш, күпсанлы ярдәмче сюжет сызыклары була. Кайвакыт аерым кешеләрнең язмышлары турында хикәяләп кенә бирми, ә бәлки билгеле бер чор, җәмгыять тормышы колачлап алына. Сюжет дәвамында герой үзенең халәтен яки дөньяга карашын үзгәртә.

Романның түбәндәге төрләре билгеле: тарихи роман, сәяси роман, хәрби роман, детектив роман, документаль роман, мәхәббәт романы, интеллектуаль роман, фантастик роман, фәлсәфи роман, биографик роман, автобиографик роман, маҗаралы роман.

Романдагы вакыйгалар җәмгыятьне төрле яктан күрсәтә, герой бу вакыйгаларда катнашып, аларны үзара бәйли, шул рәвешле сюжет туа.

Без өйрәнә торган әсәрнең үзенчәлеге — аның трилогия булуында. Бу очракта аңа аңлатма биреп китү урынлы:

Трилогия — сюжет, геройларның бердәйлеге белән бәйле өч кисәктән (әсәрдән) торган роман яки драма әсәре.

Шулай итеп, И. Газиның «Онытылмас еллар» романы өч китаптан гыйбарәт. Беренче китап «Малай чак» дип аталып, 1949 елда языла. Икенче китап 1964 елда иҗат ителә һәм ул «Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт» дип исемләнә. Өченче — «Канатланыр чак» дип аталган китап 1968 елда языла. Шунысын да өстәп әйтәбез: трилогия кисәкләре эшләнешләре, язылышлары ягыннан бер-берсенә охшамаганнар. Китап өлешләренең исемнәренә карап, романда сүз нәрсә турында баруын укучылардан фаразлатырга мөмкин. Шуннан соң аңлатма бирәбез: беренче китапта әсәр герое Хәлимнең балалык еллары олы вакыйгалар арасына кереп китеп үсә һәм тулылана. Икенче китапта алгы планга иҗтимагый-сәяси вакыйгалар чыга. Өченче китап тулысынча Хәлимгә бәйләнешле хәл-күренешләрдән тора һәм яшь кешенең дөньяны, тормышны аңлавындагы үсешне тасвирлый.

Әсәр үзенчәлекле образлар аркылы бөтен бер тарихи чорны — XX йөзнең беренче чирегендә һәм шунда булып узган вакыйгаларны күрсәтә. Бу авылдагы Беренче бөтендөнья сугышы тудырган бөлгенлекләр, Февраль буржуаз революциясе, Октябрь революциясе, Гражданнар сугышының беренче еллары.

Дәреслектә роман кыскартылып, өч өлешкә бүлеп бирелә (дәресләрне шул өлешләргә бәйле оештырабыз). Һәр өлештә әсәрнең төп герое Хәлимнең төрле чорга караган балачагы, яшүсмер вакыты белән бәйле вакыйгалар бәян ителә. Хәлимнең төс-кыяфәтен билгеләү өчен, дәреслектә күрсәтелмәгән тулы романнан алынган сыйфатнамә белән таныштырабыз. «Хәлим ябыграк булса да, эре сөякле, нык тәнле, каты куллы малай», «башкаларга буйсынудан бигрәк, үзе кеше өстеннән атаманчылык итәргә ярата» һ.б.

Дәреслектә тәкъдим ителгән беренче өлештә Хәлимнең балалар йортыннан кайтып китеп өенә ашыгуы тасвирлана. Бу вакытта тексттан Хәлимнең юлын тасвирлаган урыннарны таптырып укытырга, Хәлим кичергән хисләрне ачыкларга

кирәк. Аның өйгә таба юлы бер дә җиңел булмый. Ләкин ул бертуктамый атлый да атлый, аяклары йөрмәс хәлгә килгәндә дә барудан туктамый. Аның туган авылын, туган йортын, газиз әнисен күрәсе килә. Укучылар бирелә үк Хәлимнең ихтыяр көчен, аның үҗәтлеген, максатчанлыгын күреп билгеләр. Хәлимгә теләктәшлек итеп, аның тизрәк әнисе янына кайтып җитүен телиләр. Ни аяныч, Хәлим авылга кайтып җиткәндә, аны тәрәзәләре кадакланган, ишектә йозак эленеп торган туган йорты каршы ала. Бу вакытта әлеге күренешнең Хәлимгә ничек тәэсир итүен билгеләгән җөмләне таптырып укытабыз. «Хәлим багана кебек катты да калды» дигән җөмләдә күпме уй, күпме хис яшерелгәнлеген билгеләү өчен, аларны укучылардан фаразлатабыз. Гомумән, әсәр буена И. Гази өчен иң мөһиме — образның эчке табигатен ачу, аның хис-кичерешләрен сурәтләү. Әнисенең үлемен ишеткәч, Хәлимнең үз-үзен тотышын билгеләү дә бик мөһим. Бу өлешне анализлауда *Ни өчен мәчеләре Хәлимне танымый? Хәлим ни сәбәпле әти-әнисен күз алдына китерә алмый? Ни өчен аның өйләреннән тизрәк чыгып китәсе килә? Нинди сәбәпләр аркасында бакчалары ят булып тоела? Бакча күренеше нәрсәгә ишарә булып тора? Хәлим бакчада йөргәндә, нәрсәне аңлый? Ялангач бакчада калган бердәнбер яшел яфрак нәрсәне символлаштыра?* сораулары һәм дәреслектә бирелгән сорау-биремнәр ярдәмгә килә.

Хәлим, бакчада йөргәндә, үзенең ятим, ялгыз калганын, әти-әнисенең беркайчан да әйләнеп кайтмаячагын аңлый. Әсәр героеның ятимлеген, ялгызлыгын чагылдырган образларны барлыйбыз: шәрә бакча, ятим алмагач, ятим чия, карлыган, буш кош оясы. Шул рәвешле, Хәлимнең халәте белән тәңгәллекләр уздырабыз.

Юл образына аерым игътибар итеп, әсәрдә сурәтләнгән заманга бәя бирәбез. Бу — алга таба Таифә нәнәй әйткән сүзләрдә дә чагылыш таба.

Икенче дәрестә өйрәнелә торган өлештә Хәлимнең шәһәргә килеп, балалар йортының елга буендагы балконлы йортка күчеп яши башлаган чоры тасвирлана. Балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең ничек яшәүләрен, нәрсә белән шөгыльләнүләрен, һәм кызыксынуларын күрәбез. Әсәр геройла-

ры белән булган вакыйгалар аларның яшәү рәвешен, төс-кыяфәтен билгеләргә, холкын ачыкларга ярдәм итә.

Өченче өлештә Хәлимнең Казанга китүе турында сөйләнә. Биредә аның уй-кичерешләре белән беррәттән, теләк-омтылышларына да тукталабыз. Казанга китүенең сәбәпләрен ачыклыйбыз. Башкаларның Хәлимгә мөнәсәбәтен ачыклау максаты белән, танышлары белән саубуллашып йөрүе турындагы урыннарны таптырып укытабыз. Аерым игътибарны Хәлимдә Казанга җитәрәк туган хис-кичерешләргә юнәлтәбез, аларга бәя бирәбез.

**V. Яңа белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тормышта үз урыныңны табу темасына әңгәмә оештыру отышлы булыр.

Романда бирелгән балалар йортында тәрбияләнүчеләр образын характерларга кушып була. *Әлеге җыелма образ нәрсә белән үзенчәлекле?* соравын биреп, укучыларны сөйләшүгә алып чыгабыз.

Өченче дәрестә йомгак ясап, тема кысаларында өйрәнелгәннәрне искә төшерәбез. Татар мәктәпләрендә әлеге биремгә аерым дәрес каралган.

Бу вакытта әсәр буенча сорауларга җавап бирү, өй эше итеп бирелгән хикәяне уку, нәтиҗәләр ясау, электрон дәреслектәге тестны эшләтү кебек эш төрләре кулланыла ала.

**VI. Өй эшен бирү.**

Әсәрне укырга, әчтәлеген сөйләргә, геройларга характеристика бирергә һ.б.

Татар мәктәбендә «Хәлим тормышта үз урынын таба алырмы?» соравына җавап бирү рәвешендә әсәрнең дәвамы итеп кечкенә хикәя язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яшәү яме нәрсәдә? (Драма жанры. Туфан Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр»);

Рухы нык җаннар берешми (Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә көчле кеше образы);

Кеше китә — җыры кала (Иҗади эш: «Кеше китә — җыры кала» темасына сочинение).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне өйрәнүе һәм бәяләве; тормышка гашыйк булуның әһәмияте, яшәү мәгънәсе, яшәү һәм үлем турында аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасының эчтәлеген белү, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 29—60.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.
2. «Тормыш яме, тәме нәрсә ул?» темасына әңгәмә оештыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Драма жанрын өйрәнү дәресләрендә укучылар Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында халкыбызның

физик һәм рухи байлыгын үзендә туплаган, сокландыргыч уңай сыйфатларга ия булган Әлмәндәр белән таныша. Әсәрдә юмор, шаяру аша татар милләтенең тормышка ябышып ятуы, яшәүчәнлеге, авырлыкларны кичерә белүе күрсәтелә. Яшьләрне аңлый белүе, холкының җиңел булуы, шаян рухы Әлмәндәр картны тирә-юньдәгеләр өчен кадерле, кирәкле картка әйләндерә. Әлмәндәр тормышны ярата, безне дә дөрес һәм мәгънәле яшәргә чакыра.

Бу дәресләрдә укучылар шулай ук әдәбият теориясеннән драма, конфликт, диалог, монолог, ремарка, реплика төшенчәләрен аерырга өйрәнәләр. Нәтиҗәдә Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасы нигезендә «Кеше китә — җыры кала» исемле инша язачаклар һәм өзекне сәхнәләштерәчәкләр.

Укучылар өлешләп әсәрнең эчтәлеген үзләштерә баралар.

Әсәрнең пролог өлешендә Газраил Әлдермеш авылындагы Әлмәндәр картның үләргә тиешлеген искәртә һәм, моны тормышка ашырыр өчен, Әҗәлне Әлдермеш авылына җибәрә. Аны бирәү дә карт дип әйтми, чөнки Әлмәндәр бу сүзне яратмый. Авылда эшкә чакырмаганы өчен бригадирга ачулана. Хәмдебану белән шаярып сөйләшә. Мансур һәм Өммия белән тарткалашып ала. Улы Искәндәрне шелтәләп куя, Илсурны бал белән сыйлый.

Әлмәндәр Әҗәлгә балалары һәм оныкларына соңгы сүзләр әйтеп калырга теләвен җиткерә. Үзенең үләсен белсә дә, яхшылык эшләп калырга ашыга.

Әсәрдә Әлмәндәр образы ярдәмендә Т. Миңнуллин бүгенге татар авылының гадәти аксакалы образын тудыра. Әлмәндәр картка характеристика биргәндә, аның нинди генә авыр шартларда яшәвенә һәм нинди генә югалтулар кичерүенә карамастан Әлмәндәр картның шаян, көр күңелле булып калуын билгелибез. Әлмәндәр — тормыштан туя белмәс милли герой, татар рухлы, дәртле, эш сөючән, тапкыр, зирәк картның үлемсез образы. Ул бик күп сугышларда катнаша, дүрт улын югалта, төпчеге Искәндәр яраланып, инвалид булып кайта. Яраткан хатынын югалту да аның рухын сындырмый. Әлмәндәр картның дуслары күп, ул һәр эшне күңел биреп эшли, тормышны ярата. Аның тирәсендә булган һәр

кеше карттан энергия ала. Аның күңелендә матур яшьлек хатирәләре, мәхәббәте, керсез хисләре сакланган. Ул шулар белән юанып яши. Әлмәндәр карт үзенең хөр күңеле, шаянлыгы, башкаларны елмайта алуы белән бик бәхетле. Кеше күңелен ачуны бик зур игелек дип исәпли. Әлмәндәр үлем алдында да сер бирми. Үзенә авыр булса да, һаман шаярта. Хәсрәтен дә, чирен дә берәүгә дә сиздерми. Вакыйгалар барышында Әҗәл белән Әлмәндәр конфликты бераз йомшара. Моның сәбәбе — Әлмәндәрнең хәйләсе. Әҗәл, аңа сокланып, бераз вакыт бирә. Әлмәндәр авыр хисләрен барыбер җиңә. Аның Әҗәл артыннан китүен сизми дә калалар. Әлмәндәр җиңелә, ләкин җиңүче булып җиңелә. Автор Әлмәндәр образы аша халыкның җан җылысын, шаянлыгын-наянлыгын, уен-көлкегә хирыслыгын, мәхәббәтле, намуслы һәм горур булуын, башка бик күп уңай сыйфатларын күрсәтә.

Хәмдебану карчык — Әлмәндәр картның авылдашы, аңардан күпкә яшь булганга, аны Әлмәндәр абзый дип атый. Хәмдебануның балалары юк, ире сугышта үлгән. Ялгыз калса да, башка кияүгә чыкмаган. Әлмәндәр аны башкаларга да димләп карый, соңрак үзе дә өйләнмәкче була. Әлмәндәрнең шаярып сөйләшүен ул чынга ала, аңа аның хәтере кала. Әлмәндәр Хәмдебануның күңелен күтәрү өчен шаярта. Хәмдебану — акыллы, горур хатын, әсәр ахырында Әлмәндәр картны аңлап гафу итә.

Искәндәр — Әлмәндәрнең сугыштан исән-сау кайткан улы. Аның дүрт абыйсы да һәлак була. Ул сугыштан нык яраланып кайта. Таякка таянып кына йөри. Әтисе яше буенча улыннан күпкә картрак булса да, күңеле һаман да яшь, ә улының күңеле карт. Әтисенең ихтыяр көченең чиге юк, ә улы сынган, төшенкелеккә бирелгән. Искәндәрне Әлмәндәр карт белән чагыштырсак, ул күпкә көчсез. Ул үзенең авыруы белән ризалашкан, тормышында бернәрсәне дә үзгәртергә теләми. Искәндәр әтисе белән бәхәсләшә, әтисен юатасы урынга, Әлмәндәр карт улын юатырга мәҗбүр. Әлмәндәр картның тормыш фәлсәфәсе матур, ә Искәндәр төшенкелеккә бирелүчән. Шуның аркасында да алар арасында конфликт барлыкка килә. Соңыннан гына Искәндәр әтисенең хаклы икәнлегенә инана. Әсәр ахырында аңа әтисенең ярдәме ае-

руча файдалы була: аның боеклыгы, яшәүгә битарафлыгы югала.

Өммия — Әлмәндәр картның килене, Искәндәрнең хатыны. Ул да олы яшьтәге хатын. Әлмәндәр татар гореф-гадәтләренә хас булганча, килен хезмәтен күрергә тели: я ул аңа чәй ясап чыгарырга, я бал алып килергә куша. Өммиягә ике картны карау җиңел түгел. Әлмәндәрдән кала аның авыру ире дә бар. Әлмәндәр аны үзенең яшенә караганда яшь дип аңа эш кушарга ярата. Бу исә Өммиягә ошамый. Әлмәндәр киленен бик ошатып җиткермәсә дә, барыбер аны хөрмәт итә. Аларның бер-берсе белән әйткәләшүендә ярату, хөрмәт сизелә. Әсәр ахырында бу конфликт чишелә. Әлмәндәр аның сабыр булганын искәртеп үтә.

Әҗәл — фәрман үтәүче, җансыз, хиссез бер зат. Кешеләрдәге яшәү теләгенә Әҗәл таң кала. Бер караганда, рухи гомере мәңгеләшкән кеше Әҗәлнең үзенә дә ошый. Әҗәлнең хыялы: аның кешеләрчә яшәп карыйсы, алар кичергән хисләрне кичерәсе килә башлый. Әҗәл бер үк вазифаларны башкарудан туя, ул гөнаһлы яшәүнең дә үз кызыгын таба, хәтта аның өчен җавап бирергә дә әзер кебек. Әҗәлдә бу картның тормышны яратуына соклану хисе уяна. Әҗәлгә Әлмәндәр ошый, аның Әлмәндәрне алып китәсе килми башлый.

Яшьләр образы — Гөлфирә, Мансур һәм Илсур. Гөлфирә — Әлмәндәр картның оныкчыгы. Әлмәндәр аны бик ярата, чөнки Гөлфирә аның хатыны Йөзембикәгә охшаган. Аңа карап юаныч ала. Мансур — Гөлфирәгә гашыйк егет. Әлмәндәр Мансурга да үзенең киңәшләрен бирә, аралары бозылган яшьләрне дуслаштыра. Илсур образы әсәргә юкка гына кертелмәгән. Ул — Әлмәндәр карт урынына каласы алмаш. Илсур әлегә бу бабайны алыштыра алмый, ләкин киләчәктә ул да Әлмәндәр карт кебек булыр: авыруларны терелтер, елаганнарны юатыр. Аның Әлмәндәр карт кебек җор телле, оптимист кеше булып үсүенә шик юк.

Сугышта дүрт улын югалту — Әлмәндәр карт өчен зур фаҗига. Әлмәндәр бу югалтуны яшьләр, балалар белән аралашып җиңеләйтә. Сугыштан кайтмаган дүрт улының да юкка гына бу дөньяга килеп китмәгәннәрен раслау өчен дә, ул үзеннән соңгы гомере, тормышы, кешелек язмышы ту-

рында уйлана. Үзенең дәвамын ул яшьләрдә күрә, шуңа күрә алар белән рәхәтләнеп аралаша, шаяра, балаларга җырлар өйрәтә. Әлмәндәр авыр, катлаулы язмыш кичереп, тормышка мәхәббәтен бер генә минутка да киметми, һаман-һаман яшәргә омтыла һәм шул какшамас омтылышы белән тирә-юнендәге кешеләрне, яшен-картын дәрләндереп, алга ияртеп бара.

Әлмәндәрдә яшәү теләге бик көчле. Ни кызганыч: мондый сыйфатлар теләсә кемгә бирелми. Ул, беренчедән, кешенең табигатенә салынган була, икенчедән, авыр сынаулар аша ныгытыла. Бер караганда, рухи гомере мәңгеләшкән кеше Әҗәлнең үзенә дә ошый төшә. Тормышка бөтен тамырлары белән гашыйк Әлмәндәр белән очрашкач, Әҗәл үзе дә аптырап кала. Әҗәл булып Әҗәл дә: «Сез адәмнәр бәхетлеләр, үлә аласыз», — ди.

Чыннан да, Әлмәндәр — бәхетле карт. Ул матур итеп яшәгән, кешеләрне кимсетмәгән, берәүгә дә начарлык эшләмәгән. Авыл халкы аны ярата, хөрмәт итә. Ул — авылда бөтен кешенең бабасы. Бу — зур бәхет.

Әлмәндәр картның теләкләре — улына ярдәм итү, авырып, урын өстенә ятмас өчен, нәрсәдер эшләү (дача салу), яшьләрнең мөнәсәбәтләрен яхшырту, Хәмдебануның күңелен күтәрү, авылдашларына кулыннан килгәнчә ярдәм итү. Ул боларның барысын да эшли. Теләгенә ирешә дип әйтергә була. Ләкин Әҗәл белән бергә мәҗбүрилек килеп керә. Ул үләргә тиеш. Әлмәндәр моннан берничек тә котыла алмый, чөнки кеше гомере үлем белән чикләнгән. Бу проблема Әлмәндәрнең үлеме белән чишелә.

Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында әйтәсе килгән фикере бик тирән — милләтебез язмыш тарафыннан нинди генә сынауларга дучар ителмәсен, аның күңелендә хөрлек һәм шаяру, тапкырлык һәм күңел көрлегенә урын бар. Туфан Миңнуллин халыкның аеруча типик характер үзенчәлекләреннән җорлыкның, юморның гаять әһәмиятле нәрсә булуын тирәнтен аңлаган, тойган һәм шуны расларга омтылган. Әлеге юмор исә турыдан-туры халыкның тапкырлыгы, хикмәтлелеге, фәлсәфи фикере, тормыш тәҗрибәсе белән дә тыгыз бәйләнештә тора.

«Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә авторның халкы белән горурлануы, аны яратуы, аңа соклануы күренә. Һәм ул безне дә шундый булырга чакыра. Язучының идеясе: яшәү ул — үзеңне хуҗа итеп тою, башкаларның бәхете өчен җаваплы булу.

Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е — драма әсәре, ә драмага үзенчәлекле сыйфатлар хас. Аның сәхнә өчен язылуы тышкы төзелешенә йогынты ясый.

Бу дәресләрдә укучылар әдәбият теориясеннән драма, конфликт, диалог, монолог, ремарка, реплика төшенчәләрен аерырга өйрәнәләр.

Драма сәнгатьнең ике төренә карый: әдәбият һәм театр. Сәхнәдә уйнау өчен язылган драма башка әдәби төрләрдән персонажларның репликалары һәм автор ремаркалары рәвешендә тәкъдим ителүе белән аерылып тора. Драма — матур әдәбиятның бер төре, бердәм хәрәкәт тәшкил иткән вакыйга-күренешләр тормышчан конфликт аша диалог һәм монологларда ачыла торган сәхнә әсәре. Ул пәрдәләргә һәм күренешләргә бүленә.

Драма төренең өч төп жанры билгеле: драма, комедия, трагедия. Шулай ук трагикомедия, мистерия, фарс, водевиль, музыкаль драма (мелодрама), моңсу комедия кебек жанрлары да аерылып чыга.

Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре ике пәрдәдән һәм дүрт күренештән тора. Сәхнә әсәре. Вакыты һәм күләме чикле. Әсәрдә геройлар үзара сөйләшә. Репликалар автор ремаркалары белән баетыла.

Драматург, әсәрен язганда, капма-каршы сөйләшү, ягъни диалоглардан файдалана. Әсәрнең башында ук катнашучыларның исемнәре, аларга карата аңлатмалар бирелә.

Монолог — драмада катнашучы персонаж тарафыннан әйтелгән сүзләр. Персонаж башкаларга яки үзенә мөрәҗәгать итеп сөйләргә мөмкин.

Диалог — ике һәм аннан да күбрәк кеше арасында әйтелгән сүзләрне (репликаларны, сораулар һәм җаваплар) телдән яки язма сөйләшүнең әдәби формасы.

«Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә диалог һәм монологка тексттан мисал китерергә кушабыз.

Драма әсәрендәге диалогларда персонажларның сөйләме бирелә. Бу сүзләр реплика дип атала. Укучылардан тексттан репликага мисаллар эзләтәбез.

Драма әсәрендә персонажларның сөйләмен, пәрдә-күренешләрне искәрмәләр ачыклап бара. Алар, ягъни ремаркалар ярдәмендә без вакыйгаларның кайда һәм ничек барганлыгын, персонажлар турында иң кирәкле мәгълүматларны беләбез. Ремаркаларның төп функциясе — авторның фикерен чагылдыру. Шулай ук тексттагы ремарка булган өлешләрне таптырабыз.

Бу әсәрне өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренең көче нәрсәдә?* проблемалы соравын куеп, укучыларны уйлануга этәрәбез һәм ахырдан нәтиҗә ясатабыз: Хәзерге дөньяда начарлыклар, ямьсез күренешләр бик күп. Бу яманлыклар безне басып алмасын өчен, китаплар укыйбыз, спектакльләр, кинофильмнар карыйбыз, сынлы сәнгать әсәрләре белән танышабыз. Алар барысы да безгә яшәргә көч бирә, тормышның матур якларын тоярга өйрәтә. Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрен укыгач, 91 яшьлек картта яшәү омтылышын күреп, үзеңнең тормышка карашыңны үзгәртәсең. Тормыш нинди матур, анда синең әти-әниең, туганнарың, дусларың бар! Алар сине ярата, син каядыр китсәң, сагынып көтеп ала. Күктәге кояш сине җылытып, нурын сибә, ай-йолдызлар тормышыңа серлелек өсти. Кошларның сайравы, елгаларның тыныч кына агуы сиңа тән сихәте, күңел тынычлыгы бирә. «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренең көче — кешене яшәргә, тормышның кадерен белеп яшәргә өйрәтүдә.

*Яшәү мәгънәсе нидә?* соравын тәкъдим итәбез, укучыларның фикерләрен тыңлыйбыз һәм нәтиҗә ясатабыз: Т. Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә 91 яшьлек карт — Әлмәндәр — образын тудырып, «Кеше ни өчен туа, яши, эшли, балалар үстерә һәм үлә?» дигән сорауларга җавап эзли. Кеше үзенең үткән тормышы өчен үкенергә тиеш түгел. Аның яшәеше нинди булырга тиеш? Ул нәрсәгә омтылырга,

ә нәрсәне кире кагарга тели? Кеше тормыш матурлыгын күрә белергә тиеш. Әгәр дә без матурлыкка игътибар итмәсәк, безнең рухыбыз ярлылана. «Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?» дигән сорауга без җавапны Әлмәндәр карттан алдык. Ул безне матур, тәртипле яшәргә, кешеләргә начарлык эшләмәскә, авырлыкларны җиңәргә үзеңдә көч табарга, кешеләргә игелек күрсәтергә, авыр вакытларда ярдәм итәргә, тормыштан канәгать булып, шатланып-көлеп яшәргә өйрәтте. Кеше бервакытта да үкенеп яшәмәсен иде. Аның тормышы гел үсештә булса, ул эшеннән канәгать, балалары, туганнары исән-сау булса, андый кешенең яшәү мәгънәсе камил санала. Һәм ул шуңа омтылырга да тиеш. Язучы яшьләрне аңлый белүче, җиңел холыклы, шаян рухлы картны тирә-юньдәгеләр өчен кадерле, кирәкле картка әйләндерә. Әлмәндәр тормышны ярата, безне дә дөрес һәм мәгънәле яшәргә чакыра.

«Үткән гомер әрәм түгел, әрәм үткән гомер әрәм» дигән татар халык мәкале Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасындагы Әлмәндәр картка капма-каршы мәгънәдә. Туфан Миңнуллин Әлмәндәр образы аша халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен, иң матур сыйфатларын — хезмәтне ярату, өлкәннәргә хөрмәт, буыннар арасында рухи бәйләнеш, яшәү дәрте, әхлакый кануннарга тугрылыклы булуны күрсәтте. Әлмәндәр картның тормышы мәгънәсез үтми. Мәгънәсез яшәү нәрсә ул? Мәгънәсез тормыш ул — үз-үзеңнән канәгать булмау, үзең турында матур истәлекләр калдырмау, сине берәү дә сагынып искә алмау. Әгәр кешенең үз-үзен тотышында һәм кылган эш-гамәлләрендә мәгънә булмаса, бу аның тормышында, язмышында чагылыш таба. Мәгънәсез яшәү — кеше язмышын, тормышын үз кулына ала алырдай этәргечтән мәхрүм булуы, аның өчен җавап бирергә әзер булмавы. Гомумән, кеше үз өстендә эшләми һәм тормышын яхшы якка үзгәртергә теләми дә. Нәтиҗәдә ул көчсезгә әйләнә, таяныр ноктасын, яшәү эликсиры бирә торган нигезен югалта һәм теләсә нинди тормыш ситуациясе, проблема аны чыгырдан чыгара, ул күңел тынычлыгыннан мәхрүм кала һәм кешелек сыйфатларын югалтып, тормыш арбасыннан төшеп калырга мөмкин. Аның төшеп калганын берәү дә сизми, аның өчен борчылмый да. Мондый кеше

белән җиңел идарә итеп була һәм ул шәхес булудан туктый, начар кешеләрнең җиңел табышына, корбанына әйләнә.

Өченче дәрестә теманы йомгаклап, укучылар «Кеше китә — җыры кала» темасына инша язалар.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә, сорауларга җавап бирергә. «Кеше китә — җыры кала» темасына инша язарга әзерләнеп килергә.

Укучылар үзләре сайлап алган күренешләрне (Әҗәл белән Әлмәндәр; Евстигней белән Әлмәндәр; Әлмәндәр белән Илсур; Әлмәндәр белән Искәндәр һ. б.) төркемнәрдә сәхнәләштерергә кушып була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Табигатькә таң калырлык (Лирика жанрлары. Пейзаж лирикасы. Габдулла Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә табигать образы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү; табигатьнең матурлыгын күрә белү, таң ату күренешеннән туган хисләргә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, монологик сөйләм төзү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — лирика жанрлары, пейзаж лирикасы төшенчәләрен аңлау, Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлегенә төшенү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 61—64.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

*Синең табигатьне күзәткәнең, таң атканны күргәнең бармы? Таң ничек ата?* соравын биреп, укучыларга теманы өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәреснең максатын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрес әдәбияттагы лирика төре, аның жанрлары белән танышуга, пейзаж лирикасы жанрын өйрәнүгә юнәлдерелгән, моңа Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе», Мөхәммәт Мирзаның «Көздә бер мәл» шигырьләре нигез булып тора. Аларның эчтәлеге үзәгендә укучылар пейзаж лирикасына хас билгеләрне күзәтәләр. Лириканың бу жанрына хас үзенчәлекләрне билгелиләр. Пейзаж лирикасында лирик геройның хисләрен гәүдәләндерүче сурәтләү чараларын табалар. Бу белемнәре нигезендә мөстәкыйль рәвештә әдәби төр буларак лирикага хас сыйфатларны, аның җанрларын күрсәтә алалар. Пейзаж лирикасын мисаллар белән дәлилләләр. Жанр үзенчәлекләренә туры китереп, лирик әсәр иҗат итә һәм сыйныфташлары язган иҗат эшен бәяли алалар.

Татар әдәбиятының эпик, драма төрләре белән укучылар инде таныш. Шуңа өстәп, түбәндәге мәгълүматны җиткерәбез. Әдәби төрләр өчәү. Алар бер-берсеннән сурәтләү предметы (нәрсәне сурәтләве), эчтәлеге һәм формасы (ничек сурәтләве), максаты (кешене нинди яссылыкта сурәтләве) белән

аерылалар. Алар арасындагы иң зур охшашлык шунда: һәркайсының төп сурәтләү предметы булып кеше тора.

Лириканың сурәтләү предметы — кешенең эчке дөньясы: уй-фикерләре, хис-кичерешләре, мөнәсәбәте, шуларның хәрәкәте, үзгәреше. Эчтәлеге — мәхәббәт, нәфрәт, ачу, шатлык, хәсрәт һәм башка бик күп хисләр һәм аларның сәбәпләре. Алар лирик геройның шул вакыттагы кичерешләре, уйланулары буларак аңлашыла. «Мин» исеменнән сөйләнә, сюжет булдыру беренчел түгел, композиция әһәмиятле. Лириканың максаты — кешене уй-фикер, хис-кичерешләр яссылыгында сурәтләү. «Лирика» дигән төшенчә грек телендәге кыллы уен коралы — лира белән бәйләп аңлатыла.

Лирикада хисләрнең сәбәпләре аның жанр үзенчәлегендә дә чагылыш таба. Лирик геройның шәхси кичерешләре белән бәйле күңел лирикасы, табигать сурәте тудырылган пейзаж лирикасы, тарихи вакыйга, җәмгыятьтәге тәртипләрне чагылдырган гражданлык лирикасы, сәяси фактларга нигезләнгән сәяси лирика һәм яшәеш кануннарына бәйле уйлануларны эченә алган фәлсәфи лирика жанрлары бар.

Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигыре белән укып танышканнан соң (бу теманы өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин), укучылар аның табигать күренешен сурәтләвен билгелиләр. Шул вакытта пейзаж лирикасы турында төшенчә бирәбез. Табигать күренешләрен тасвирлаган лирик әсәрләрне пейзаж лирикасы дип атыйлар. Мондый шигырьләрдә табигатьнең бер күренеше, аерым детальләр ярдәмендә баетылып, образга әйләнә.

Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә табигатьтә таң күренеше образы тудырыла. Иң элек, укучыларның, үз күзәтүләренә нигезләнеп, таң вакытын ничек күз алдына китерүләрен, шуңа бәйле хис-кичерешләрен ачыклыйбыз. Алга таба шигырьдә бирелгән күренешләр, тойгылар белән чагыштырабыз. Шигырьдә таң вакытын бөтен матурлыгында ачу өчен, ай бату, йолдызлар сүнү, әкрен искән җил, ямь-яшел кыр ачылу, яфракларның аз-аз селкенүе, караңгылык китү кебек детальләр кулланыла. Таң ату *галибәнә яктырып, әкрен генә* эпитетлары ярдәмендә сурәтләнә, *кап-кара чапан (кап-кара өс киеме)* төнгә метафора булып килә.

Пейзаж лирикасы гажәеп табигать образларына ия. Шул образлар шагыйрьнең табигатьне күрү рәвешен, аны бәяләвен күрсәтәләр. Пейзаж лирикасына хас билгеләрнең берсе — анда бер хис үстерелә бара һәм соңгы строфада фикер әйтелә. «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә соклану хисе үстерелә, җәйге таң күренешеннән таң калу әсәрләнү дәрәҗәсенә җиткерелә. Автор иң ахырдан нәтиҗә ясый: таң вакыты — илһам килә торган чак, димәк, уйланырга кирәк һәм шулвакыт илһам киләчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның күңеленә хуш килгән, ошаган табигать күренешләре турында сораштырып, әңгәмә үткәреп була.

Шулай ук Г. Тукай шигырендә кулланган искергән сүзләрне формаларны куллану үзенчәлекләрен күзәтеп эшләргә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

«Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата» темасына инша язарга әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Күңелдәге моңнар сүзгә күчә (Мөхәммәт Мирза. «Күздә бер мәл»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгәнлек; күзге табигать тудырган хискә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Мирзаның «Көздә бер мәл» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлекләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 65.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү.
2. Көз ел фасылы турында сөйләшү үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапларда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәрестә сүз нәрсә турында барачагы фаразлана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

М. Мирзаның «Көздә бер мәл» шигырен сәнгатьле укыйбыз, укучылардан шигырьдән алган беренче тәэсирләрен белешәбез. Шигырь көзге табигатьнең матурлыгы турында. Шигырьнең үзәгендә табигать сурәте тора: детальләп, алтын көз тасвиры тудырыла. Табигать сурәте барлыкка китергән хис-кичерешләр лирик геройның күңел халәтен билгели: ул шундый илаһи матурлыкны күреп соклана, җанына тынычлык ала.

Шигырьне строфалап анализлыйбыз. Беренче өч строфада пейзаж тасвирын бирүдә тынлык образы алгы планга чыга. Биредә табигать сурәте лирик геройның күңелендәге тынычлык, гармония халәте турында сөйли.

Соңгы ике строфада пейзаж тасвирын сурәтләүдә көзге авазлар образы төп рольне уйный. Бу строфаларда гәүдәләнгән табигать сурәте лирик геройның күңелендәге соклану, хозурлану халәте турында сөйли.

Шигырьнең эчтәлегенә нигезләнеп, шигырьдән төп теманы атаган сүзтезмә булып *алтын көз* тора.

Шигырьдә автор төрле сурәтләү чараларыннан файдалана: метафора (алтын көз); чагыштыру («Бөтен тирә хәрәкәтсез, дөнья тынып калган сыман»); эпитет («Гаҗәп тынлык, сихри тынлык, илаһи мәл); җанландыру («Мәрткә киткән тал, ярлары»).

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Рәссам булсаң, син Мөхәммәт Мирзаның «Көздә бер мәл» шигыре буенча картинаны нинди итеп ясар идең? Нинди төсләр кулланыр идең? Ни өчен?* сорауларын биреп, укучыларның җавапларын тыңлыйбыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга. Жанр үзенчәлекләрен саклап, пейзаж лирикасына караган шигырь иҗат итәргә тәкъдим итеп була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата (Иҗади эш: «Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата» темасына сочинение).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлеген аңлау; табигатьнең матурлыгын күрә, аңа соклана белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; үз фикерен язма текстларда белдерү, язма текстлар төзү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне системага салу, сочинение язу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 61—65.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эше тикшерү. Алдагы дәрестә үткәннәрне искә төшерү

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге этапта сочинение язу өчен алынган тема буенча аерым сорауларны ачыклау, план төзү, шул план буенча төгәлләштерүләр ясау, план буенча сөйләү кебек эшләрне башкару күздә тотыла.

Төрле әсәрләрдә таң вакытын сурәтләнеше биргән өзекләр белән таныштырырга мөмкин. Мәсәлән, 5 нче сыйныфта укучылар Габделхәй Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» әсәре белән танышкан булалар (татар мәктәпләре). Укучыларның игътибарына биредән өзекне тәкъдим итеп була:

*Гаҗәп. Таң вакытында урман тылсымлы бер төскә керә икән! Агач асларында куе күләгә, тау куышы кебек караңгы. Ә кояш төшкән урыннарда агачлар ачык яшел төстә. Һәр агачта, һәр ботакта — меңләгән чык бөртекләре. Аларның һәрберсе, күзләрнең явын алырлык булып, төрле төсләр белән балкый. Үләннәрдәге чыклар да бик кызык: кояш төшкән урында алан өсте көзге кырау төшкән кебек ап-ак, ә күләгә җирдә — куе зәңгәр. Әйтерсең кемдер төн буе зәңгәр буяу сибеп йөргән!*

Мисал өчен 9 нчы сыйныф өчен уку әсбабында бирелгән Ф. Садриевның «Таң җиле» әсәреннән берничә өзек:

*Җир йөзендә таңнан да матур нәрсә юк. Таң атканда, бөтен нәрсә — сулар, һавалар да, үләннәр, чәчәкләр дә, җиләк-җимешләр дә шифалы. Барлык тереклек ияләренең*

*җан җылысы, җир өстенә җәелгәндә, таң җиле булып исә. Таң суы, таң чыгы, таң җиле күңел чирләрен дә дәвалый...*

*...Кошлардан кала бар җиһан татлы йокыда. Пыяладай шома су өстеннән урыны-урыны белән аксыл пар күтәрелә. Ык аръягындагы яшел куаклар да, зәңгәрләнергә өлгермәгән күк тә әле төн шәүләсен саклыйлар. Нуриасма бераз башын күтәрде дә, карашын Ык аръягы өстеннән йөгертеп, еракка — зәңгәрсу өрфия артында күкләргә ашып торучы Чия тавына юнәлтте... Кояшның алтын бишеге тау итәгенең әнә шул бил турына асылгандыр кебек тоела Нуриасмага... Таң беленә, таң ата... Таң, таң, таң... Исеме үк чыңлап, моң таратып, җырлап тора.*

Сочинение планының бер үрнәге:

I. Кереш.

Лирикада табигать образлары.

II. Төп өлеш.

Сызылып кына офык алсулана.

Кояш күренде.

Тынычлык һәм хозурлык.

Табигать уяна.

III. Йомгак.

Табигатьнең матурлыгын күрә белергә кирәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Сочинение язылa. Тәмамланмаган очракта өйдә язып килергә кушыла.

**VI. Өй эше бирү.**

Сочинениене язып бетереп килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Йөрәк ярасын җылы куллар гына дәвалый (Күңел лирикасы. Хәсән Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә хис-кичерешләр тирәнлеге).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмо-

циональ халәтен аңлау; моңсулану, сагышлану, юксыну хисләренә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилле әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Х. Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигыренең эчтәлеген белү, мәгънәсен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 66—67.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге этапта өй эшен тикшерү, белгәннәрне кабатлау башкарыла ала.

*Вулканнарга ничек кереп була?* соравын биреп, укучыларны уйландырабыз, теманы өйрәнүгә кызыксыну уятабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшү нигезендә укучылар теманы, максатны билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Сөйләшүне шигырьләрдә лирик геройның шәхси тормышы белән бәйле хис-кичерешләре, хыяллары сурәтләнүен ачыклаудан башлыйбыз. Мондый шигырьләр кешенең иң нечкә, интим, күңел кылларын тибрәтергә сәләтле күңел ли-

рикасын тәшкил итүен әйтәбез. Күңел лирикасына дәреслектә китерелгән билгеләмәне укытабыз.

Х. Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» әсәрен сәнгатьле итеп укып, аннан алган беренче тәэсирләрне сораштыру барышында түбәндәгеләр ачыклана: шигырь якын кешесен югалткан герой турында. Ул сөйгәне үлгәнче кайтып өлгерә алмаган. Бу югалтуны ул чиксез авыр кичерә: «Вулканнарга керер идем, шундадыр ул... дисәләр», юллары шуны дәлилли.

Алга таба Хәсән Туфан биографиясе, хатыны Луиза Сәлиаскарова белән бәйле аңлатмалар бирү сорала: 1956 елда Хәсән Туфан, акланып, сөргеннән кайта. Ул кайтканда сөекле хатыны Луиза Сәлиаскарова һәм уллары Идегәй үлгән була. Бу югалтуны Хәсән Туфан бик авыр кичерә. Күңелендәге югалту сагышы аны гомере буе озата бара. Бу аның Луизага багышланган бер цикл шигырьләрен, күңел лирикасын тудыра. Аларда шагыйрьнең үз язмышын чыгылдырган хис-тойгылар өстенлек итә. «Кайсыгызның кулы җылы?» шигыре дә шул циклдан. Шигырьдәге һәр образ-деталь аның сагышының тирәнлеген ачарга ярдәм итә. (Бу турыда сөйләгәндә, видеодәрес материалын файдаланып була.)

Шигырьдә лирик «мин»нең күңелендәге хис тойгылары *күлмәк җиңе, алка, кабер, вулкан, җылы кул* образлары аша ачыла. Күлмәк җиңен ертып яраны бәйләү чарасызлык, авыр хәлдән чыгу юлында ялгыз икәнлеген белдерә. Алка һәм кабер — сөйгәне турында иң соңгы истәлек. Вулкан сөйгәне белән очрашу өчен гомерен бирергә, тере килеш утта янарга да әзерлеген, хисләренең чиксез олылыгын дәлилли. Лирик герой чарасызлыктан сызлана. «Кайсыгызның кулы җылы?» дип, лирик «мин» кешеләргә эндәшә. Ул сагыш-кайгыларын уртаклашыр, ялгызлыктан аралар, йөрәген җылытыр кешеләр эзли.

Шул ук вакытта күп авырлыклар аша үтеп, еламаска, сыкранмаска, түзәргә өйрәнгәнлеген дә искәртә. Бу авырлыкларны үзе җиңеп чыгарга тиешлеген белә. Әмма аңа җылы кулын сузучы, кайгысын уртаклашучылар кирәк.

Х. Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы» шигырен күңел лирикасы буларак билгеләргә мөмкинлек бирә торган

төп үзенчәлек — авторның язмышы белән бәйле шәхси кичерешләр тасвирлануы.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Мәхәббәт, тугрылык турында әңгәмә үткәреп була.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне яттан өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр, нәрсә әйтер туганнарыма? (Хәсән Туфан. «Агыла да болыт агыла»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау; сагыну, чарасызлык хисләренең асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, гомумиләштерә һәм нәтиҗә ясый белү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә һәм дәлилле белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Х. Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигыренең идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 68—69.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. Күңел лирикасы лирик геройның шәхси тормышы белән бәйле хис-кичерешләрен, хыялларын сурәтләвен, хис-кичерешләрне табигать образлары, символлар аша белдерүен хәбәр итәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигырен сәнгатьле итеп укып, эчтәлеген кыскача сөйләгәннән соң, укучылардан шигырьнең нәрсә турында булуы хакында сораштырабыз.

Шигырь туган җиреннән, Казаннан, туганнарыннанеракта, алар белән хәбәрләшү мөмкинлеге булмаган герой хакында. Лирик героей туган җиреннән читтә сагыну-сагышлар эчендә яши. Аның күңелен аңлаучы юк, вакыт үз җае белән үтә тора. Болытлар агыла, яңгыр ява. Тирән сагыш эчендәге бу геройда аларның гаме юк. Шигырьдә ялгыз, чарасыз, сагышлы герой турында сөйләнә.

«Агыла да болыт агыла» шигыре авторның язмышы белән бәйле. Тарихның шундый бер чоры була: 1937 еллардан башлап, төрле гаепләр тагып, халык дошманы исеме белән кешеләрне төрмәгә утырталар. Бу фаҗига шагыйрь Хәсән Туфан язмышына да кагыла. 1940 елның көзендә кулга алына һәм 10 ел төрмәдә утыра. Калган гомерен сөргендә Себердә үткәрергә тиеш була. 1956 елда акланып, Казанга кайта. Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла» әсәре сөргендә вакытта языла. 1951 елның 2 августында абыйсына юллаган хатында: «Бүген ял көнем иде. Җиләккә бардым. Кайтканда, көтмәгәндә, яңгыр каршыга килеп чыгып, үз телендә шыбырдый-шыбырдый (5 км) озата килде», — дип яза.

Шигырьдә туган җиреннән, туганнарыннан еракта булган лирик «мин» үзенең хис-кичерешләрен сөйли. Ул болытларның битараф кына Туган якка агуларына карап сагышлана. Болытлар таулар аша Казан ягына агылалар. Әмма алар тишек итекләр киеп, яңгыр астында чыланып, борчуга күме-

леп яшәгән кешенең күңелен аңламыйлар. Лирик «мин» туганнары белән хәбәрләшә алмавы хакында сөйли. Бу кичерешләрне белдерү өчен, автор *болыт, яңгыр, кукурузлар, юл* кебек табигать образлары куллана. Алар гадәти образ гына түгел, символик образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Табигать образлары лирик «мин»нең эчке кичерешләрен ачарга ярдәм итә. Аның сагыш тулы күңеленә битарафлык саклап, туктаусыз аккан вакытны гәүдәләндергән болытлар, дөньяны сафландыручы яңгырның да аңа карата ваемсызлыгы лирик «мин»нең күңелендәге сагышның тирәнлеген ача. Юл образы, ничек кенә авыр булса да, яшәүнең матурлыгы турында сөйли.

Шигырьдә туктаусыз агылучы болытлар — гомер, вакыт агышының символик гәүдәләнеше. Вакыт өметләр белән тулы. Лирик «мин» туганнарын күрергә өметләнгән кебек, туганнары да аның хәбәрен көтеп яши. Ләкин нәрсәдер үзгәрер кебек тә түгел, аның хисләрен аңлаучы юк, битараф тынлык. Әмма ул төшенкелеккә бирелми, гомер юлын күңелле романга тиңли. Тормышындагы авырлыкларны да гадәти хәл дип кабул итә. (Итекләрнең тишеклеге куркыныч түгел, кешеләр бит Җиргә яланаяк килә.) «Агыла да болыт агыла» дигән юллар, кабатланып, өмет, сагыну-сагышлар белән тулы гомернең туктаусыз агышын гәүдәләндерә.

Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигырендә күңел лирикасына хас сыйфатлардан түбәндәгеләрне күрсәтеп була: авторның язмышы белән бәйле шәхси кичерешләр тасвирлана, шагыйрь табигать образларын иркен куллана һәм аларны символик югарылыкка күтәрә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Агыла да болыт агыла» җырын тыңлаганда туган хис-кичерешләре турында сөйләтә алабыз.

**VI. Өй эше.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яшьлек эзләре калган үзән (Сибгат Хәкимнең «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгән булу; якка мәхәббәт хисенең олылыгына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — С. Хәкимнең «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыренең эчтәлеген аңлау, идея-эстетикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 69—70.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максатыннан, укучыларны Ә. Еникинең «Туган туфрак» повестеннан алынган түбәндәге өзек белән таныштырабыз.

*Кларанның бабасы, мәрхүм, аңа еш кына: «Клара бәбкәм, безнең Каракошны бер кайтып күрер идең, ата-бабаңның туган туфрагы бит ул!» — дип әйтә торган иде. Бабасының бу сүзләренә каршы Клара, ни әйтергә белмичә, уңайсызланып кала торган иде. Әллә кайдагы ул «туган*

*туфрак» дигән нәрсә аңа билгесез, ят иде, шуңа күрә бабасының сүзләре аңарда бернинди теләк тә, кызыксыну да уятмый иде. Гомумән, Клара, чын шәһәр кызы булганлыктан, авыл җирен өнәп бетерми иде. Нәрсә ул авыл? Азрак күрергә туры килде аңа мактаулы авыл җирен. Салкын, пычрак көзләрдә барып, бәрәңге казып йөрде. Чыланды, күшекте, тыгыз өйләрдә тараканнардан җирәнә-җирәнә куныл ятты, өс-башы тузып, үзе керләнеп бетте һәм бөтен кайгысы тизрәк шул «бәрәңге базыннан» котылу турында гына булды. Бернинди кызык та, матурлык та тапмады ул анда.*

*Ничек кенә булмасын, бабасының «туган туфрак» дигәнен Клара ихтыярсыздан әлек үзе барып йөргән әнә шул Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләре белән бертөсләрәк итеп күрә иде.*

Укучылар өчен туган туфракның нәрсә аңлатуын, бу сүз аларда нинди күзаллаулар тудыруын ачыклап, әңгәмә үткәрәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Сибгат Хәкимнең «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыренең темасы — Туган җиргә мәхәббәт. Шигырьдәге лирик геройның күңел кичерешләре Туган ягына булган мәхәббәте, андагы балачак, яшьлек хатирәләре, сагынулары белән бәйле. Ул җиренең газиз, күңелгә якын, кадерле туган җир табигате образлары — кырлар, үзәннәр, таллар, җырлар, юл образлары аша ача.

Шигырьнең төп идеясе — туган туфрак балачак, яшьлек хатирәләрен саклый, шуңа күрә ул бик тә газиз. Ул лирик геройның күңел кичерешләре белән бәйле. Шуңа күрә күңел лирикасына карый.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Туган як, аның матурлыгы турында мәкальләрне, җырларны, шигырьләрне искә төшереп, әңгәмә үткәреп була.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Байлык белән бәяләнми гомер (Фәлсәфи лирика. Равил Фәйзуллин. «...Җыя кеше», Мөхәммәт Мирза. «Моң»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгән булу; яшәү мәгънәсе, кешенең тормыштагы урыны төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Фәйзуллинның «...Җыя кеше», М. Мирзаның «Моң» шгырьләренең эчтәлеген аңлау, идея-эстетик үзенчәлекләрен билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 71—73.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү, үткәннәрне искә төшерү.

*Шигырьдә хис өстенлек итәргә тиешме, әллә фикерме?* соравын биреп, укучыларны теманы өйрәнүгә кызыксындырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Яшәештәге төрле хәлләр, вакыйгалар турында фикер йөрткәндә, аңа мөнәсәбәт белдергәндә, кеше тәэсирләнүдән туган беренче ярсу хисләре белән уртаклашырга яки тәҗрибәле кеше сыйфатында аңа читтән торып бәя бирүче ролен алырга мөмкин. Бу вакытта үзәктә хис-кичереш түгел, дөньяга караш тора, ягъни лирик герой нинди дә булса хакыйкатьне ачарга, шуны башкаларга җиткерергә тели. Бу вакытта фәлсәфилек турында сүз бара. Фәлсәфә сүзе «акылны ярату» дигәнне аңлата. Фикер әйтүне беренче урынга куйган, тормыш кануннарын, кешенең яшәештәге урынын аңларга-аңлатырга омтылган шигырьләрне дә шуңа фәлсәфи шигърият дип атаганнар.

Фәлсәфи лирикада кеше, язмыш, яшәеш хакында уйланулар урын ала. Бу жанр яшәешне бербөтен итеп карый, биредә кешенең асылы, яшәү мәгънәсе, тормыш законнары, яшәү һәм үлем, бу дөнья (фанилык) һәм теге дөнья турында сүз алып барыла. Фәлсәфи лирика тамырлары белән дөньяның ничек барлыкка килү турындагы мифларга барып тоташа, дип саный галимнәр.

Бу дәрестә Р. Фәйзуллинның фәлсәфи лирикага караган «...Җыя кеше», М. Мирзаның «Моң» исемле зур булмаган шигырьләре өйрәнелә.

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укыйбыз, һәрберсе турында аерым сөйләшү алып барабыз.

Равил Фәйзуллинның «...Җыя кеше» шигырендә кеше гомере буена күп әйберләргә ирешә һәм аларның иясе була. Шулай да алар барысы да — бу фани дөньяда кала торган әйберләр. Болардан тыш, бу дөньяда аның кылган эшләре

(нинди булуына карамастан), кешеләргә китергән файдасы кала. Иң мөһиме: дәвамчылары кала, алар булганда эше дә онытылмаячак. Ләкин эшенең нинди булуын (яхшымы, яманмы) улының яки кызының күзләре (күңеле) күрсәтәчәк. Балаларының күзләрендә Кояш булып күренер өчен, бары тик яхшы, изге гамәлләр генә эшләргә кирәк, дияргә тели автор.

М. Мирзаның «Моң» шигырен өйрәнгәндә, аерым юлларның нинди мәгънәдә килүен ачыклап, төп идеягә килеп чыгабыз. «*Җаннан бүленгән халәт — моң, җаннарга җитәр өчен…*», дигәндә, шагыйрь кешенең моңлы күңел халәтен сүз белән аңлатып бетерү мөмкин түгел, башка кеше җаны белән тоя дигән, мәгънәне күздә тота. «*Җырга-көйгә әверелеп, галәмгә китәр өчен...*», — дигәндә, шагыйрь халыкның галәмгә җитәрлек тирән моңы аның җыр-көйләрендә саклана дигән фикер җиткерергә тели. *Дөнья фани. Моңлы мизгел — мәңгелекнең бер төше* юлларында төп идея җиткерелә, ягъни бу дөньяда һәр нәрсә фани, кеше гомере бер мизгел кебек кенә үтеп китә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Кеше, аның бу дөньядагы урыны турында уйландырып, сөйләшү үткәреп була.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Үткәннәребез бай, киләчәгебез өметле (Гражданлык лирикасы. Гамил Афзал. «Бу — Ватан», Нури Арсланов. «Халкыма»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү; туган иле — Ватаны, үз халкы белән горурлану хисен тою.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Афзалның «Бу — Ватан», Н. Арслановның «Халкыма» шигырьләренең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 73—76.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларны *Кешенең гражданлык бурычы нинди?* соравы турында уйландырып, түбәндәге нәтиҗәгә киләбез: һәркайсыбыз — билгеле бер ил, халык вәкиле. Без шул илнең кануннарын үтәргә, халкыбызга хас әхлакый кагыйдәләргә тугры калырга; ил, халык алдында хезмәтебезне намус белән үтәргә; башка халыкларны, аларның мәдәниятен хөрмәт итәргә; үзебезнең телне, тарихны белергә, рухи мирасыбызны хөрмәтләргә һәм сакларга тиеш.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Гражданлык лирикасын өйрәнүгә 5 сәгать бирелә. Укучылар гражданлык лирикасына хас билгеләр белән танышалар. Г. Афзалның «Бу — Ватан», Н. Арслановның «Халкыма»,

Р. Гаташның «Татар китабы», Р. Харисның «Кеше кайчан матур?» шигырендәге гражданлык лирикасына хас үзенчәлекләрне билгелиләр. Әлеге жанрга караган шигырьләрдә лирик геройның хисләрен гәүдәләндергән сурәтләү чараларын табалар. Шигырьләр белән танышып, алардагы төп фикерне билгелиләр, тема һәм идея уртаклыгын күзәтәләр. Гражданлык лирикасындагы образларның, тел-сурәтләү чараларының үзәнчәлекләрен ачыклыйлар. Бу белемнәре нигезендә мөстәкыйль рәвештә әдәби төр буларак гражданлык лирикасына хас сыйфатларны күрсәтә алалар. Шагыйрьне борчыган иҗтимагый мәсьәләләр һәм халыкның бер вәкиле булган аерым шәхес — гражданинга нинди сыйфатлар хас булырга тиешлеге турында әңгәмә кора алалар.

Г. Афзалның «Бу — Ватан» шигырендә лирик герой, Ватан — туган җир, дип әйтә. Ташлары иске — димәк, борынгы бабаларыбыз җире. Аларның каны, тире тамган җир, изге җир. Шигырьнең соңгы строфасында лирик герой туган җир алдында кешенең бурычы турында фикер йөртеп туган җир өчен җаныңның яртысын да кызганмаска куша.

«Җаныңның яртысын ярып бирү» гыйбарәсен укучыларга Туган җир өчен көчеңне кызганмау, җаныңны дә бирерлек дәрәҗәдә ярату дип аңлатабыз. Лирик герой бабаларыбызның каны, тире тамган изге җирнең тыныч таңының кадерен белергә чакыра.

Гражданлык лирикасында лирик герой, гражданин буларак хис-кичерешләрен белдерә. Ул үз иленең, билгеле бер халыкның вәкиле сыйфатында фикерләрен җиткерә. Аны ил-халык язмышына кагылышлы мәсьәләләр борчый. Ул аерым тарихи вакыйгаларга, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә мөнәсәбәтен белдерә. Лирик герой шәхси кичерешләрен генә түгел, бер иҗтимагый төркем вәкиле буларак сөйли.

Г. Афзалның «Бу — Ватан» шигыренең лирик герое да — туган җирен яратучы, башкаларны да туган җирне, Ватанны җаның кебек кадерләргә чакыручы. Лирик герой урынында Туган җирен яраткан һәр кеше була ала. Бу хисләр безнең өчен дә уртак.

Шигырьдә лирик герой «без» исеменнән сөйли. «Без» ролендә туган җире бер булган халыкны күзаллыйбыз.

Бу шигырьне өйрәнгән вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

Н. Арслановның «Халкыма» шигырендә лирик геройның үз халкы белән горурлануы һәм хөрмәт хисләре чагылыш таба.

Шигырьдә лирик герой халык тормышындагы сугышлар, дәүләтләр җимерелгән чорларны, халыкның дәүләт корып, милләтне бер ояга берләштереп торган чакларын, авырлыкларга бирешмичә, хәрабәләрдән торып баскан вакытларын искә ала.

Н. Арслановның «Халкыма» шигырендә лирик герой, гражданлык лирикасына хас булганча, үз халкы белән горурлану хисе кичерә, бу хиснең сәбәбе — халкына хас матур сыйфатлар. Шуның өчен ул аны яратуын, хөрмәтен белдерә. Башка милләтләрнең дә үрнәк алырлык яклары, акыл, хикмәтләре бар. Шигырьдә татар халкының матур сыйфатлары санала, шунда ук башка халыкларның да уңай яклары ачыла, әмма лирик герой, читкә чыгуга, үз халкын сагына, сагышлана, аның күңеле гел Туган җиргә талпына. Ул шундый нәтиҗә ясый: үз халкыңнан да якынрак халык була алмый, Туган җирдән дә изгерәк җир юк! Башкалар да яхшы, тик үзеңнеке үз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Н. Арслановның «Халкыма» шигырендә лирик герой үз халкы өчен җанын фида итүен, халкына лаек булырга теләвен белдерә. Әсәрдән шул юлларны табып, сәнгатьле итеп укытып, аның буенча сөйләшү үткәреп була.

Татар мәктәпләрендә *Сезгә татар халкының матур сыйфатларын чагылдырып, гражданлык лирикасы жанрында шигырь иҗат итәргә кирәк булса, сез халкыбызның нинди күркәм якларын күрсәтә алыр идегез? Шигыреңдәге төп фикер нинди булыр?* сорауларын биреп уйландыра алабыз. Укучылар татар халкының рухи байлыгын, ярдәмчеллеген, башка халыкларны хөрмәт итеп, үз традицияләренә тугрылыгын, телебезне, матур бәйрәм йолалары саклап яшәвен, кунакчылыгын чисталык яратуын һәм саф күңеллелеген, яу кырында батырлыгын, хезмәт сөючәнлеген күрсәтәләр.

Нәтиҗә ясап, күңелләрендә үз халкына соклану һәм тирән хөрмәт саклауларын белдерәләр.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә. Н. Арслановның «Халкыма» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Туган телне сайлап алмыйлар (Газинур Морат. «Туган тел»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу; туган телгә мәхәббәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Моратның «Туган тел» шигыренең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 76—77.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, «Туган тел ничәү була?» дигән сорауны куеп, әңгәмә үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Г. Моратның «Туган тел» шигырен өйрәнү аны сәнгатьле укудан башлана. Шигырь укылганнан соң, укучыларның шигырьдән алган беренче тәэсирләрен сораштырабыз.

Әсәрне анализлауда дәреслектә бирелгән сорау-биремнәрне кулланып эшлибез.

Шагыйрьнең милләте аның шигырьләренең телендә чагылыш таба: һәр шагыйрь үз ана телендә милләттәшләренә атап иҗат итә. Һәр милләткә хас образлар, сурәтләү чаралары бу әсәрләрдә чагылыш таба. Хәзерге шагыйрьләрне туган телнең юкка чыгу ихтималлыгы, милләтнең әхлагы, аның киләчәге, милләтне саклап калу кирәклеге кебек уйлар борчый.

Шигырьдә, туган телен белгән кеше ай, кояш белән сөйләшә ала, диелә. Лирик герой Әлифбаны дога итеп укый. Туган телен белгән кеше генә тарихын онытмый, дигән фикер җиткерелә. Лирик геройның төп максаты, хыялы да — иленә игелекле булу. Автор әлеге шигыре белән «туган тел, әнкәйләр кебек, бер генә була» дип әйтергә тели.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Туган телнең кеше тормышындагы роле турында сөйләшү үткәреп була.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Утта янмый, суда батмый безнең үткәннәр (Рәдиф Гаташ. «Татар китабы»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп

мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау; татар китабына карата тирән хөрмәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Гаташның «Татар китабы» шигыренең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 78—79.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, укучылардан татарларда язу тарихы, беренче китаплар басылу хакында белгәннәрен сораштырабыз, башлангыч мәктәптә бу турыда алган белемнәрен искә төшерәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Р. Гаташның «Татар китабы» шигырен өйрәнү аны сәнгатьле укудан башлана. Шигырь укылганнан соң, укучыларның шигырьдән алган беренче тәэсирләре хакында сораштырабыз.

Әсәрне тикшергәндә дәреслектә бирелгән сорау-биремнәрне кулланып эшлибез.

«Шигъри йөзек» дип автор бөтен татар шигъриятен атый. «Шигъри йөзек»тәге «алмаз кашлар» гасырлар буена тупланган шигъри мирасның иң-иң яхшы әсәрләрен бәяләү өчен кулланылган. Автор татар теленең буыннан-буынга, шагыйрьдән-шагыйрьгә күчүен алмаз тел ачкычлары дигән образлы гыйбәрә белән җиткерә.

Анализлау барышында укучылар татар китабының күп заманнарны кичеп килгән асыл мирас, гасырлардан аваз салучы булуын аңларга тиешләр. Ул һәрвакыт хәтердә булырга, халыкка сөйләп, ягъни мәгълүмат биреп торырга тиеш. Аның моңа хакы бар, чөнки ул — үлемсез халык китабы.

Шигырьдә халкыбызның әдәби мирасына мактау өстенлек итә. Моның өчен шагыйрь төрле образлар, тел-сурәтләү чаралары куллана. Мәсәлән, *алмаз кашы, алмаз тел ачкычлары* — метафора; *хикмәтле җыр, газиз тавыш* — эпитет; метонимия — *шигъри йөзек*, *пергаментлар, кулъязмалар сөйли* — сынландыру; *сөйлә, китап* — риторик эндәш; кабатлау һ.б.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларга *Сезгә татар җырын мактап гражданлык лирикасына караган шигырь иҗат итәргә кирәк булса, нинди образлар, тел-сурәтләү чаралары кулланыр идегез?* дигән сорауны биреп, әңгәмә уздырырырга мөмкин.

Ахырдан укучылар белән түбәндәге нәтиҗәләрне ясыйбыз: татар җыры халкыбыз кебек ягымлы, шаян, ихлас; анда авыр елларның сагыш, хезмәт шатлыгы, яшь йөрәкләрнең саф мәхәббәт хисләре, аналарның фатихасы, халкымның гасырлар буе туплаган тәҗрибәсе чагылыш таба; җыр — уттай яндыра, җыр яуга күтәрә, җыр яралы җаннарны дәвалый; җыр — чишмә чылтыравы, сандугачлар моңы. Татар җыры — халкыбыз үткән тарихи юл. Җырда Тукайларның сазы чыңлый, Муса Җәлилләрнең васыяте яңгырый, Илһам Шакировлар моңы белән Идел буе каеннары, Казан кичләре дәшә.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Йөз матурлыгы — күзгә өчен... (Ренат Харис. «Кеше кайчан матур?»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау; кешегә хас матур сыйфатларның асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Харисның «Кеше кайчан матур?» шигыренең эчтәлеген аңлау, идея-эстетик үзенчәлекләрен билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 81.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, кешене нинди сыйфатлар матурлавы турында сыйныфта әңгәмә үткәрәбез. Әңгәмәнең ахырында, кешене әхлаклылык, саф күңеле, ил һәм халык алдында үз бурычын төгәл үтәве матурлый, дигән нәтиҗәгә киленә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Ренат Харисның «Кеше кайчан матур?» шигырен укыганнан соң, укучыларга *Әсәрдә шагыйрь тышкы матурлык турындамы, әллә эчке, күңел матурлыгы турында сөйлиме?* дигән сорауны биреп, шигырьдә кешенең эчке, күңеленең матурлыгы турында сөйләнүен ачыклыйбыз. Кеше башкаларга игелекле, шәфкатьле, күңеле нечкә булганда, дусларын онытмаганда, башкаларның рухи халәтен аңлый, «гөнаһлыларны» кичерә алганда, иле һәм халкы өчен көчен кызганмаганда, ил өстенә төшкән авырлыкларда ярдәм иткәндә, зур абруйлы булса да кече күңелле булып калганда матур була, диелә. *Олы дангa ирешеп тә, кече булып калганда* дигән юлларның да мәгънәсе — зур эшләр башкарып та, үзен өстен куймаганда, башкаларны хөрмәт итүе.

Гражданлык лирикасында шигырьнең төп фикере, идеясе ахырдан, юану өлешендә җиткерелә. Юану һәр шигырьдә ачык күренеп тормаска да мөмкин. Ул әсәрдә күтәрелгән проблеманы хәл итү юлы буларак чагылыш таба, авторның теләге кебек аңлашыла.

Ренат Харис «Кеше кайчан матур?» шигырендә әйтергә теләгән төп фикер: кешене әхлаклылык һәм ил алдында бурычын аңлау матур итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шигырьдә кешене матур итә торган күп сыйфатлар санала. *Ә кеше кайчан ямьсез була? Нинди кеше ил алдында гражданлык бурычын үтәмәгән була дип саныйсың?* сорауларын куеп, укучыларны сөйләшүгә алып чыгабыз. Ахырда нәтиҗә ясыйбыз: кеше мактанганда, ялган сүз сөйләгәндә, башкаларны кимсеткәндә, күбрәк үз файдасын кайгыртканда, күңеле сыныкларны аңлый белмәгәндә, кеше шатлыгына сөенмәгәндә, кеше кайгысына битараф булганда, үзеннән соң яхшы эз калдырмаганда ямьсез була. Туган илен, туган җирен, нигезен, туган телен хөрмәт итмәгәндә, йөрәгендә ил гаме булмаганда, халкының уңышларына сөенә алмаганда,

халкына авыр булганда йөрәгендә авырту тоймаганда, ул гражданлык бурычын үтәмәгән санала.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне яттан өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кеше кайчан матур була? (Проект эше яклау); Үткән материалны кабатлау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү, үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру; үткәрелгән тәҗрибә (проект) нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне системага салып гомумиләштерү, проект эшен башкара алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 81.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, «Кеше кайчан матур була?» соравын куеп, укучыларны сөйләшүгә тарту.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Алдагы дәресләрдә алган белемнәрне ныгыту максатыннан укучыларга *Гражданлык лирикасы ни өчен шундый термин белән аталган? «Гражданлык» сүзе нәрсәгә ишарә итә? Татар шагыйрьләре иҗатында гражданлык лирикасында нинди темалар өстенлек итә?* сорауларын бирәбез һәм түбәндәге нәтиҗәне ясатабыз: *Гражданлык* сүзе җәмгыять белән бәйле дигәнне аңлата, әлеге төр лирикада җәмгыятьне борчыган уй-кичерешләр, проблемалар тасвирлана. Татар шагыйрьләре гражданлык лирикасында туган тел, милләт, тарих, халык язмышы, милләтнең киләчәге темаларына өстенлек бирәләр.

*Гражданин-шагыйрь нинди хисләр белән яши, аны нәрсә уйландыра, ул нәрсәләргә борчыла, нәрсәгә шатлана?* соравына түбәндәге җавапны алуга ирешәбез: шагыйрь-гражданин туган җиренә, Ватанга, үз халкына мәхәббәт хисләре белән яши. Халкыбызның рухи матди байлыкларын саклау, иҗтимагый мәсьәләләр, тарихи вакыйгалар турында уйлана. Аны халык, ил тормышындагы куанычлы вакыйгалар шатландыра, ул алар белән горурлана. Халык күңелендәге борчулар аны да кайгырырга мәҗбүр итә.

Шулай ук бу дәрестә «Лирика жанрлары» дип аталган зур темага да йомгак ясала. Шул уңайдан укучыларга алган белемнәргә таянып уйлануны таләп итә торган *Ни өчен шагыйрьләр төрле жанрда иҗат итәләр? Күңел, иҗтимагый, пейзаж, фәлсәфи лирика үрнәкләрен нәрсә берләштерә?* сорауларын биреп була. Нәтиҗә ясала: Һәр кешенең холкы, дөньяга карашлары төрле булган кебек, шагыйрьләрнең дә эчке дөньясы, илһам чыганагы төрле. Бер очракта аларны гүзәл табигать сурәте иҗатка рухландырырга мөмкин, икенче очракта инде алар туган җир, ата-ана, Ватан турындагы тирән хисләрен кәгазьгә төшерә. Барлык шагыйрьләрне дә

милләт темасы борчый, шуңа күрә һәр шагыйрь иҗатында диярлек иҗтимагый лирика актив. Дөнья, яшәеш кануннарын аңлатырга тырышу фәлсәфи лирика аша тормышка ашырыла. Нинди жанрда язсалар да, шагыйрьләрне уртак максат берләштерә: укучының күңеленә тәэсир итү, аны уйландыру.

Дәреснең икенче өлешендә укучылар «Кеше кайчан матур?» дип исемләнгән проект эшләрен тәкъдим итәләр. Бәяләү критерийлары буларак, түбәндәгеләр санала: эчтәлеге ягыннан темага туры килүе; куелган максат һәм бурычларга җавап бирүе; ирешелгән нәтиҗәләрнең гамәли әһәмияткә ия булуы; проект барлык таләпләргә туры китереп тәкъдим ителүе.

**V. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Моң чишмәсе кайдан башлана? (Әдәбиятның лиро-эпик жанрлары. Поэма жанры. Равил Фәйзуллин. «Сәйдәш»);

Халык белән мәңге бергә (Равил Фәйзуллин. «Сәйдәш»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлегенә төшенү; аерым шәхеснең татар мәдәниятенә керткән өлеше турында аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасының эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 82—103.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, татар мәдәниятендә эз калдырган шәхесләр, композиторлар, рәссамнар, артистлар турында сөйләшү үткәреп була. Татар халкы — талантлы халык. Аның сәләтле әдипләре, композиторлары, язучылары, галимнәре бик күп. Ләкин вакыт, сәяси-иҗтимагый вакыйгалар аркасында мәдәни мирас тулысы белән киләчәккә барып та ирешмәскә мөмкин. Халыкка хезмәт иткән бөек шәхесләргә багышлап музейлар ачалар, һәйкәл, бюстлар ясыйлар, шәһәр урамнарына исемнәрен кушалар, китаплар, истәлек-хатирәләр, әдәби әсәрләр язалар.

Алга таба Салих Сәйдәшев иҗат иткән «Совет Армиясе маршы»н тыңлатабыз. Аның авторы күренекле татар композиторы Салих Сәйдәшев булуын хәбәр итеп, укучылардан әлеге шәхес турында белгәннәрен сораштырабыз: *Кем ул Салих Сәйдәшев? Ни өчен Салих Сәйдәшевның тормыш биографиясендә кайбер сорауларга җавап таба алмаган серле вакыйгалар бар? Аның шәхси әйберләре, музыкаль мирасы кайда саклана? Салих Сәйдәшев һәйкәленең, Сәйдәшев урамының, Сәйдәшев исемендәге Концертлар залының кайда урнашуларын беләсегез киләме?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге дәрес әдәби әсәрләрнең лиро-эпик төрен тикшерүгә, поэма жанрының үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана. Укучы поэма жанрына билгеләмә бирергә, тезмә һәм чәчмә

әсәрләргә хас сыйфатларның синтезын билгеләргә, вакыйгадан автор фикерен, бәясен аерырга өйрәнә. Хикәяләүче-автор образының фикерләре белән уртаклашуын, лирик чигенешләр, фәлсәфи уйлануларны аңлауга ирешә. Текст буларак, Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасы алына. Укучылар музейның виртуаль экскурсиясендә катнаша, Салих Сәйдәшевнең тормыш һәм иҗат юлы белән таныша. Композиторның шәхесе, ул яшәгән чор һәм тирәлек турында мәгълүмат туплап, «Сәйдәш» поэмасының сюжет сызыгын тикшерә. Поэмада Салих Сәйдәшевнең язмышында булган каршылыкларга автор бәясен өйрәнә. Поэмага хас лирик һәм эпик катламнарны Равил Фәйзуллин әсәрендә аерып чыгара.

Поэма белән танышканнан соң, *Төп геройның прототибы кем? Төп герой нинди гаиләдә туа һәм нинди тәрбия ала? Поэма әчтәлеге чынбарлык белән туры киләме?* дигән сорауларга җавап бирү барышында поэма Салих Сәйдәшев турында булуы билгеләнә. Ул әтисез үсә, апасының ире тәрбиягә ала, белем бирә, музыка училищесында укытуы ачыклана. Бирәдә поэма чынбарлыкка нигезләнеп язылган дип ачыклык кертәбез. Салих Сәйдәшевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйлибез. Бу вакытта дәреслектәге материалдан файдаланырга мөмкин.

Сәйдәш — катлаулы язмышлы шәхес. Ул күп югалтулар аша уза. Горурланырлык эз калдыра, тормыш биографиясенә карап, дәрес, сабак алырлык урыннары да күп. Автор әлеге поэма белән укучыга талантларга, иҗат кешеләренә тиешле бәя бирелмәве турында, исән чакта талантларның кадерен белмибез, ләкин халык өчен янып яшәгән шәхес онытылмый, талантлы шәхесләрнең кадерен белергә кирәк, дип әйтергә тели.

«Сәйдәш язмышы — гыйбрәт тә, горурлык та, алыр сабак та» юллары белән татарның талантлы уллары күп, ләкин аларның иҗатларын өйрәнергә, халыкка кайтарырга, музей, һәйкәлләрен төзергә, китаплар чыгарырга кирәк, дигән фикер җиткерә.

Поэмада бирелгән *Сәйдәш — Тукае ул безнең көйләрнең!* дигән фикер Салих Сәйдәшевнең музыка сәнгатендә тоткан

урынын билгели. Тукай белән чагыштыру Сәйдәшне соңгы юлга озату күренешендә дә чагылыш таба.

«Шәрык клубы»нда Салихның чыгышларын, аны татар зыялылары тыңлый. «Шәрык клубы» — Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Габдулла Кариев кебек иҗат кешеләренең очрашу, лекцияләр уку, концертлар кую урыны. Шулай итеп, поэмада татар халкының күп кенә танылган шәхесләре искә алына. Алар турында дәреслектә бирелгән «Шәхесләребез» рубрикасынан укып белергә мөмкин.

Шулай ук *Заманалар килгәч, чорлар аша тоташтырыр бергә урамнарны!* юлларының мәгънәсен Казан шәһәрендәге Габдулла Тукай урамының Салих Сәйдәшев урамы белән кисешкән булуын картадан күрсәтеп аңлатсак яхшырак. Гомумән, әсәрдәге һәр бүлекнең ахырында бүгенге көн белән бәйләнеш чагылыш таба.

Автор Сәйдәшнең талантыннан башка затлылыгын, интеллигентлыгын ассызыклый. Сәйдәш халыкка ягымлылыгы, гади мөнәсәбәте һәм иҗаты белән якын. Ул көйләрен халык өчен яза. Үз иҗаты турында уйланып, «Тиешенчә эшли алдыммы?» дип сорау куя. Ул канәгать: эшен яңа буынга тапшырырга әзер. Салих, кинәт авырып, Мәскәү больницасында үлә. Соңгы юлга озатканда, бөтен халык — сабыйлар да, олылар да, авыл агайлары да килә. Тукайны соңгы юлга озаткандагы кебек, урамнар халык белән тула.

«Сәйдәш» поэмасы — тарихи, олы һәм фаҗигалы язмышлы шәхесне бөтен каршылыклары, ачышлары, сөенеч-көенечләре белән шигърияттә ачуга омтылуның беренче зур тәҗрибәсе. Тирән фәлсәфи фикер, гражданлык пафосы, горурлык хисе — поэманың төп сыйфатлары. Поэмада ике юнәлеш ачык төсмерләнә. Беренчесе — Сәйдәшнең тормыш юлы, биографиясе, шәхес һәм композитор булып үсү чорлары. Икенчесе — татар җыры, татар моңы турында уйланулар. Чөнки «халыкларның җаны — җыр ул»...» — дип яза, галим, тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллин. Халык җыры турында уйланып, аның көченә, аһәңенә югары бәя бирү аша автор Сәйдәш иҗатына шәхси мөнәсәбәтен ача.

Равил Фәйзуллин Сәйдәш иҗатын гыйбрәтле, сабак алырлык, горурланырлык дип бәяли. Салих Сәйдәшевнең трагик

язмышы һәм олы таланты аша автор татарларның бай мәдәниятле, җәмгыятьтәге авырлыклар алдында бирешмәс рухлы, затлы халык булуын күрсәтүгә ирешә.

Автор әсәрендә шулай ук татарларның элек-электән җырга-моңга гашыйк булуын, Сабантуйларын, милли бәйрәм, йолаларын искә ала. Концертларга, спектакльләргә агылып килүләрен яза.

Алга таба поэмага билгеләмә бирү сорала. Поэма лиро-эпик жанрга караганлыктан, үзенчәлекләрен искә төшерәбез. Лиро-эпик төр эпик һәм лирик жанрларга хас сыйфатларны туплый, тормыш моделен төзүдә аларның үзенчәлекле синтезы ролен башкара. Эпиклык сюжетлылык, вакыйгалар, персонажлар системасы булуда күренә. Персонажларның эш-гамәлләре гәүдәләнә. Лирик башлангыч исә лирик герой образы, аның хис-кичереш бирелеше тезмә формада чагыла.

Лиро-эпик төргә кергән жанрларны барлап, поэма жанрына аңлатма бирәбез.

Поэма — лиро-эпик жанр атамасы, сюжет сызыклары лирик чигенешләр, хис-кичереш һәм мөнәсәбәт белдерү белән үрелеп бара, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә торган әсәр. Әлеге жанр — лирик һәм эпик башлангычларның үзенчәлекле синтезы. Анда сурәтләнгән вакыйгалар сюжетны — эпик катламны барлыкка китерә, зур вакыйгалар кайчакта берничә сюжет сызыгы тәшкил итәргә дә мөмкин, аларга бәйле төстә, автор үзенең мөнәсәбәтен укучыга җиткерә. Лирик башлангычта исә сурәтләнгәннәргә шәхси мөнәсәбәт, автор-хикәяләүче һәм лирик геройның хисләре, фикерләре, бәясе әһәмиятле роль уйный.

Лирик яки эпик башлангычның эчтәлегенә карап, поэмалар ике төргә бүленә. Лирик башлангыч өстенлек иткән поэмаларда, вакыйгалар чылбырыннан бигрәк, хис-кичереш һәм мөнәсәбәтнең үзгәрүе әһәмиятле роль уйный. Бу очракта, төп герой буларак, лирик герой алга чыга.

Эпик башлангыч сюжет чылбырын, вакыйгалылыкны таләп итә, бу очракта поэмада лирик герой түгел, ә хикәяләүче-герой үзәккә куела. Беренче катлам эчтәлекне тәшкил иткән сюжет, сурәтләнгән вакыйга-хәлләр исә хикәяләүче-автор фикеренең, хис-кичерешенең сәбәбенә әверелә.

Поэма аерым кеше язмышыннан башлап, ил, халык тормышындагы вакыйга-хәлләрне яктырту аша иҗтимагый-сәяси, шәхес, милли проблемаларны күтәрә, тышкы формасы белән шигъри шәкелдә иҗат ителә.

Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасында халык тормышында бәйле вакыйгалар, аерым алганда XX гасырда революцияләр, үзгәрешләр булачагы, татар тормышында театрлар ачылу тарихы, Казан халкының Ташаяк ярминкәләренә, татар зыялыларыңны «Шәрык клубы»на йөрү вакыйгалары һәм башкалар тасвирлана.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Поэма жанры турында сөйләшүне дәвам итеп, Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» әсәрендә поэмага хас сыйфатларны барлыйбыз. Укучылар әсәрдәге әлеге сыйфатлардан биредә лирик һәм эпик төрләрнең синтезы бирелгәнлеген, вакыйгалар һәм хис үрелеп баруын, шәхес, халык, ил язмышы урын алуын, автор-хикәяләүче үз бәясен бирүен билгелиләр. Эпик башлангычта Салих Сәйдәшевнең тормыш һәм иҗат юлы чагыла. Лирик башлангычта хикәяләүченең Сәйдәш язмышына, татар халкы язмышына бәйле вакыйгаларга фикерләре, бәясе урын ала.

Татар мәктәбендә *Поэмада фәлсәфи яссылыкта шәхес таланты вакыт агышында ничек тасвирлана?* дигән сорау биреп уйландыра алабыз. Сорауга җавап бирү барышында талантлар өчен вакыт чик куя алмый, чын сәнгать әсәрләре — мәңгелек, кеше туа, үлә, яшәеш алышына, ә рухи мирас мәңге яши, дигән нәтиҗә ясала.

Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасы татар халкының бөек композиторына мәңгелек һәйкәл кебек яңгырый. *Ничек уйлыйсыз, автор Салих Сәйдәшевнең татар сәнгатендә тоткан урынын тиешле дәрәҗәдә яктыртып бирә алганмы? Әллә күбрәк аның тормыш биографиясенә тукталганмы? Әгәр сез Сәйдәш турында поэма язсагыз, аның нинди сыйфатларына өстенлек бирер идегез?* дигән сораулар биреп уйландырабыз; укучыларның төрле фикерләре тыңлана.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Поэманы укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә, сорауларга җавап бирергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Ерагайган саен ара, сагыну арта бара (Нәсер жанры үзенчәлекләре. Гадел Кутуйның «Сагыну нәсере»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрнең эмоциональ тәэсирен аңлау; сагыну хисе турында төшенчә алу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — нәсер жанры турында мәгълүматлы булу, Гадел Кутуйның «Сагыну нәсере»ндәге идея-эстетик үзенчәлекләрне билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 104—109.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, М. Җәлил сүзләренә, З. Хәбибуллин музыкасына иҗат ителгән «Сагыну» җырын тыңлатабыз. Җыр эчтәлеге нигезендә укучыларга түбәндәге сорауларны бирәбез: *Сугышта Туган илне сагыну хисе тыныч тормыштагы сагыну хисеннән нәрсә белән аерыла? Бу җырда нинди хис-кичереш турында сүз бара? Бу хиснең*

*тууына нәрсә сәбәп булып тора? Ничек уйлыйсың, кешеләрнең сугышта Туган илләрен сагыну хисе әлеге җырдагы сагыну хисеннән көчлерәкме? Шул турыда беләсең киләме?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрес лиро-эпик төрдә образлылыкны тикшерү максатыннан, Г. Кутуйның «Сагыну» нәсерен өйрәнүгә багышланган. Укучыларга әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, лирик герой образының хис-кичерешен һәм аның сәбәбен ачыкларга, әсәрнең темасын һәм идеясен тәгъбир итәргә кушыла. Лиро-эпик төргә характеристика бирелә, әлеге төргә караган нәсер жанрының үзенчәлекләренә якынрак тукталу күздә тотыла. Автор нәсерендә кулланган тел-сурәтләү, шигъри алымнарны барлау аның матурлыгын, аһәңлеген тоярга ярдәм итәчәк. «Сагыну» нәсеренең Гадел Кутуйның тормыш юлына бәйле булуын ачыклап билгеләү әсәрнең идея эчтәлегенә тагын да тирәнрәк төшендерәчәк.

Нәсерне өйрәнгәнче, Гадел Кутуйның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә бирү отышлы була. Язучының портреты белән эш үткәрергә мөмкин. «Гадел Кутуй турында истәлекләр» исемле китаптан Гази Кашшафның Гадел Кутуй турында язган истәлектән өзек укып китә алабыз.

«Сагыну» нәсере белән танышу аны сәнгатьле итеп укудан башлана. Алга таба сораулар ярдәмендә укучыларның әсәрдән алган беренче тәэсирләре турында белешәбез. Нәсерне анализлау барышында солдат образына характеристика бирәбез, аның хис-кичерешләрен, эчке дөньясын ачабыз, әсәрдәге сагыну хисе турында сорашып, аның сәбәбен ачыклыйбыз. Тексттан сагынуның көчен белдерә торган җөмләләрне табып укытырга мөмкин. Иң мөһиме — әлеге әсәрнең Гадел Кутуйның язмышына бәйле булуын аңлатырга кирәк.

«Сагыну» нәсере чит илләрдә йөрүче солдатның Туган илен сагынуы турында сөйли. Ул төрле җирләрдә була, сугыш чорында төрле илләрне үтә, анда никадәр яхшы булмасын, ул үз Туган илен сагына. Нәсер лирик герой (солдат, язучы үзе) исеменнән сөйләнә. Әсәрдә сугыш еллары турын-

да сүз бармый. Сугыш инде тәмамланган. Моны «Мин горур атлыйм, чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим» дигән юллардан укып белергә мөмкин.

Сагыну нәсердәге төп хис булып тора. Лирик герой Туган иленнән бик еракта. Шуңа күрә сагынуы да көчле. Сагыну хисе лирик геройны дошманнан үч алуга этәрә, Туган иленә кайтып җитә алуына өметләндерә.

Гадел Кутуйның «Сагыну» нәсерен биш өлешкә бүлеп өйрәнәбез. Нәсернең беренче өлешендә лирик герой чит илдәге матур гөлләрне телгә ала, үз иленең энҗе чәчәкләрен, хәтта әрем исләрен сагынуын әйтә. Чит илдәге чәчәкләрне туган җир әреме белән чагыштыра. Лирик геройның Туган илне сагыну хисе беренче планга чыга. Сәбәбе итеп лирик геройның Туган иленнән еракта булуын күрсәтә алабыз.

Икенче өлештә лирик герой үз туган иленең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын, елга һәм чишмә суларын сагынуын сөйли. Лирик геройның Туган илне сагыну хисе беренче планга чыга. Шуңа күрә ул образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Сәбәбе итеп лирик геройның Туган иленнән еракта булуын күрсәтә алабыз.

Өченче өлештә лирик герой Туган илнең матурлыгын тасвирлый. Җиңүче совет солдатын чит илләрдә җылы каршылыйлар, хөрмәт итәләр. Ләкин нинди генә матур җирләр булса да, лирик герой аларны үз илендәге гүзәллек белән алмаштыра алмый. Бу өлештә лирик герой туган илендәге тау һәм күлләрне чит илнең тау-күлләре белән чагыштыра, туган илнең матурлыгы турында сөйли. Моның өчен ул *илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтле бер җир, газиз, ямьле* кебек сүзләрне куллана.

Бу өзектә хис-кичерешләр булып соклану (сәбәп — туган иленең матурлыгын күрә белүе), сагыну (сәбәп — Туган илдән еракта булуы) тора. Җиңүче солдатны чит илләрдә олы хөрмәт белән каршы алалар, чәчәкләр бүләк итәләр, сыйлыйлар. Чөнки ул аларның илен фашистлардан азат иткән. Ләкин лирик герой барыбер йөрәккә җылы өргән нечкә билләрен, гөнаһсыз балаларын сагына.

Дүртенче өлештә лирик геройның үз халкын, Туган ил кешеләрен сагынуы тасвирлана. Автор чит ил кешеләрен,

аларның кунакчыллыгын мактый. Әлеге чагыштыру аша сагыну хисен тагын да көчлерәк итеп бирә.

Лирик герой Берлинга барып җитәргә ашыга. Берлинга ул, Туган иленә тизрәк кайтып җитәр өчен, Туган иле белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен, чиксез ачу белән бара, чөнки дошманны ахырына кадәр юк итәргә кирәк. Ул горур атлый, чөнки ул — җиңүче, дөньяны дошманнан азат итүче.

Бу өзектә горурлану (сәбәбе — совет иленең җиңүе), ачу (сәбәбе — дошманнан үч алу), сагыну (сәбәбе — туган иленнән еракта булуы, аны күрәсе килүе) кебек хисләр бирелә.

Бишенче өлештә дә туган илне сагыну ярылып ята. Биредә лирик геройның сагыну хисе иң биек ноктасына җитә, ул шулкадәр көчле җыр булып тышка атылып чыга.

Сагыну хисе лирик геройның көч-дәртен арттыра, рухын канатландыра. Ул кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда булмавын аңлый. *Сагынган саен сагынасы килә* дигән сүзләр лирик геройның сагыну хисенең көчен билгели. Ул Туган илен өзелеп сагына. Лирик герой үзенең туган иленә исәнсау кайта алуына нык ышана, чөнки сугыш инде беткән, дошман юк ителгән, туган якка, өйгә генә кайтасы кала.

Әсәрнең темасы — Туган илне сагыну дип билгели укучылар.

Язучы бу әсәре белән чит илләр нинди генә булмасын, һәр кеше өчен Туган илнең кадерле, якын булуы, аны яратырга һәм иминлеге өчен тырышырга кирәклеген әйтә.

Сурәтләү чараларын таптырабыз.

Алга таба әлеге әсәргә нигезләнеп, нәсер жанрына аңлатма бирәбез. Нәсер — кечкенә күләмле әсәр. Ул эмоциональлеге, ритмик төзелеше белән шигъри прозага якын. Нәсердә хис-кичерешнең тирәнлеге аны образ дәрәҗәсенә күтәрү мөмкинлеген бирә, ягъни биредә хис образ була ала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Кеше өчен туган ил нәрсә ул?* дигән сорау буенча әңгәмә үткәрү. Туган ил, туган як турында укучылар белән шигырьләр, җырлар, мәкаль-әйтемнәрне искә төшерәбез.

Гадел Кутуй «Сагыну» нәсеренә кертеп җибәргән татар халык җырлары турында сөйләшеп була. Халык җырлары — геройның психологик дөньясын ачу чарасы. Солдат та, сагынуына түзә алмыйча, йөрәк хисен җырда бирә. Тексттан җырларны табып укытабыз. Автор ни өчен җыр образына мөрәҗәгать итүен ачыклыйбыз. Гадел Кутуй җыр образы ярдәмендә лирик геройның хис-кичерешләрен, сагыну хисенең тирәнлеген, Туган илнең иң газиз нәрсә икәнлеген ачып бирүгә ирешә.

Гадел Кутуй «Сагыну» нәсерендә шактый күп географик атамаларны телгә ала. Телгә алынган һәр географик атама авторның тормыш юлы белән бәйле. Ул Идел буенда Сталинград сугышында катнаша, Дон фронтында авыр гвардия миномет бригадасы сәяси бүлегендә хезмәт итә. Тыныч вакытта, Карпат тауларында, Финляндия күлләре янында була. Шуңа күрә аларны илебездәге күлләр, Казбек, Эльбрус таулары белән чагыштыра ала. Польшада дошманга каршы көрәшә, Берлинга барып җитү аның хыялы була. Бүгенге көндә кабере Польшаның Згеш шәһәрендә урнашкан.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Нәсерне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә. Нәсердән өзекне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Үткән материалны кабатлау. Контроль эш.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — белемгә омтылышның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру, гомумиләштерүләр, нәтиҗә ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне системага салып гомумиләштерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—109.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Үткәннәрне искә төшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар алдагы сөйләшүдән соңгы дәрес буларак, кабатлау, үткәннәрне искә төшерү дәресе икәнлеген билгели алалар.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Кабатлауны төрлечә оештырырга мөмкин. Анда һәр укучы катнашырга (димәк, сорауларның авырлары һәм җиңелрәкләре дә), дәрес формасы да кызыклы булырга тиеш. Мәсәлән, алдан карточкалар әзерләп, аларга бу бүлектә укылган әсәрләрнең исемнәрен һәм авторларын язып куярга мөмкин. Һәр партада утырган (төркемдә булган) укучылар бер карточканы алып, әсәр турында белгәннәрен әйтәләр (башка төркемнәр дә өсти ала). Бу — укылган әсәрләрне тиз генә искә төшерергә ярдәм итә. Шул ук алым белән аерым әсәрнең темасын, төп фикерен искә төшерергә, бирелгән өзекнең кайсы әсәрдән булуын ачыкларга һ.б. биремнәрне үтәргә була.

Шулай ук эшне дәрес-семинар рәвешендә үткәрергә мөмкин. Укытучы үзе әзер темалар тәкъдим итәргә мөмкин, яки укучылар аларны үзләре уйлап килә алалар. Моның өчен укучыларга бу дәреснең үткәрелү турында бер атна алдан хәбәр ителә. Дәресне аерым чыгышларны тыңлап үткәрергә мөмкин.

Кабатлауны дәрес-зачёт итеп тә оештырып була. Бер атна алдан укучыларга сораулар бирелә. Эшне төрләндереп, сорау-

ларны укучылардан үзләреннән төзетәбез. Уйлануга этәрә торган иң яхшы сорауга конкурс да үткәрергә мөмкин. Бу сорауларга җавап эзләү барышыңда укучылар ел дәвамында үткән материалга кат-кат әйләнеп кайтырга мәҗбүр булалар, шул рәвешле, аларга белемнәрне системага салып гомумиләштерү мөмкинлеге туа.

Шуны истә тотарга кирәк: йомгаклау дәресендә эш төрлечә оештырылып, биремнәр дә төрле булырга мөмкин, әмма кабатлау үтелгән материалның иң әһәмиятле өлешләре укучының хәтеренә сеңдеререргә булышырга тиеш.

Дәреснең икенче өлешендә ел дәвамында үзләштергән белемнәр нигезендә контроль эш эшләтәбез яки электрон дәреслектә бирелгән тестны үтәргә тәкъдим итә алабыз. Бу очракта үзбәягә мөмкинлек бирергә кирәк. Шулай итеп, тест нәтиҗәләренә карап укучылар үзләренә бәя куярга тиешләр.

**VI. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

# ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР ИСЕМЛЕГЕ

www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/uchebniki — Дәреслекләрнең электрон формалары.

www.antat.ru/ru/tatzet — Татар теле: зур электрон туплама.

https://magrifat.antat.ru — Укытучылар, әти-әниләр һәм балалар өчен мәгълүмати ресурс.

https://photo.miras.info/№ — «Татарское визуальное наследие» сайты

www.belem.ru — Татар мәгарифе порталы.

www.balarf.ru — Интерактив мультимедия китапханәсе.

http://tatarile.tatar — «Татар иле» укучылар өчен электрон энциклопедиясе.

www.ganiev.org — Русча-татарча тавышландырылган онлайн сүзлек.

www.tatarhistory.ru — Татарстан тарихы буенча электрон атлас.

www.tatarcartoon.ru — «Татармультфильм» берләшмәсе эшләгән анимацион фильмнар җыентыгы.

Учебное издание

**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна
**Абдуллина** Дилария Маратовна

РОДНАЯ (ТАТАРСКАЯ) ЛИТЕРАТУРА

**7 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
основного общего образования, работающих с обучающимися,
владеющими родным (татарким) языком

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы
**Абдуллина** Диләрия Марат кызы

ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**7 нче сыйныф**

Методик әсбап
Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *А. А. Дәүләтова*
Рәссамы *Д. Л. Нәүрузова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Л. И. Матвеева*

Подписано в печать с оригинал-макета 21.08.2024
Формат 60×84 1/16.